



А. С. ПЧЁЛКО һәм Г. Б. ПОЛЯК

АРИФМЕТИКА

3 нче класс өчен

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1961





А. С. ПЧЁЛКО, Г. Б. ПОЛЯК * АРИФМЕТИКА 3 НЧЕ КЛАСС ӨЧЕН

РСФСР ПЕДАГОГИЯ ФӘННӘРЕ АКАДЕМИЯСЕ

А. С. ПЧЁЛКО һәм Г. Б. ПОЛЯК

АРИФМЕТИКА

БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПНЕҢ
3 нче КЛАССЫ ӨЧЕН
ДӘРЕСЛЕК

ЯНАДАН ЭШЛӘНГӘН АЛТЫНЧЫ БАСМАСЫ

Тәрҗемәне Татарстан Мәгариф министрлыгы раслады

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1961

ЭЧТӘЛЕК

Йөз 3

Икенче класста үткәннәрне кабатлау 3

Мең 13

1000 эчендә нумерация 13
Километр 14
Кушу 16
Алу 22
Берурынлы санга тапкырлау 29
Берурынлы санга бүлү 35
Барлык гамәлләргә мәсьәләләр һәм мисаллар 43

Күбурынлы саннар 49

Күбурынлы саннар нумерациясе 49
Озынлык үлчәү берәмлекләре 58
Авырлык үлчәү берәмлекләре 61
Күбурынлы саннарны кушу 64
Күбурынлы саннарны алу 69
Мәсьәләләр 76
Күбурынлы саннарны тапкырлау 78
Күбурынлы саннарны бүлү 94
Кара-каршы хәрәкәткә мәсьәләләр 113

Кабатлау 117

Гади вакланмалар 122

Вакланмаларның ясалуы 122
Санның бер яки берничә өлешен табуга мәсьәләләр . .125

Вакыт үлчәү берәмлекләре 128

Геометрик материал 133

Кабатлау 146

Кызыклы мәсьәләләр 163
Таблицалар 165
Җаваплар 166

Й ө з.

2 НЧЕ КЛАССТА ҮТКӘННӘРНЕ КАБАТЛАУ.

Кушу һәм алу.

1. Класста 19 ир бала, 20 кыз бала укый. Класста барлыгы ничә укучы бар?

2. Безнең класста ... ир бала, ... кыз бала укый. Безнең класста барлыгы ничә укучы?

3.

32 + 60	52 + 7	70 + 25	46 + 30
52 + 36	28 + 4	36 + 36	23 + 38
28 + 32	37 + 6	47 + 24	37 + 59
13 + 57	75 + 9	56 + 18	16 + 75

4. Балалар ике тапкыр урманга җиләккә барганнар. Алар беренче барганда 18 стакан җиләк җыйганнар, икенче барганда 12 стакан артыграк җиләк җыеп кайтканнар. Балалар барлыгы ничә стакан җиләк җыйганнар?

5. Энесе апасы белән урманга гөмбә җыярга барган. Энесе 26 ак гөмбә тапкан, апасы 6 гөмбә артыграк тапкан. Алар икесе берга ничә ак гөмбә тапканнар?

6. 1) Бер укучы җәй буена 9 китап укыган, икенчесе, беренче укучыга караганда, 3 китап артыграк, өченчесе икенчесеннән 2 китап артыграк укыган. Өченче укучы ничә китап укыган?

2) Үз классыгыздагы укучыларның җәй буена ничә китап укулары турында мәсьәлә төзегез.

7.

42 + 26	25 + 8	28 + 28	68 + 25
36 + 54	6 + 49	47 + 47	24 + 57
17 + 63	8 + 67	39 + 39	19 + 66

8. Хезмәт дәресләре өчен 75 табак кызыл һәм яшел кәгазь хәзерләгәннәр. Шуның 40 табагы кызыл кәгазь. Яшел кәгазь ничә табак булган?

9. 56 — 35	50 — 4	84 — 50	75 — 30
40 — 24	42 — 6	56 — 28	63 — 35
80 — 46	71 — 5	31 — 14	92 — 78
90 — 58	83 — 7	72 — 47	74 — 46

10. Мәктәпнең яшелчә бакчасында бер түтәлдән 18 *кг*, икенчесеннән 4 *кг* кимрәк кишер җыеп алдылар. Ике түтәлдән барлыгы ничә килограмм кишер җыеп алдылар?

11. 1) Мәктәп күргәзмәсенә 2 кабак куелган. Аларның берсе 25 *кг* авырлыкта, ә икенчесенең авырлыгы 3 *кг* га кимрәк. 2 кабак бергә ничә килограмм булган?

2) Үзегезнең мәктәп күргәзмәсенә куелган уңышларыгыз турында мәсьәлә төзегез.

12. Берсе 4 *см*, икенчесе 12 *см* озынлыкта 2 туры сызык сызыгыз. Икенче сызык беренчесеннән ничә сантиметрга озынрак? Беренче сызык икенчесеннән ничә сантиметрга кыскарак?

13. Хор түгәрәгендә 25, физкультура түгәрәгендә 20 укучы бар иде. Хор түгәрәгенә тагын 5 укучы, физкультура түгәрәгенә 17 укучы язылды. Хәзер физкультура түгәрәгендә, хор түгәрәгенә караганда, ничә укучы артыграк?

14. Вәли 15 өрәңге яфрагы, 9 имән яфрагы киптерде, Ләлә 13 өрәңге яфрагы, 14 имән яфрагы киптерде. Вәли ничә яфрак кимрәк киптергән?

15. 37 — 20	40 — 28	34 — 17	28 + 59
48 — 35	80 — 57	56 — 18	94 — 68
79 — 54	32 — 8	63 — 45	22 + 49
83 — 63	61 — 5	92 — 86	75 — 66

16. Нинди ике санны кушкач 50 килеп чыга?

17. Паркта 50 төп каен үсә иде. Көз көне тагын утырткканнан соң аларның саны 70 кә җитте. Көз көне ничә төп каен утыртылган?.

18. 1) Узган ел мәктәптә 28 чүлмәк гөл үсә иде, быел алар 60 булды. Бер елда ничә чүлмәк гөл арткан?

2) Үз мәктәбегездәге гөлләр турында мәсьәлә төзегез.

19. Укучылар алмагач утырттылар. 30 төп алмагач утырткач, аларның тагын 12 төп утыртасылары калды. Барлыгы ничә төп алмагач утыртырга кирәк булган?

20. Класс китапханәсеннән 36 китап биргәч, тагын 60 китап калды. Китапханәдә барлыгы ничә китап булган?

21. Пионерлар бер инвалидка утыннарын сарайга ташырга булыштылар. 27 утын агачы китергәч, тагын 18 агач китерәселәре калды. Барлыгы ничә утын агачы китерергә кирәк булган?

22. 68 — 30	26 + 48 — 34	70 — 32 + 62
57 + 40	17 + 39 — 28	64 — 20 + 46
28 — 28	54 + 38 — 65	50 — 18 — 30

23. Кушкач һәрберсендә дә 75 саны килеп чыгарлык итеп, кушуга 4 мисал төзегез.

Тапкырлау һәм бүлү.

24. 6 пионер 4 әр кролик тәрбияләп үстерде. Бу пионерлар барлыгы ничә кролик үстерделәр?

25. Бакчадан 4 *кг* кура җиләге һәм аңа караганда 6 тапкыр күбрәк карлыган җыеп алдылар. Бакчадан ничә килограмм карлыган җыеп алдылар?

26. Кушуны тапкырлау белән алмаштырыгыз:

$$3+3+3+3+3+3+3+3=$$
$$4+4+4+4+4+4+4=$$

27. Укучылар 3 рәткә, һәрберсенә тигез санда итеп, 24 төп каен утырттылар. Һәр рәткә ничә төп каен утыртылган?

28. 2×8	4×8	18 : 2	18 : 3	14 : 2
3×7	4×6	21 : 3	20 : 4	24 : 3
3×9	4×9	32 : 4	27 : 3	28 : 4
3×8	4×7	40 : 4	24 : 4	36 : 4

29. Түгәрәкнең яртысын күрсәтегез; түгәрәкнең дүртенче өлешен; түгәрәкнең сигезенче өлешен күрсәтегез.



30. Өстәлдә 12 карандаш бар. Бер укучыга шушы карандашларның өченче өлешен алырга куштылар. Ул ничә карандаш алырга тиеш?

31. Таган ясар өчен 24 *м* озынлыктагы бауның дүртенче өлешен кисеп алдылар. Ничә метр бау калды?

32. Бер кисәктә 27 *м* материя бар иде. Сатып алучыларның берсенә барлык материянең өченче өлешен, икенчесенә 10 *м* материя саттылар. Кисәктә ничә метр материя калды?

33. Дәфтәргә һәрберсе 12 шәр шакмаклы 3 турыпочмаклык сызарга. Беренче турыпочмаклыкны, рәсемдә күрсәтелгәнчә, 2 тигез өлешкә бүләргә. Икенчесен 3 тигез өлешкә, ә өченчесен 4 тигез өлешкә бүләргә.



34.

$4 \times 6 : 3$	$(15+17):4$	$(41-17):3$
$21 : 3 \times 2$	$(16+8):3$	$(40-12):4$
$36 : 4 \times 2$	$(17+19):4$	$(45-27):3$

35.

Кайсы һәм күпмегә зуррак:	Кайсы һәм күпмегә кечерәк:
6×6 яки 5×7?	6×9 яки 7×8?
7×6 яки 5×9?	6×8 яки 7×7?
6×5 яки 5×8?	6×7 яки 7×9?

36.

$35:5$	$48:6$	$42:6$	$45:5$	$42:7$	$63:7$
$30:6$	$35:7$	$30:5$	$49:7$	$40:5$	$54:6$

37. Бер юлга 2, икенче юлга 5 тапкыр артыграк, өченче юлга, беренчегә караганда, 5 кә артыграк итеп түгәрәкләр сызарга.

38. 1) Нинди сан 5 тән 7 тапкыр зуррак? 5 тән 7 гә зуррак?

2) Нинди сан 30 дан 6 тапкыр кечерәк? 30 дан 6 га кечерәк?

39. Укучылар ике зур карбыз үстерделәр. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә кечерәк карбыз, икенче тәлинкәсенә 5 әр *кг* лы 2 гер куйгач, үлчәү тәлинкәләре тигезләнде. Икенче карбыз беренчесеннән 1 *кг* га авыррак. Ике карбызның авырлыгы күпме булган?

40. Балалар мәктәп бакчасында беренче җыюда 5 *кг* җир җиләге, икенче җыюда, беренчесендәгегә караганда, 8 тапкыр

артыграк, өченчесендә, икенче җыюдагыга караганда, 4 *кг* артыграк җир җиләге җыйдылар. Балалар барлыгы күпме җир җиләге җыйдылар?

41. 1) Бер туры сызыкның озынлыгын үлчәгез. Дәфтәрегезгә шундый ук озынлыкта икенче бер туры сызык сызыгыз.

2) Беренчесенә караганда 5 тапкыр кыскарак булган икенче бер сызык сызыгыз.

42. 30 : 6 × 7 (18 + 17) : 5 (66 — 17) : 7
35 : 5 × 8 (19 + 23) : 7 (64 — 16) : 6
42 : 7 × 9 (26 + 28) : 6 (73 — 28) : 5

43. Кайсы зуррак һәм ничә тапкыр зуррак?

8 × 5 яки 5 × 4? 8 × 7 яки 7 × 4?
9 × 5 яки 5 × 3? 9 × 7 яки 3 × 7?

44. 1) Нинди сан 9 дан 5 тапкыр зуррак? 9 дан 5 кә зуррак?

2) Нинди сан 90 нан 9 тапкыр кечерәк? 90 нан 9 га кечерәк?

45. 48 : 6	72 : 8	63 : 7	56 : 8	48 : 8	81 : 9
36 : 9	54 : 9	42 : 7	72 : 9	45 : 9	63 : 9
42 : 6	56 : 7	72 : 8	32 : 8	36 : 9	27 : 9

46. 32 *кг* кура җиләген һәм 27 *кг* чияне кәрзиннәргә бүлеп салганнар: кәрзиннәргә кура җиләген 8 әр *кг*, чияне 9 ар *кг* салганнар. Барлыгы ничә кәрзин кирәк булган?

47. Дәфтәрегезгә берсе 3 *см*, икенчесе 15 *см* озынлыкта 2 туры сызык сызыгыз. Икенче сызык беренчесеннән ничә тапкыр озынрак? Беренче сызык икенчесеннән ничә тапкыр кыскарак?

48. Бер алмагачтан 70 *кг*, икенчесеннән 10 *кг* алма җыйганнар.

Беренче алмагачтан, икенчесенә караганда, ничә килограмм алма артык җыйганнар?

Беренче алмагачтан, икенче алмагачка караганда, алманы ничә тапкыр артыграк җыйганнар?

49. Балалар дүрт чия агачыннан 9 ар *кг* чия һәм ике карлыган куагыннан 3 әр *кг* карлыган җыеп алдылар. Чияне, карлыганга караганда, ничә тапкыр артыграк җыйганнар?

50. Дәфтәрегезгә 9 ар шакмаклы 4 турыпочмаклык һәм 3 әр шакмаклы 2 турыпочмаклык сызыгыз. Исәпләгез: беренче турыпочмаклыкта, икенчесенә караганда, шакмаклар саны н и ч ә г ә артыграк?

Икенче турыпочмаклыкта, беренчесенә караганда, шакмаклар саны н и ч ә т а п к ы р кимрәк?

51. $48 : 8 \times 7$ $\quad (29 + 19) : 8$ $\quad (91 - 27) : 8$

$72 : 9 \times 8$ $\quad (25 + 29) : 9$ $\quad (84 - 28) : 7$

$63 : 7 \times 6$ $\quad (18 + 38) : 7$ $\quad (92 - 29) : 9$

52. Укучылар физкультура дәресендә һәр рәттә 18 әр булып ике рәткә тезелделәр. Ике рәттә барлыгы ничә укучы булды?

53. 15×3 $\quad 27 \times 3$ $\quad 29 \times 3$ $\quad 2 \times 18$ $\quad 6 \times 13$

17×5 $\quad 38 \times 2$ $\quad 47 \times 2$ $\quad 4 \times 19$ $\quad 3 \times 28$

16×6 $\quad 24 \times 4$ $\quad 25 \times 4$ $\quad 7 \times 13$ $\quad 5 \times 19$

54. 76 сумга метры 12 шәр сумнан 3 *м* сукно һәм 5 *м* йон материя сатып алганнар. Йон материянең бер метры ничә сум тора?

55. 3 кисәк сабын һәм 2 данә теш щеткасы өчен 85 тиен түләгәннәр. Сабынның бер кисәге 15 тиен булса, теш щеткасының берсе ничә тиен торыр?

56. 20 *м* материядән 3 хатын-кыз күлмәге һәм берничә алъяпкыч текteләр. Һәр күлмәккә 4 әр *м*, һәр алъяпкычка 2 шәр *м* материя китте. Ничә алъяпкыч тектеләр?

57. Балалар йортындагы балалар өчен 56 *м* материядән 12 данә кызлар күлмәге һәм берничә малайлар күлмәге тектеләр. Кызлар күлмәгенең һәрберсенә 3 әр *м*, малайлар күлмәгенә 2 шәр *м* материя китте. Малайлар өчен ничә күлмәк тегелгән?

58. $15 \times 5 + 17$ $\quad 2 \times 28 - 39$ $\quad 14 \times 4 : 8$

$19 \times 3 + 38$ $\quad 5 \times 19 - 78$ $\quad 24 \times 3 : 9$

$14 \times 4 + 29$ $\quad 3 \times 28 - 36$ $\quad 18 \times 3 : 6$

59. Укучылар урамның һәр ягына, тигез санда итеп, барлыгы 78 төп акация утырттылар. Урамның һәрбер ягына ничәшәр төп акация утыртылган?

60.	56 : 2	64 : 4	84 : 6	81 : 3	72 : 6
	72 : 3	92 : 4	91 : 7	98 : 7	52 : 4
	51 : 3	80 : 5	96 : 8	85 : 5	84 : 7
	87 : 3	95 : 5	90 : 6	78 : 6	57 : 3

61. 5 *м* материя өчен 60 сум түләделәр. Бу материяне 3 *м* ы ничә сум торыр?

62. 3 *м* тасма өчен 39 тиен түләгәннәр. Шундый 5 *м* тасма өчен күпме түләргә кирәк?

63. Мәктәпне ремонтлау өчен бертигез зурлыктагы 3 ящик кадак сатып алганнар. Кадакларның барлыгы 96 *кг* булган. Ремонтка 2 ящик кадак тотылган. Ремонт өчен ничә килограмм кадак киткән?

64. Дәфтәрегезгә 18 шакмаклы бер турыпочмаклык сызыгыз. Аны 6 тигез өлешкә бүлегез. 4 өлештә ничә шакмак барлыгын исәпләгез.

65.	70 : 2	54 : 3	56 : 4	85 : 5	(47 + 29) : 4
	48 : 3	96 : 2	87 : 3	84 : 6	(80 − 26) : 3
	60 : 5	95 : 5	68 : 4	91 : 7	(91 − 13) : 6

66. Велосипедта йөрүче сәгатькә 15 *км* тизлек белән барса, 45 *км* юлны ничә сәгатьтә үтәр?

67.	50 : 25	56 : 14	70 : 14	78 : 13	84 : 12
	51 : 17	84 : 28	92 : 23	72 : 24	96 : 16
	72 : 36	76 : 19	85 : 17	90 : 15	91 : 13

68. 20 табак кәгазьдән бертөрле 5 данә кесә дәфтәре тектеләр. 36 табак кәгазьдән шундый ничә дәфтәр тегәргә мөмкин?

69. 75 тиенгә 25 төймә сатып алганнар. 90 тиенгә ничә төймә алып булыр?

70. 28 *м* ситсыдан 14 алъяпкыч теккәннәр. 50 *м* ситсыдан шундый ничә алъяпкыч тегәргә мөмкин?

71.	36 : 18	48 : 16	72 : 18	12 × 5 : 15
	52 : 13	74 : 37	90 : 15	24 × 4 : 16
	42 : 14	60 : 12	81 : 27	12 × 6 : 36

72. Юннатлар 36 кроликны, тигез итеп, 9 читлеккә урнаштырдылар. Шундый 6 читлеккә ничә кролик урнашыр?

73. Балалар 40 данә кишер китергәннәр һәм аны, һәрберсенә тигез итеп, 8 кроликка бүлеп биргәннәр. Әгәр шул ук норма белән бирелсә, 50 данә кишер ничә кроликка житәр?

74. Бер малай, һәр көн бертигез укып, 3 көндә китаптан 36 бит укыган. Китапта тагын 60 бит бар. Әгәр бу малай һәр көн шул ук тизлек белән укыса, калганын ничә көндә укып чыгар?

75. Бер кыз, һәр көн бертигез укып, 2 көнгә 30 бит укыган. Әгәр ул һәр көн шулкадәр укыса, 5 көндә ничә бит укыр?

76.	68 : 4	48 : 3	60 : 12	45 : 15	96 : 2 : 16
	84 : 3	76 : 2	70 : 14	80 : 16	72 : 2 : 18
	92 : 2	90 : 5	91 : 13	54 : 18	84 : 2 : 14
	65 : 5	78 : 6	68 : 17	57 : 19	92 : 2 : 23

Барлык гамәлләргә мәсьәләләр һәм мисаллар.

77. Нинди ике санны кушкач 74 саны килеп чыга?

Нинди ике санны тапкырлагач 48, 72, 54 саннары килеп чыга?

78. Өч малай балык тотканнар. Аларның берсе 16 балык, икенчесе, беренчесенә караганда, 5 балык кимрәк, ә өченчесе, икенче малайга караганда, 2 тапкыр артыграк балык тоткан. Малайлар барысы бергә ничә балык тотканнар?



79. Аяк киемен сөртер өчен рәшәткә ясарга 3 борыс һәм 7 планка киткән. Шундый 4 рәшәткә ясар өчен, ничә борыс һәм ничә планка кирәк булыр?

80. 1) Пионерлар паркка агачлар утыртканнар. 45 төп агач утырткач, вожатый: „Утырткан агачларыбыз саныннан өч тапкыр кимрәк агач утыртасыбыз калды", — дигән. Алар барысы ничә төп агач утыртырга тиеш булганнар?

2) Үз мәктәбегездәге укучыларның агач һәм куаклар утыртулары турында мәсьәлә төзегез.



81. 1) Рәсемдә күрсәтелгәнчә китап шүрлеге ясар өчен, ничә метр такта кирәк булыр? (Ян такталар һәм шүрлекләр һәр берсе берәр тактадан тора.)

2) Шундый шүрлек ясар өчен, озынлыгы 5 әр метрлы ничә такта кирәк булыр?

82. Мәктәп күргәзмәсе өчен өченче класстан 34 рәсем сайлап алдылар: 8 укучы 2 шәр һәм берничә укучы 3 әр рәсем бирде. Ничә укучы 3 әр рәсем биргән?

83. Укучыларга 36 рәт кишер утарга кирәк иде. Беренче сәгатьтә алар барлык рәтнең өченче өлешен, ә икенче сәгатьтә 14 рәт утадылар. Тагын ничә рәт кишер утыйсы калды?

84. 24 *м* материядән малайлар өчен 8 күлмәк тектеләр. 42 *м* материядән шундый ничә күлмәк тегәргә мөмкин?

85. 7 шкаф ясар өчен 28 *м* такта киткән. Шундый 18 шкаф ясар өчен ничә метр такта кирәк булыр?

86. Октябрятлар балалар бакчасындагы урта группадагы балалар өчен 16 уенчык, кечкенә группадагылар өчен, урта группадагыларга караганда, 2 тапкыр кимрәк, ә зурлар группасындагы балалар өчен, кечкенәләргә караганда, 12 уенчык артыграк ясадылар. Октябрятлар зурлар группасы өчен ничә уенчык ясаганнар?

87. Пионерлар балалар бакчасындагы урта группадагы балалар өчен 18 флагчык, кечкенә группадагылар өчен, урта группадагыларга караганда, 2 тапкыр кимрәк, ә зурлар группасындагы балалар өчен, кечкенәләргә караганда, 15 флагчык артыграк ясадылар. Пионерлар барлыгы ничә флагчык ясаганнар?

88. Бер укучы җәй көне 25 хезмәт көне, икенчесе 75 хезмәт көне эшләде. Икенче укучы, беренчесенә караганда, ничә хезмәт көне артыграк эшләгән? Беренче укучы, икенчегә караганда, хезмәт көнен ничә тапкыр кимрәк эшләгән?

89. Буяучы, һәр көн бертигез эшләп, 24 партаны 2 көндә буяп бетерде. Әгәр һәр көн шулай эшләсә, 5 көндә ул ничә парта буяр?

90. Столяр, һәр көн бертигез эшләп, 3 көндә 12 рам ясады. Әгәр ул, элеккегә караганда, көнгә бер рам артыграк ясаса, 30 рам ясар өчен ничә көн кирәк булыр?

91. Пионерлар лагере өчен укучылар 50 *м* полотнодан 15 җәймә, 20 мендәр тышы тектеләр. Һәр мендәр тышына 1 *м* полотно китте. Һәр җәймәгә ничә метр полотно киткән?

92. Мәктәп тәрәзәләрен сөртергә кирәк: мәктәп бинасының өч ягында 12 шәр тәрәзә, дүртенче якта тәрәзәләр саны, башка якларга караганда, 2 тапкыр кимрәк. Мәктәптә барлыгы ничә тәрәзә сөртергә кирәк?

93.

$36 + 28 - 15$	$54 : 9 \times 8$	$16 \times 6 : 4$
$80 - 57 + 28$	$84 : 6 \times 7$	$81 : 27 \times 19$
$91 - 72 + 48$	$92 : 23 \times 18$	$68 : 17 \times 16$

94. Түбәндәге нокталар урынына тиешле гамәлләрнең билгеләрен куярга. (Мисалларны дәфтәрдә чишегез.)

32...8 = 24	36...18 = 2	28...4...5 = 12
48...6 = 54	16...4 = 64	5...8...4 = 36
7...8 = 56	45...3 = 15	36...3...5 = 60

Мең.

1000 эчендә нумерация.

95. Бер йөздән башлап меңгә кадәр һәм кирегә таба йөзәрләп санагыз.

Бер йөздән башлап ике йөзгә кадәр дистәләп санагыз.

96. 1) 3 йөз 2 дистә һәм 5 берәмлектән торган санны әйтегез;

2) 5 йөз 7 дистә һәм 8 берәмлектән торган санны әйтегез.

3) 7 йөз һәм 3 дистәдән торган санны әйтегез.

4) 1 йөз 1 дистә һәм 1 берәмлектән торган санны әйтегез.

97. Түбәндәге саннарда ничә йөз, ничә дистә һәм ничә берәмлек бар: 563; 796; 804; 240; 609; 800?

98. Шундый таблица төзегез:

Йөзләр	Дистәләр	Берәмлекләр

99. 4 ле цифр язылган карточканы алып, түбәндәге урыннарга куегыз:

1) таблицада уңнан беренче урынга (берәмлекләр турысына) куйгач, нинди санны белдерә?

2) уңнан икенче урынга (дистәләр турысына) куйгач, нинди санны белдерә?

3) уңнан өченче урынга (йөзләр турысына) куйгач, нинди санны белдерә?

100. Уңнан беренче урынга 6 лы цифр язылган карточканы куегыз, икенче урынга — 9 лы, өченче урынга 5 ле цифр язылган карточкаларны куегыз. Нинди сан килеп чыгар?

101. Уңнан беренче урынга 8 ле цифр, икенче урынга 4 ле цифр, өченче урынга 2 ле цифр язылган карточкаларны куегыз. Нинди сан килеп чыгар?

102. Таблицада түбәндәге саннарны цифрлар белән билгеләгез: 7 йөз, 3 дистә һәм 6 берәмлек; 9 йөз, 1 дистә һәм 8 берәмлек, 3 йөз һәм 8 дистә.

103. Берәмлекләр уңнан ничәнче урынга язылалар? Дистәләр? Йөзләр?

104. Бу саннарны укыгыз: 725; 863; 914; 706; 905; 340; 560; 900; 1 000; 222; 666; 111; 101; 110; 999.

105. Түбәндәге саннарны цифрлар белән языгыз: җиде йөз; дүрт йөз туксан; өч йөз дүрт; бер йөз сигез; дүрт йөз илле алты; җиде йөз җитмеш җиде.

106. Түбәндәге саннарда ничә йөз, ничә дистә һәм ничә берәмлек бар: 758; 411; 540; 602; 304?

107. 4 йөз; 52 дистә; 6 йөз һәм 5 берәмлек; 73 дистә һәм 8 берәмлектән торган саннарны языгыз.

108. Түбәндәге саннарда барлыгы ничә берәмлек: 63 дистәдә; 85 дистәдә; 9 йөз һәм 3 берәмлектә?

109. 3 *м* 5 *дм* 8 *см* да ничә сантиметр бар? 6 *м* 4 *дм* 1 *см* да? 4 *м* 5 *см* да? 4 *м* 9 *дм* да? 7 *м* 58 *см* да ничә сантиметр?

110. 1) 297 дән 304 кә кадәр; 898 дән 905 кә кадәр тәртип буенча санагыз һәм шул саннарны языгыз.

2) 704 тән 697 гә кадәр, 502 дән 496 га кадәр берәмләп кирегә санагыз һәм саннарны языгыз.

111. 599 дан соң нинди сан килә? 999 дан соң?

112. Иң кечкенә һәм иң зур икеурынлы сан языгыз; иң кечкенә һәм иң зур өчурынлы сан языгыз.

Километр.

Ераклык километр белән үлчәнә.

Бер километрда 1 000 метр.

„Километр“ сүзе сан янында килгәндә кыскача *км* (нокта куймыйча) дип язына. Мәсәлән: 5 *км*, 200 *км*, 250 *км*.

1 *км* = 1 000 *м*.



113. Укып чыгыгыз: 1)

5 *км*	75 *м*	7 *дм*	5 *см*
68 *км*	96 *м*	4 *дм*	9 *см*
926 *км*	50 *м*	1 *дм*	2 *см*

2) Мәскәүдән Ленинградка кадәр 651 *км.*

114. Җөмләләрне тутырып языгыз: 1) Безнең авылдан район үзәгенә кадәр ... *км.*

2) Безнең авылдан шәһәргә кадәр ... *км.*

3) Безнең шәһәр (авыл) дән Мәскәүгә кадәр ... *км.*

115. 100 *м* араны үлчәү өчен 10 *м* лы бауны ничә тапкыр салырга кирәк? 1 *км* ны 100 *м* лы бау белән ничә тапкыр үлчәргә кирәк?

116. Мәктәптән 1 *км* ераклыкта булган урын яки әйберләрне әйтегез.

117. Сезнең өегез мәктәптән нинди ераклыкта?

118. Җәяү баручы 1 сәгатькә 5 *км* юл үтә,

атта баручы	—	10 *км*	„ „
велосипедта баручы	—	16 *км*	„ „
автомашинада баручы	—	100 *км*	„ „
поездда баручы	—	50 *км*	„ „
самолётта очучы	—	400 *км*	„ „

Реактив самолётта очучы — 1 000 *км* оча ала.

Бу саннарны шушы үрнәк буенча таблицага языгыз:

Хәрәкәт төрләре	1 сәгатьтә үтү тизлеге
Җәяүле һ. б. ш.	5 *км*

119. Төзелгән таблицадан файдаланып, түбәндәге мәсьәләләрне чишегез:

1) 3 сәгатьтә җәяүле ничә *км* юл үтә алыр? 4 сәгатьтә? 5 сәгатьтә?

2) Велосипедта баручы 2, 3, 4, 5 сәгать вакыт эчендә ничәшәр километр юл үтә ала? Атта баручы 2, 3, 4, 5, 6 сәгатьтә? Автомашинада 3, 4, 5, 8 сәгатьтә ничәшәр километр юл үтә алыр?

Кушу.

Телдән кушу.

120. 1 000 гә кадәр 100 гә 100 әрләп куша барыгыз.

121.

300 + 300	500 + 500	700 + 200	100 + 700
400 + 400	100 + 600	300 + 500	200 + 800
200 + 200	600 + 300	200 + 600	400 + 500

122. Түбәндәге саннар рәтен дәвам иттерегез:

100   110   120   130...   (300 гә кадәр).

123. Чаңгы станциясендә 120 пар чаңгы бар иде. Кыш башында тагын 60 пар чаңгы сатып алдылар. Станциядә ничә пар чаңгы булды?

124.

100 + 70	160 + 10	610 + 50	930 + 40
200 + 40	440 + 20	720 + 60	810 + 70
300 + 80	720 + 30	540 + 50	420 + 50

125. Узган ел колхозда 640 баш сарык бар иде, быел аларның саны 120 башка артты. Быел колхозда барлыгы ничә баш сарык бар?

126.

160 + 110	230 + 230	350 + 410	720 + 260
130 + 150	460 + 420	570 + 120	130 + 850
120 + 170	340 + 330	450 + 230	240 + 630

127. Жәй көне пионерлар лагеренда беренче сменада 110 бала, икенче сменада 20 гә артыграк бала ял итте. Лагерьда ике сменада барлыгы ничә бала ял иткән?

128. Укучыларның бер бригадасы колхозда 420 хезмәт көне эшләде, икенче бригада, беренчегә караганда, 40 хезмәт көне артыграк, өченчесе, икенчегә караганда, 30 хезмәт көне артыграк эшләде. Өченче бригада ничә хезмәт көне эшләгән?

129. Укучылар чәчәк орлыклары хәзерләделәр: орлыкларны 4 пакетка 25 әр *г* һәм өч пакетка 30 ар *г* итеп салдылар. Укучылар барлыгы ничә грамм чәчәк орлыгы хәзерләгәннәр?

130.

$150+30$	$140+110$	$210+(14\times 3+8)$
$360+20$	$360+320$	$140+(51:3+13)$
$510+80$	$630+250$	$530+(19\times 4-46)$
$820+50$	$120+870$	$650+(46\times 2-52)$

131. Түбәндәге саннар рәтен дәвам иттерегез:

1) 100 150 200 250 ...(800 гә кадәр)
2) 800 820 840 860 ...(1000 гә кадәр)

132. Үткән ел колхозда 150 баш бозау бар иде, быел 50 башка артты. Быел колхозда ничә баш бозау бар?

133.

$280+20$	$590+10$	$330+70$	$620+80$
$360+40$	$750+50$	$810+90$	$540+60$
$470+30$	$680+20$	$440+60$	$950+50$

134. Мәктәп бинасы төзелешенә башта 650 табак, аннан тагын 150 табак калай китерделәр. Төзелешкә барлыгы ничә табак калай китергәннәр?

135.

$150+150$	$270+130$	$280+320$	$630+170$
$180+120$	$750+150$	$490+210$	$420+380$
$160+140$	$340+360$	$270+430$	$110+590$

136. Шәһәрдә 180 магазин бар иде. Бер елдан аларның саны 20 гә, аннан тагын 30 га артты. Шәһәрдә барлыгы ничә магазин булды?

137. 1) Мәктәпнең яшелчә бакчасыннан балалар беренче тапкыр һәрберсендә 20 шәр *кг* булган 3 кәрзин помидор, икенче тапкыр, беренчегә караганда, 40 *кг* артыграк помидор җыйганнар. Балалар ике җыюда ничә килограмм помидор җыйганнар?

2) Мәктәпнең яшелчә бакчасындагы үз эшләрегез турында мәсьәлә төзегез.

138.

$110+90$	$250+150$	$130+(48:16+67)$
$430+70$	$370+130$	$210+(68:17+86)$
$720+80$	$680+220$	$390+(72:\ 3-14)$
$840+60$	$190+710$	$580+(74:\ 2-17)$

139. Мәктәптә 80 пионер бар иде. Тагын 30 укучыны пионерга алганнар. Мәктәптә барлыгы ничә пионер булды?

140.

$50+60$	$60+70$	$180+40$	$570+60$
$40+80$	$50+90$	$290+50$	$690+80$
$20+90$	$80+80$	$460+60$	$740+90$

141. Колхоздан Мәскәүгә йөк автомобиле белән фруктылар илткәннәр. 180 *км* юл үткәч, тагын 140 *км* барасы калган. Колхоз Мәскәүдән нинди ераклыкта булган?

142.

$160+160$	$240+170$	$350+280$	$180+680$
$180+180$	$350+190$	$230+490$	$260+570$
$170+150$	$560+180$	$540+270$	$190+630$

143. Мәктәп салу өчен дүрт зур йөк автомобиленә 20 шәрне салып һәм 3 кечкенә йөк автомобиленә 10 арны салып бүрәнәләр китерделәр. Төзелешкә барлыгы ничә бүрәнә китерелгән?

144. 740 *кг* алманы саткач, колхоз ларёгында тагын 4 ящик алма калды. Әгәр һәр ящикта 20 шәр *кг* алма булса, сата башлаганчы ларёкта ничә килограмм алма булган?

145. 850 *кг* балны саткач, магазинда тагын 45 әр *кг* тутырылган 2 бидон бал калды. Сата башлаганчы магазинда ничә килограмм бал булган?

146.

$80+80$	$140+180$	$230+\ 50+\ 70$
$50+90$	$370+370$	$460+\ 30+\ 80$
$140+70$	$250+490$	$120+140+160$
$290+60$	$560+280$	$350+220+150$

147. $99+56=(100+56)-1=156-1=155$

$99+47$	$98+75$	$43+99$	$54+38$
$99+63$	$98+37$	$62+98$	$72+19$
$99+84$	$98+65$	$85+99$	$69+25$

148. Бер кыз китапның 39 битен укыган, аның тагын укылганнан 22 бит артыграк укыйсы калган. Китапта барлыгы ничә бит булган?

149. Колхозчы, үзенә 98 *кг* алма калдырып, 65 *кг* алмасын сатты. Колхозчының барлыгы ничә килограмм алмасы булган?

150. 1) Бу кызыклы квадратның һәрбер рәтендәге саннарны кушкач, нәтиҗәдә бер үк сан килеп чыга. Моның шулай булуын тикшерегез.

2) Кызыклы квадраттагы һәрбер санга 10 ны кушыгыз. Килеп чыккан саннар белән кызыклы квадратны дәфтәрегезгә языгыз. Телдән исәпләгез, һәрбер рәттәге саннарны кушкач ничә килеп чыга.

10	60	50
80	40	0
30	20	70

3) Шундый берничә кызыклы квадрат төзегез һәм теләсә кайсы рәттәге санны кушудан нинди сан килеп чыгуын тикшерегез.

Язып кушу.

151. Укучыларның бер бригадасы 145 *кг*, икенчесе 134 *кг* помидор җыйды. Ике бригада бергә барлыгы ничә килограмм помидор җыйган?

Бу мәсьәлә кушу юлы белән чишелә:

$$\begin{array}{rl} & 145 \text{ кг} — \text{кушылучы} \\ + & 134 \text{ кг} — \text{кушылучы} \\ \hline & 279 \text{ кг} — \text{сумма.} \end{array}$$

Кушыла торган саннар к у ш ы л у ч ы л а р дип аталалар.

Кушкач килеп чыккан сан с у м м а дип атала.

Кушу тамгасы + (плюс).

152. Кушу гамәлен эшләгез:

$$\begin{array}{r} 231 \\ +628 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 372 \\ +523 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 423 \\ +456 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 73 \\ +624 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 836 \\ +52 \\ \hline \end{array}$$

153. (Т е л д ә н.) $5+0$ $0+3$ $0+7$ $0+0$

$8+0$ $0+9$ $4+0$ $0+1$

154. Бер кушылучы 528, икенчесе 340. Бу саннарның суммасын табарга.

155.

$$\begin{array}{r} 235 \\ +420 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 340 \\ +534 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 703 \\ +205 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 803 \\ +66 \\ \hline \end{array} \quad \begin{array}{r} 90 \\ +702 \\ \hline \end{array}$$

156. Аучылар артеле сентябрь аенда 320 тиен, октябрьда, сентябрьгә караганда, 136 тиен артыграк һәм ноябрьда, октябрьга караганда, 140 тиен артыграк ауладылар. Аучылар ноябрь аенда ничә тиен аулаганнар?

157. Балалар мәктәп бакчасында беренче көнне 110 *кг*, икенче көнне аннан 48 *кг* артыграк алма җыйдылар. Балалар ике көндә ничә килограмм алма җыеп алганнар?

158. $\begin{array}{r} 732 \\ +\,163 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 431 \\ +\,506 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 304 \\ +\,573 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 635 \\ +\,54 \\ \hline \end{array}$ $\quad$ $\begin{array}{r} 42 \\ +\,856 \\ \hline \end{array}$

159. $372+415 \qquad 304+505 \qquad 36+652 \qquad 84:14+0$

$140+635 \qquad 236+52 \qquad 70+804 \qquad 72:18+0$

160. (Телдән.)

$7+6+5 \qquad 80:16+9 \qquad 72:12+0$

$3+9+7 \qquad 78:26+8 \qquad 60:15+0$

$9+8+4 \qquad 84:14+7 \qquad 78:39+0$

161. $428+2 \qquad 748+32 \qquad 204+76 \qquad 957+33$

$386+4 \qquad 536+54 \qquad 863+27 \qquad 609+71$

162. Магазин беренче көнне 235 карандаш, икенче көнне 245 карандаш сатты. Ике көндә ничә карандаш сатылган?



163. $165+125 \qquad 737+103 \qquad 125+137 \qquad 435+209$

$156+624 \qquad 401+509 \qquad 244+328 \qquad 308+507$

$312+268 \qquad 306+484 \qquad 536+345 \qquad 404+78$

164. Ике малай юлның ике башыннан бер-берсенә каршы килә. Очрашканчы бер малай 135 *м*, икенчесе 145 *м* юл үткән. Бу юл нинди озынлыкта булган?



165. Ике шәһәрдән бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан. Очрашканга кадәр беренче поезд 215 *км*, икенчесе беренче поездан 10 *км* артыграк юл үткән. Шәһәрләр арасындагы ераклыкны табарга. (Мәсьәләгә сызым сызыгыз.)

166.

432 + 9	104 + 769	367 + 526	76 : 19 + 8
218 + 5	409 + 306	504 + 229	98 : 14 + 5
349 + 37	625 + 367	208 + 66	78 : 26 + 0

167. Китапханә өчен беренче тапкыр 155 китап, икенче тапкыр 72 китап артыграк сатып алынган. Икенче тапкыр ничә китап сатып алынган?

168.

254 + 73	760 + 194	456 + 253	516 + 390
362 + 84	540 + 280	372 + 437	380 + 420
186 + 72	325 + 490	83 + 765	470 + 389

169. Колхозчы апа метрын 12 сумнан 6 *м* материя сатып алган. Шуннан соң аның тагын 55 сум акчасы калган. Материя сатып алганчы аның ничә сум акчасы булган?

170. Укучы китапны көнгә 36 шар биттән 2 көн укыгач, тагын 140 бит укыйсы калган. Китапта барлыгы ничә бит булган?

171. Бакчада 3 рәткә 30 ар төп алмагач һәм 2 рәткә 28 әр төп чия утырттылар. Бакчага барлыгы ничә төп агач утыртылган?

172.

465 + 82	495 + 410	350 + 594	65 : 13 × 17
590 + 94	357 + 482	82 + 757	81 : 27 × 18
275 + 34	276 + 693	93 + 815	68 : 17 × 23

173. Комсомоллар паркка 135 төп каен һәм 85 төп тополь утырттылар. Комсомоллар барлыгы ничә төп агач утыртканнар?

174.

195 + 68	635 + 187	279 + 328	146 + 256
247 + 79	756 + 156	358 + 162	609 + 196
389 + 56	435 + 365	239 + 275	726 + 87
729 + 87	228 + 378	187 + 475	538 + 98

175. Туристлар 185 *км* җәяү, 118 *км* автобуста һәм 250 *км* пароходта бардылар. Туристлар үткән юлның озынлыгын исәпләгез.

176.

385 + 457 + 84	245 + 555 + 132	37 + 293 + 408
276 + 248 + 76	386 + 474 + 65	638 + 66 + 273
109 + 256 + 178	270 + 386 + 94	458 + 84 + 158

177. Самат әтисенә җиләк-җимеш куаклары төбен йомшартырга булышты. Әтисе 76 куак төбе, Самат, әтисенә караганда, ике тапкыр кимрәк куак төбе йомшартты. Тагын 112 куак төбен йомшартасы калды. Аларга барлыгы ничә куак төбе йомшартырга кирәк булган?

178. Фәридә әбисенә җир җиләге утыртырга булышты. Әбисе 96 төп, Фәридә әбисеннән өч тапкыр кимрәк утыртты. Аларның тагын 118 төп җиләк утыртасылары калды. Барлыгы ничә төп җиләк утыртырга кирәк булган?

179. Комсомоллар урман чистартканда бер участоктан 98 агач, икенче участоктан ике тапкыр кимрәк, өченче участоктан, беренчегә караганда, 156 агач артыграк кискәннәр. Өч участоктан барлыгы ничә агач кискәннәр?

180.	276 + 389	637 + 293	172 + 628 + 102	76 : 4 + 37
	139 + 705	472 + 68	438 + 95 + 216	92 : 2 − 18
	378 + 496	54 + 786	590 + 276 + 34	81 : 3 − 19

Алу.

Телдән алу.

181. 0 калганчы, 1 000 нән 100 әрләп алырга.

182. Түбәндәге саннар рәтен дәвам иттерегез:

1) 1 000 800 600 ...
2) 180 160 140 ...

183.	600 − 300	700 − 200	500 − 400	1 000 − 300
	800 − 400	800 − 300	900 − 500	700 − 600

184. 1) Яшелчә бакчасының буе 180 *м*, иңе буеннан 60 *м* кимрәк. Яшелчә бакчасының иңе нинди озынлыкта?

2) Үз бакчагызның буе һәм иңе турында мәсьәлә төзегез.

185.	150 − 30	480 − 40	770 − 30	980 − 60
	190 − 50	690 − 20	560 − 50	890 − 70
	180 − 60	360 − 40	450 − 30	780 − 50

186. Мәктәп 350 данә шакмаклы дәфтәр һәм аннан 120 гә кимрәк санда юллы дәфтәр алды. Мәктәп ничә данә юллы дәфтәр алган?

187.	280 − 140	560 − 250	670 − 430	880 − 750
	270 − 110	480 − 320	950 − 720	790 − 560
	260 − 150	350 − 140	560 − 330	970 − 840

188. Физкультурачы 280 *м* араны йөзеп үтте. Аның тагын, йөзгәнгә караганда, 160 *м* кимрәк йөзәсе калды. Ул барлыгы ничә метр йөзәргә тиеш булган?

189. 1) Укучылар 180 төп кура җиләге, аңа караганда 50 төп кимрәк карлыган, карлыганга караганда 120 төп кимрәк крыжовник утырттылар. Укучылар барлыгы ничә төп җиләк-җимеш куагы утыртканнар?

2) Көз көне үзегезнең җиләк-җимеш куаклары утыртуыгыз турында мәсьәлә төзегез.

190.	160 — 40	250 — 110	350 — 140	15 × 6 : 2
	380 — 30	470 — 150	930 — 710	28 × 2 : 4
	760 — 50	860 — 430	490 — 370	18 × 4 : 3

191. 1) Сул квадрат эчендәге һәр саннан башта 40, аннан 60, 110, 130, 160 саннарын алырга.

2) уң яктагы квадрат эчендәге һәр саннан 230, 120, 140 саннарын алырга.



192. Шәһәрдә ике ел эчендә 200 йорт салынган, шулардан 80 йорт беренче елда салынган. Икенче елда ничә йорт салынган?

193.	200 — 50	400 — 40	800 — 20	700 — 70
	300 — 20	600 — 30	900 — 60	600 — 90
	500 — 10	300 — 50	500 — 80	900 — 40

194. Ике малай 500 *м* ераклыкка йөгерүдә ярышкан. Малайларның берсе йөгереп барып җиткәндә, икенчесе 480 *м* гына йөгерә алган. Икенче малай ничә метр артка калган?

195.	200 — 150	600 — 230	700 — 250	500 — 360
	300 — 120	400 — 180	900 — 110	800 — 620
	200 — 170	300 — 160	600 — 340	900 — 580

196. Алексиннан Берёзовкага кадәр 200 *км*, Берёзовкадан Ольховкага кадәр 50 *км* кимрәк. Алексиннан Ольховкага кадәр ничә километр?



197. Балыкчылар 300 *кг* эре балык, ана караганда 180 *кг* кимрәк вак балык тотканнар. Балыкчылар барлыгы ничә килограмм балык тотканнар?

198. Туристлар 3 көндә 700 *км* юл үткәннәр. Беренче көнне алар 200 *км*, икенче көнне, беренче көнгә караганда, 40 *км* артыграк юл үткәннәр. Туристлар өченче көнне ничә километр юл үткәннәр?

199.	200 — 80	300 — 120	(62 — 8) : 3
	500 — 30	600 — 240	(65 — 17) : 16
	400 — 90	900 — 450	(91 — 23) : 17
	700 — 60	800 — 570	(84 — 19) : 13

200. Уңыш җыюда булышкан өчен югары класс укучыларына 170 хезмәт көне, кечкенәләргә 90 хезмәт көне яздылар. Зурларга, кечкенәләргә караганда, ничә хезмәт көне артыграк язганнар?

201.	110 — 50	120 — 50	220 — 50	630 — 80
	130 — 60	140 — 70	310 — 60	380 — 90
	140 — 80	170 — 80	440 — 70	720 — 60

202. Төзүчеләр мәктәпне 210 көндә салып бетерергә тиеш булганнар, ә алар 190 көндә салып бетергәннәр. Мәктәп срогыннан ничә көн элек өлгергән?

203.	210 — 150	410 — 150	730 — 260	860 — 190
	320 — 140	640 — 180	550 — 470	970 — 280
	240 — 170	350 — 160	620 — 180	710 — 150

204. Узган ел районда 170 трактор һәм аннан 80 данә кимрәк комбайн булган. Быел районда 210 трактор һәм 120 комбайн бар. Бер елда тракторлар саны күпмегә һәм комбайннар саны күпмегә арткан?

205.	130 — 80	210 — 150	250 + 70 — 130
	150 — 90	340 — 180	140 + 180 — 250
	640 — 70	560 — 270	510 — 360 + 170
	810 — 60	720 — 360	920 — 780 + 160

206. Эшчеләр шәһәрдән 110 *км* ераклыктагы совхозга эшкә киткәннәр. Юлда тукталганда шофер: „Тагын 20 *км*



барасыбыз калды", — дигән. Алар туктаганчы ничә километр юл үткәннәр?

207. Бер укучы 300 *м* озынлыктагы юлны йөгереп үткән. Бер минут йөгергәч, юлның аргы башына җитәргә 30 *м* калган. Укучы бер минутта ничә метр йөгергән?

208. Укучылар 300 *кг* гөмбә җыеп, әзерләү пунктына тапшырганнар. Киптергәч, гөмбә 40 *кг* га калган. Киптергәндә гөмбә күпме авырлыгын югалткан?

209. Бер район укучылары 400 *кг* дару үләннәре җыйганнар. Киптергәч бу үләннең авырлыгы 70 *кг* га калган. Сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

210. Түбәндәге мәсьәләгә сорау куегыз һәм чишегез:

Китапханә шкафында 240 китап бар иде. Берничә китапны укучыларга биргәч, шкафта 180 китап калды. Ничә...?

211.

86 — 24	380 — 120	5 — 5	7 — 0
90 — 63	500 — 150	9 — 9	4 — 0
79 — 56	810 — 260	6 — 6	0 — 0

212. $135 - 99 = (135 - 100) + 1 = 35 + 1 = 36$

150 — 99	146 — 99	130 — 98	130 — 49
127 — 99	173 — 99	175 — 98	140 — 68
184 — 99	166 — 99	154 — 98	120 — 59

213. Мәктәп-интернатның җанлы почмагында 39 кролик бар иде. Бер елдан соң аларның саны 120 гә җитте. Ничә кролик арткан?

214. Завод поселогында 98 яңа йорт бар иде. Бер елдан соң алар 145 булды. Бер елда ничә яңа йорт салганнар?

Язып алу.

215. Укучылар 375 *г* гөл орлыгы җыйганнар һәм 125 *г* орлыкны күрше мәктәпкә биргәннәр. Аларның үзләренә ничә грамм гөл орлыгы калган?

Бу мәсьәлә алу юлы белән эшләнә.

375 *г* — кимүче
125 *г* — киметүче
250 *г* — калдык яки аерма.

Кайсы саннан алынса, шунсы кимүче дип атала.

Алына торган сан киметүче дип атала.

Алгач килеп чыккан сан калдык яки аерма дип атала.

Алу билгесе — (минус).

216. $\begin{array}{r}486\\-124\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}798\\-567\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}964\\-854\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}639\\-432\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}895\\-65\\\hline\end{array}$

$\begin{array}{r}784\\-320\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}692\\-501\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}903\\-403\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}890\\-670\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}947\\-30\\\hline\end{array}$

Әгәр 947 дән 30 ны алсак, күпме калыр? Әгәр 947 не 30 га киметсәк, ничә булыр? 947 саны 30 саныннан күпмегә зуррак? 30 саны 947 саныннан күпмегә кечерәк?

217. Кимүче 576, киметүче 250. Аерманы табарга.

218. Сазлыкны киптерү өчен өч канау казыганнар: беренче канауның озынлыгы 388 *м*, икенче канау беренчесеннән 136 *м* га кыскарак, өченчесе икенче канаудан 140 *м* га кыскарак. Өч канауның озынлыгы күпме?

219. Кошларга ашату өчен юннатлар 278 *кг* солы, аннан 26 *кг* кимрәк тары, тарыдан 30 *кг* кимрәк кукуруз тоттылар. Кошларга ашату өчен барлыгы күпме ашлык тотылган?

220. $\begin{array}{r}956\\-735\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}875\\-325\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}768\\-407\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}697\\-75\\\hline\end{array}$ $\begin{array}{r}869\\-50\\\hline\end{array}$

221. $368+579$ $60:5\times7$ $84:6\times4$
$637+290$ $91:7\times6$ $51:3\times5$

222. Магазинда 345 ручка булган, мәктәпкә 28 ручка сатылган. Магазинда ничә ручка калган?

223.

572 — 4	593 — 306	860 — 325	690 — 208
854 — 28	741 — 537	780 — 547	580 — 372
685 — 59	924 — 816	970 — 856	935 — 128

224. 672 саны 154 тән күпмегә зуррак? 154 саны 672 дән күпмегә кечерәк?

225. Бер колхозда 255 сыер, икенчесендә 270 сыер бар иде. Бер елдан соң беренче колхозда 80 сыер, икенчесендә 90 сыер артты. Кайсы колхозда сыерлар күбрәк һәм күпмегә артыграк булды?

226. Фабрика поселогында 138 таш йорт һәм 160 агач йорт бар иде. Соңгы елларда 146 таш йорт һәм 55 агач йорт салынды. Таш йортлар агач йортлардан күпмегә артыграк булды?

227.	485 — 37	792 — 485	780 — 139	237 + 365
	946 — 18	652 — 309	690 — 253	590 + 369
	884 — 57	576 — 368	880 — 74	87 + 765

228. Мәктәп мастерскоенда 326 кәтүк җеп бар иде. Бер көндә 65 кәтүк җеп тотылды. Ничә кәтүк җеп калган?

229.	548 — 65	612 — 472	705 — 384	504 — 390
	926 — 72	423 — 380	608 — 268	906 — 45
	815 — 44	736 — 596	909 — 814	408 — 78

230. Өч мәктәп-интернатта 607 укучы бар. Берсендә 236 укучы, икенчесендә, беренчесенә караганда, 45 укучы кимрәк. Өченче мәктәптә ничә укучы?

231. Физкультура ярышларында 318 кеше катнашкан; шулардан йөзүдә — 85 кеше, йөгерүдә аннан 90 кеше артыграк, калганнары ишкәк ишүдә ярышканнар.

Сорау куярга һәм мәсьәләне чишәргә.

232.	637 — 85	735 — 475	407 — 167	107 + 796
	918 — 53	608 — 372	305 — 285	648 + 57
	826 — 94	503 — 290	916 — 676	94 + 879

233. 1) Югары класс укучылары китапханәдә 125 китапка, башлангыч класс укучылары 48 китапка ремонт ясадылар. Югары класс укучылары, башлангыч класс укучыларына караганда, ничә китап артыграк ремонтладылар?

2) Үз мәктәбегез укучыларының дәреслекләр һәм уку әсбапларын ремонтлаулары турында мәсьәлә төзегез.

234.	742 — 67	940 — 875	425 — 387	702 — 562
	934 — 86	631 — 286	614 — 286	811 — 394
	523 — 97	830 — 772	346 — 198	910 — 589

235. Өч ай вакыт эчендә 220 колхозчының өенә электр үткәрделәр; беренче айда 45 өй, икенче айда, беренче айга

караганда, ике тапкыр артыграк өй электр белән яктыртылды. Өченче айда ничә өйгә электр үткәрелгән?

236. Укучылар 206 төп агач утыртканнар; шулардан 29 төп агачны балалар яслесе ишек алдына, аңар караганда өч тапкыр артыграк агачны балалар бакчасы ишек алдына утыртканнар. Калган агачларны паркка утыртканнар. Укучылар паркка ничә төп агач утыртканнар?

237.

534 — 76	730 — 584	830 — 376	(47 + 37) : 28
625 — 88	920 — 776	403 — 173	(91 — 26) : 13
863 — 95	810 — 547	628 — 570	(83 — 19) : 16

238. (Телдән.)

70 — 6	100 — 3	500 — 7	700 — 4
90 — 8	400 — 2	800 — 9	900 — 1

239.

201 — 5	500 — 38	705 — 87	503 — 76
406 — 8	802 — 56	607 — 98	900 — 82
602 — 7	904 — 78	308 — 69	804 — 59

240. Ларёкта 405 карандаш бар иде, шулардан 138 карандашны саттылар. Ларёкта ничә карандаш калды?

241.

602 — 156	806 — 487	500 — 275	1 000 — 824
704 — 268	503 — 496	700 — 169	1 000 — 277
901 — 575	405 — 49	600 — 382	1 000 — 86
805 — 408	906 — 58	900 — 824	1 000 — 61

242. Совхоздан Орешкино авылына туры юл белән дә, Софьино авылы аркылы үтеп тә барырга мөмкин. Совхоздан Орешкинога туры юл белән 87 *км*, совхоздан Софьинога



34 *км* һәм Софьинодан Орешкинога кадәр 68 *км*. Совхоздан Орешкиного туры юл, Софьино авылы аркылы баруга караганда, ничә *км* га якынрак?

243. Шәһәрдән Марьино авылына кадәр туры юл 96 *км*, шәһәрдән Калиновкага кадәр 87 *км*, Калиновка белән Марьино

арасы, шәһәр белән Калиновка арасына караганда, өч тапкыр якынрак. Шәһәрдән Марьинога туры юл, Калиновка аркылы баруга караганда, ничә километрга кыскарак?



244.			
401 — 175	300 — 147	356 + 479 — 236	87 : 29
804 — 638	700 — 629	87 + 868 — 406	91 : 13
503 — 297	900 — 53	735 + 90 — 350	76 : 38

Берурынлы санга тапкырлау.

Телдән тапкырлау.

245. Беренче рәттәге һәр санны икенче рәттәге һәр санга тапкырларга.

7	5	9
9	6	8

246.



$$30 \times 4 = ?$$

3 дистә × 4 = 12 дистә
30 × 4 = 120

247.				
6 × 3	7 × 5	9 × 4	8 × 6	5 × 9
60 × 3	70 × 5	90 × 4	80 × 6	50 × 9

248. Колхоз умарталыгында 80 умарта бар иде. Бер елдан соң умарталар саны ике тапкыр артты. Умарталыкта ничә умарта булды?

249. Колхоз бакчасында һәр рәттә 40 ар төптән 5 рәт алмагач утыртылган. Барлыгы ничә төп алмагач утыртылган?

250. 1)



2) Кечкенә карточкага: $\times 6$ дип языгыз. Бу карточканы сул яктагы кечкенә түгәрәк урынына куегыз. 50; 70; 90; 80 саннарын алты санына тапкырлагыз.

Бу саннарны шулай ук 8 гә, 5 кә, 9 га тапкырлагыз.

251. Ике колхоздан бер-берсенә каршы ике җәяүле юлга чыккан. Очрашканга чаклы беренче кеше сәгатькә 4 *км* тизлек белән 2 сәгать, икенчесе сәгатькә 3 *км* тизлек белән 3 сәгать барган. Бу ике колхоз арасындагы ераклыкны табарга.



252. Ике шәһәрдән бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан. Очрашканга чаклы беренче поезд сәгатькә 50 *км* тизлек белән 3 сәгать, икенчесе сәгатькә 40 *км* тизлек белән 2 сәгать барган. Бу шәһәрләр арасындагы ераклыкны табарга.

253.	60×4	80×7	$(130 - 80) \times 7$
	80×5	50×9	$(120 - 90) \times 9$
	90×3	60×8	$(680 - 610) \times 8$
	70×6	90×6	$(590 - 530) \times 9$

254.	13×3	14×4	17×5	26×3
	130×3	140×4	170×5	260×3

255. Завод эшчеләре колхозга, һәр җибәрүдә 250 шәр данә итеп, ике тапкыр китаплар җибәрделәр. Алар барысы ничә китап җибәргәннәр?

256. 1)

2) Кечкенә карточкага: ×3 дип языгыз да уңдагы кечкенә квадрат урынына куегыз һәм 120; 140; 160; 190 саннарын 3 санына тапкырлагыз.

Бу саннарның һәрберсен 4 санына да тапкырлагыз.

257. Ларёкта 900 дәфтәр бар иде. Бер атнадан соң анда 150 шәр дәфтәрле 2 төргәк калды. Бер атна эчендә ничә дәфтәр сатылган?

258. Туристларга 980 *км* юл үтәргә кирәк иде. Бер көн баргач, алар, көнгә 240 ар *км* барганда, калган юлны 3 көндә үтеп була, дип исәпләделәр. Алар беренче көндә ничә километр барганнар?

259.

160×2	130×6	120×7	(70+80)×4
190×3	240×4	150×5	(90+50)×7
180×5	170×5	290×3	(120−30)×5
170×4	280×3	140×6	(750−620)×6

260. 1) Берурынлы нинди ике санны тапкырлагач, 28, 35; 27; 56; 42; 63 саннары килеп чыга?

2) 120×3 260×2 180×3 230×4

261. Бер участоктан 3 кәрзин, икенчесеннән 5 кәрзин помидор җыеп алганнар. Һәр кәрзиндә 30 ар *кг* помидор булган. Ике участоктан ничә килограмм помидор җыеп алганнар?

Мәсьәләне Вәли болай чишкән:

1) 30 *кг* × 3 = 90 *кг*.
2) 30 *кг* × 5 = 150 *кг*.
3) 90 *кг* + 150 *кг* = 240 *кг*

Мәсьәләне Гали болай чишкән:

1) 3 к. + 5 к. = 8 к.
2) 30 *кг* × 8 = 240 *кг*.

Мәсьәләне чишкәндә, аларның һәрберсе ничек уйлаганнар? Кайсы чишү юлы яхшырак?

262 һәм 263 нче мәсьәләләрне ике юл белән чишәргә.

262. Бер звенода 8 пионер, икенчесендә 7 пионер бар. Һәр пионер 6 шар кролик тәрбияләргә йөкләмә алган. Ике звено пионерлары барлыгы ничә кролик тәрбияләргә тиеш?

263. Укучылар бер участокка 4 рәт, икенче участокка шундый ук 3 рәт кура җиләге утыртканнар. Һәр рәттә 20 шәр төп булса, укучылар барысы ничә төп кура җиләге утыртканнар?

Язып тапкырлау.

264. Пионерларның ике звеносы металл ватыклары җыйды. Һәр звено 124 әр *кг* металл ватыгы җыйды. Ике звено пионерлары ничә килограмм металл ватыгы җыйдылар?

Мәсьәлә тапкырлау юлы белән чишелә.

124 *кг* — тапкырланучы } тапкырлашучылар.
×2 — тапкырлаучы }
248 *кг* — тапкырчыгыш

Нинди санны тапкырласак, шул сан тапкырланучы дип атала.

Нинди санга тапкырласак, шул сан тапкырлаучы дип атала.

Тапкырланучы һәм тапкырлаучы икесе бергә тапкырлашучылар дип аталалар.

Тапкырлау нәтиҗәсендә килеп чыккан сан тапкырчыгыш дип атала.

Тапкырлау билгесе × яки · (нокта).

265.

232	143	321	313	212
×2	×2	×3	×3	×4

266. 1) Тапкырланучы 213, тапкырлаучы 3. Тапкырчыгышны табарга.

2) 121 һәм 4 саннарының тапкырчыгышын табарга.

267. (Телдән.) 1) $1\times5=1+1+1+1+1=5$

$0\times5=0+0+0+0+0=0$

2) 0×4 0×5 0×9 0×1

0×2 0×3 0×7 0×8

268.

302	103	401	203	202
×2	×3	×2	×3	×4

Нинди сан 202 дән 4 тапкыр зуррак? 202 не 4 тапкыр зурайтсаң, ничә була?

269. Тапкырлашучыларның берсе 202, икенчесе 3. Бу сан-нарның тапкырчыгышын табарга.

270. Авыл мәктәбенә җибәрү өчен, пионерларның бер отряды 132 китап, икенче отряды 2 тапкыр артыграк китап җыйды. Икенче отряд ничә китап җыйган?

271. Урта мәктәптә беренче чиректә 78 отличник бар иде, икенче чиректә аларның саны 24 кә артыграк булды, ә ел азагында отличниклар саны, икенче чиректәгегә караганда, ике тапкыр артты. Ел азагында мәктәптә ничә отличник булды?

272. „Пионерская правда“ газетасына бер мәктәптә 104 укучы, икенче мәктәптә 28 гә артыграк укучы, өченче мәктәптә, беренчегә караганда, ике тапкыр артыграк укучы язылды. „Пионерская правда“ газетасына өч мәктәптә ничә укучы язылган?

273.	342×2	204×2	122×4	$435 + 287$
	213×3	302×3	103×3	$561 - 274$
	414×2	101×5	101×8	$601 - 429$

274.	(Телдән.)	40×7	50×9	80×8
		90×7	70×6	90×6

275.	32×6	56×7	225×3	438×2
	45×5	74×8	123×4	329×3

276. Завод елның баштагы 5 аенда 35 әр паровоз, калган 7 аеның һәркайсында 38 әр паровозга ремонт ясаган. Завод бер елда ничә паровоз ремонтлаган?

277. 6 тавык елга 165 әр йомырка, 6 үрдәк 50 шәр йомырка салган. Тавыклар, үрдәкләргә караганда, ничә йомырка артыграк салганнар?

278.	42×8	58×7	124×4	$(178 + 169) \times 2$
	74×5	69×8	227×3	$(261 - 176) \times 8$
	96×6	87×9	112×7	$(440 - 358) \times 9$

279. (Телдән.) 130×5 170×4 180×5 270×3

280.	142×4	151×5	136×4	186×5
	253×3	182×4	278×3	124×8
	374×2	161×6	157×6	128×7

281. Магазинда 40 данә радиоалгыч бар иде. Көн азагына 32 радиоалгыч калды. Әгәр бер радиоалгыч 72 сум торса, магазин радиоалгычлар сатудан күпме акча алган?

282. Магазинда 33 телевизор бар иде. Көн азагына 29 гына калды. Әгәр телевизорның берсе 225 сум торса, магазин телевизорлар сатудан күпме акча алган?

283. Тавыкларга ашату өчен, һәрберсе 75 әр *кг* лы 8 капчык тары хәзерләделәр. Бер айдан соң 5 капчык тары калды. Бер айда ничә килограмм тары тотылган?

284.

182×4	238×4	166×6	$157 \times (96:24)$
293×3	142×7	279×3	$129 \times (98:14)$
171×5	136×6	198×4	$256 \times (84:28)$

285. Балыкчылар бер көнне 106 *кг*, икенче көнне 2 тапкыр күбрәк балык тотканнар. Балыкчылар ике көндә күпме балык тотканнар?

286.

204×3	107×6	109×4	105×6
103×8	108×5	206×3	107×9

287. 1) Бирелгән санны берничә берәмлеккә зурайтуны сораган мәсьәләләр нинди гамәл белән чишеләләр?

Шундый мәсьәлә төзергә.

2) Бирелгән санны берничә тапкыр зурайтуны сораган мәсьәләләр нинди гамәл белән чишеләләр?

Шундый мәсьәлә төзергә.

288. Липовкадан Софринога кадәр 103 *км*, Софринодан Осиповкага кадәр 5 тапкыр ераграк. Липовкадан Осиповкага кадәр ничә километр?

289. Кыш башында мәктәптә 108 укучы конькида шуа белә иде, кыш ахырына конькида шуучылар саны тагын өч тапкыр артты. Кыш буенча ничә укучы конькида шуарга өйрәнгән?

290.

106×5	307×3	135×7	107×8
208×4	109×6	198×4	269×3

291. Мисаллар дөрес чишелгәннәрме, тикшерегез:

$(411 - 328) \times (85:17) = 415$ $\quad$ $(400 - 292) \times (96:16) = 648$

$(700 - 497) \times (72:18) = 812$ $\quad$ $(912 - 784) \times (91:13) = 896$

Берурынлы санга бүлү.

Телдән бүлү.

292. 120 карандашны ике тартмага тигез итеп бүлеп салганнар. Һәрбер тартмага ничәшәр карандаш салынган?



Чишү. **120 к. : 2 = ?**

12 дистә к. : 2 = 6 дистә к.
120 к. : 2 = 60 к.

293. 18 : 2 24 : 3 30 : 5 32 : 4 45 : 9
180 : 2 240 : 3 300 : 5 320 : 4 450 : 9

294. Бер авылда 180 йорт бар. Йортларның яртысының түбәсе калай белән, өчтән березенең түбәсе черәп белән ябылган. Ничә йортның түбәсе калай белән һәм ничә йортның түбәсе черәп белән ябылган?

295. 250 : 5 210 : 3 350 : 7 360 : 9 400 : 8
360 : 4 420 : 6 480 : 8 560 : 7 810 : 9

296. Беренче участоктан 165 *кг*, икенчесеннән, беренчегә караганда, 5 *кг* кимрәк, өченче участоктан, икенчегә караганда, 2 тапкыр кимрәк кәбестә алдылар.

Ике гамәл белән чишелерлек итеп, мәсьәләгә сорау куярга.

Өч гамәл белән чишелерлек итеп, мәсьәләгә сорау куярга.

297. Беренче участоктан 90 *кг*, икенчесеннән, беренчегә караганда, 4 тапкыр артыграк, өченче участоктан, икенчегә караганда, 6 тапкыр кимрәк суган алдылар. Өч участоктан ничә килограмм суган алганнар?

298. 180 : 3 240 : 8 270 : 3 20 × 9 : 6
420 : 7 280 : 4 490 : 7 60 × 4 : 3
450 : 5 540 : 6 300 : 6 40 × 9 : 6
480 : 6 630 : 9 720 : 9 30 × 8 : 4

299. 36 : 3 56 : 4 60 : 5 96 : 8 78 : 6
360 : 3 560 : 4 600 : 5 960 : 8 780 : 6

300. Пассажир поездда 600 *км*, пароходта 4 тапкыр кимрәк барды. Пассажир барлыгы ничә километр юл үткән?

301.

520 : 2	600 : 5	640 : 4	780 : 2	810 : 3
450 : 3	750 : 3	510 : 3	900 : 6	950 : 5

302. Эшчеләрнең бер бригадасы 5 көндә 600 китап төпләде, икенче бригада шул ук сандагы китапны 4 көндә төпләп бетерде. Кайсы бригада көнгә күбрәк һәм ничә китап артыграк төпләгән?

303. Бер чаңгычы 800 *м* араны 5 минутта үтте, икенчесе шул ук араны 1 минутка тизрәк үтте. Икенче чаңгычы бер минутта, беренчегә караганда, ничә метр артыграк юл үткән?

304.

320 : 2	680 : 4	480 : 3	(340 + 230) : 3
580 : 2	720 : 3	910 : 7	(890 − 250) : 4
420 : 3	840 : 6	650 : 5	(920 − 80) : 7
600 : 5	950 : 5	920 : 4	(810 − 90) : 6

305. Бүлү гамәлен эшләгез:

32	: 4	**320**	: 4	**350**	: 5	**480**	: 6
72		**720**		**850**		**900**	

306 1) Интернат-мәктәп өчен 2 холодильник һәм 5 тегү машинасы сатып алынган. Барысы өчен 930 сум акча түләгәннәр. Әгәр һәр тегү машинасы 90 сум торса, холодильникның берсе ничә сум торган?

2) Тегү машинасын 70 сум дип, мәсьәләне яңадан чишегез.

307. 36 *м* материядән 9 күлмәк текteләр. 760 *м* материядән шундый ничә күлмәк тегәргә мөмкин?

308. Түбәндәгечә чишелә торган мәсьәлә төзергә:

1) 12 *м* : 4 = 3 *м*
2) 420 *м* : 3 *м* = 140 (пальто).

Җавап: 140 пальто.

309. 180, 6, 300 саннары бирелгән. Беренче сан икенче саннан ничә тапкыр зуррак? Өченче сан икенче саннан ничәгә зуррак?

310. 8, 240, 360 саннары бирелгән. Беренче сан икенчесеннән ничәгә кечерәк? Беренче сан өченчесеннән ничә тапкыр кечерәк?

311. Физкультурачы 2 минутта 500 *м* йөгерде. Әгәр ул йөгерешен минутына 20 *м* га арттырса, 3 минутта ничә метр йөгерә алыр?

312. Чишү юлы үткән мәсьәләгә охшаган мәсьәлә төзегез һәм чишегез.

313.

360 : 4	400 : 5	870 : 3	(470 + 90) : 8
680 : 4	700 : 5	910 : 7	(830 — 80) : 5
240 : 3	420 : 7	780 : 6	(990 — 310) : 4

100 эчендә калдыклы бүлү.

314. 1) 20 дән 30 га кадәр булган нинди саннар 3 кә, 4 кә, 5 кә, 6 га калдыксыз бүленә?

2) 30 дан 40 ка кадәр булган нинди саннар 4 кә, 5 кә, 6 га, 7 гә калдыксыз бүленә?

315. Алъяпкычка 2 *м* материя китә. 15 *м* материядән ничә алъяпкыч тегеп булыр һәм ничә метр артып калыр?

316.

12 : 2	15 : 3	20 : 4	25 : 5	27 : 3
13 : 2	17 : 3	23 : 4	26 : 5	29 : 3
18 : 2	24 : 3	36 : 4	40 : 5	28 : 4
19 : 2	25 : 3	38 : 4	44 : 5	31 : 4

317.

15 : 2	38 : 5	34 : 4	19 : 3	39 : 4
20 : 3	30 : 4	14 : 3	49 : 5	26 : 3
29 : 4	28 : 3	23 : 5	26 : 4	34 : 5
14 : 5	11 : 2	33 : 4	21 : 5	35 : 4

318. Бер малайның 5 әр тиенлек 6 акчасы бар. Ул бу акчаларга 4 әр тиенлек ничә ручка алыр һәм аның ничә тиен акчасы артып калыр?

319. Берурынлы нинди ике санны тапкырлагач, 48 килеп чыга? 63? 49? 56? 72?

320. 50 дән 60 ка кадәр булган нинди саннар 6 га, 7 гә, 8 гә, 9 га калдыксыз бүленәләр?

321. Бер дәфтәргә 6 шар табак кертеп, 20 табак кәгазьдән ничә дәфтәр тегәргә мөмкин? Тагын ничә табак кәгазь артып калыр?

322.

24 : 6	35 : 7	40 : 8	36 : 9	49 : 7
25 : 6	40 : 7	47 : 8	40 : 9	54 : 7
42 : 6	56 : 7	56 : 8	81 : 9	54 : 9
45 : 6	61 : 7	59 : 8	89 : 9	62 : 9

323. 8 гә бүлгәндә, иң зур калдык ничә булырга мөмкин? 6 га бүлгәндә? 9 га бүлгәндә? 7 гә бүлгәндә?

324.	15 : 6	36 : 8	51 : 9	44 : 7	26 : 7
	30 : 7	35 : 6	47 : 6	58 : 6	64 : 7
	28 : 8	47 : 9	50 : 8	75 : 9	58 : 8

325.	32 : 6	31 : 7	43 : 6	45 : 8	52 : 9
	18 : 7	28 : 9	67 : 9	32 : 7	63 : 8
	21 : 8	37 : 8	55 : 7	40 : 6	41 : 7

326. Тегүчедә 15 төймә бар иде. Мастерскойда аңа тагын шундый 35 төймә бирделәр. Ул һәр күлмәккә 6 шар төймә такты. Барлык төймә ничә күлмәккә җиткән һәм ничә төймә артып калган?

327.	47 : 5	39 : 7	66 : 9	33 : 5	52 : 6
	35 : 4	42 : 5	30 : 4	51 : 8	42 : 8
	23 : 3	59 : 8	54 : 7	49 : 6	77 : 9

328. Колхозчы хатын иртә белән 9 *л*, ә көндез 3 *л* артыграк сөт савып алды. Барлык сөтне ике литр сыешлы банкаларга бүлеп салды. Ничә тулы банка булган һәм ничә литр сөт артып калган?

329.	38 : 4	40 : 6	71 : 8	54 : 7	51 : 6
	20 : 3	50 : 9	59 : 6	80 : 9	60 : 9
	37 : 5	48 : 7	84 : 9	70 : 8	55 : 8

330. Мисаллар дөрес чишелгәннәрме?

$(57 + 186) \times 4 = 972$ $\quad$ $(612 - 536) \times 9 = 684$

$(704 - 637) \times 8 = 536$ $\quad$ $(900 - 768) \times 7 = 924$

$(201 - 76) \times 5 = 625$ $\quad$ $(502 - 428) \times 8 = 592$

Язып бүлү.

331. 284 төп каенны, һәр якка тигез санда итеп, юлның ике ягына утыртып чыктылар. Һәр якка ничәшәр төп каен утыртылган?

$$\begin{array}{r|l} 284 \text{ к.} & 2 \\ \cline{2-2} -\underline{2} & 142 \text{ к.} \\ -\underline{8} & \\ \underline{8} & \\ -\underline{4} & \\ \underline{4} & \\ 0 & \end{array}$$

Бу мәсьәләдә: 284 — бүленүче
2 — бүлүче
142 — өлеш

> **Кайсы санны бүлсәк, шунысы бүленүче дип атала.**
> **Кайсы санга бүлсәк, шунысы бүлүче дип атала.**
> **Бүлгәч килеп чыккан сан өлеш дип атала.**
> **Бүлү билгесе: (ике нокта).**

332. 486 : 2 693 : 3 936 : 3 996 : 3 966 : 3
642 : 2 848 : 4 264 : 2 555 : 5 484 : 4

Әгәр 484 не 4 тигез өлешкә бүлсәң, ничә була?
Әгәр 484 не 4 тапкыр кечерәйтсәң, ничә була?
484 нең дүртенче өлеше ничәгә тигез?
484 эчендә ничә тапкыр 4 бар?
484 саны 4 тән ничә тапкыр зур?

333. Бүленүче 396, бүлүче 3, өлешне табарга.

334. Китап төпләү мастерское эшчеләре 848 китапны 3 көндә төпләделәр. Беренче көнне алар барлык китапның дүртенче өлешен, икенче көнне, беренче көнгә караганда, 88 китап артыграк төпләделәр. Эшчеләр өченче көнне ничә китап төпләгәннәр?

335. Әтисе колхозда бер ел эчендә 428 хезмәт көне, улы әтисеннән ике тапкыр кимрәк, әнисе, әтиләренә караганда, 78 хезмәт көне кимрәк эшләгән. Алар барысы бергә бер елда ничә хезмәт көне эшләгәннәр?

336. 488 : 2 448 : 4 684 : 2 (700 — 212) : 4
963 : 3 639 : 3 777 : 7 (604 — 136) : 2

337. (Телдән.) 1) 64 : 4 91 : 7 520 : 2 750 : 5

2) Өлешне һәм калдыкны табарга:

7 : 2 9 : 4 7 : 4 8 : 3

3) 7 дистә 4 берәмлектә ничә берәмлек бар? 2 дистә 8 берәмлектә? 6 дистә 5 берәмлектә?

338. Мастерскойдан ике магазинга тигез санда итеп барлыгы 456 данә балалар көрәге җибәрелгән. Һәр магазинга ничәшәр көрәк җибәрелгән?

Чишү:

```
_456 к. | 2
  4     |------
  --    | 228 к.
 _5
  4
  --
 _16
  16
  --
   0
```

Чишүне тикшереп карагыз һәм бүлү гамәле ничек эшләнгәнен аңлатыгыз.

339.	674:2	892:4	490:2	678:6	476:4
	896:2	676:2	860:4	896:8	687:3
	678:3	954:3	580:5	798:7	585:5

340. 678 *км* озынлыкта телефон линиясе үткәрергә кирәк булган. Бер ай эчендә эшчеләрнең бер бригадасы өченче өлешен, икенче бригадасы барлык линиянең яртысын үткәргән. Бер ай эчендә икенче бригада, беренчегә караганда, ничә километр линия артыграк үткәргән?

341. Ике пристань арасы 560 *км*. Пароход беренче көнне юлның бишенче өлешен, икенче көнне барлык юлның дүртенче өлешен үткән. Пароход кайсы көнне күбрәк һәм ничә километрга артыграк үткән?

342. Эшчеләргә 120 *км* озынлыктагы юлны төзәтергә кирәк булган. Беренче көнне алар барлык юлның дүртенче өлешен, ә икенче көнне калган юлның яртысын төзәткәннәр. Икенче көнне эшчеләр ничә километр юл төзәткәннәр?



343. Укучыларга китапханәдәге 150 китапны төпләргә кирәк иде. Беренче көнне алар барлык китапның бишенче өлешен, икенче көнне калган китапларның өченче өлешен төпләделәр. Икенче көнне алар ничә китап төпләделәр?

344.	654:2	298:2	468:4	684:6	214 × 4:2
	876:4	675:3	595:5	872:4	228 × 3:6

345. (Телдән.) 1) 240 : 6   350 : 7   480 : 8   810 : 9

2) Өлешне һәм калдыкны табарга:

29 : 3   27 : 5   38 : 9   50 : 8

3) 2 йөз һәм 4 дистәдә ничә дистә бар? 1 йөз һәм 5 дистәдә? 2 йөз һәм 7 дистәдә? 4 йөз һәм 5 дистәдә?

346. Пионер дружинасы ике отрядка 150 *кг* иске кәгазь җыярга тапшырды. Әгәр отрядлар икесе дә бертигез җыярга уйласалар, һәрбер отряд ничәшәр килограмм кәгазь җыярга тиеш?

347.	146 : 2	355 : 5	408 : 8	567 : 7	486 : 6
	219 : 3	288 : 4	426 : 6	549 : 9	728 : 8

348.	196 : 2	370 : 5	330 : 6	684 : 9	595 : 7
	332 : 4	291 : 3	455 : 7	504 : 8	531 : 9

349. Укучылар бер участокта 248 *кг*, икенчесендә 2 тапкыр кимрәк кәбестә үстерделәр. Үстергән кәбестәнең дүртенче өлешен кроликларга ашату өчен тоттылар. Кроликларга ашату өчен ничә килограмм кәбестә тотылган?

350. Укучылар бер участоктан 168 *кг*, икенчесеннән 3 тапкыр кимрәк кишер җыеп алдылар. Җыеп алынган барлык кишернең яртысын мәктәптә кайнар аш өчен тоттылар. Кайнар аш өчен ничә килограмм кишер тотылган?

351.	168 : 4	232 : 4	432 : 9	(642 — 357) : (51 : 17)
	9 : 3	504 : 6	539 : 7	(843 — 358) : (95 : 19)
	405 : 5	592 : 8	516 : 6	(700 — 196) : (78 : 13)
	260 : 4	252 : 3	376 : 8	(980 — 278) : (96 : 16)

352. Эшче хатын 108 сум хезмәт хакы алды. Ул бу акчаның дүртенче өлешен саклык кассасына салды. Ул саклык кассасына ничә сум акча салган?

353.	570 : 2	840 : 5	882 : 7	708 : 4	984 : 8
	672 : 4	936 : 6	965 : 5	903 : 7	852 : 6
	792 : 3	920 : 8	738 : 6	822 : 6	973 : 7
	828 : 6	912 : 4	801 : 3	895 : 5	936 : 4

354. Ике пристань арасы 180 *км*. Пароход бу араны агым уңаена 5 сәгатьтә, агымга каршы 6 сәгатьтә үткән. Пароход,

агымга каршы баруга караганда, агым уңаена сәгатькә ничә километр тизрәк йөрегән?



355. Эшчеләр бригадасы 7 сәгать эчендә 112 деталь эшләргә тиеш, ә коммунистик хезмәт бригадасы 128 детальне 4 сәгатьтә эшләп бетерә. Коммунистик хезмәт бригадасы 1 сәгатьтә, билгеләнгәнгә караганда, ничә тапкыр артыграк деталь эшли?

356. Поезд 8 сәгатькә 352 *км* юл үтте, пароход 6 сәгатькә 132 *км* юл үтте. Поезд пароходка караганда, 1 сәгатькә ничә тапкыр артыграк юл үткән?

357.	875 : 5	918 : 6	996 : 4	(329 + 127) : 8
	572 : 4	966 : 7	894 : 6	(803 — 158) : 5
	855 : 3	992 : 8	889 : 7	(900 — 156) : 6
	976 : 2	792 : 3	952 : 8	(704 — 156) . 4

358. 416 карандаш тигез итеп 2 тартмага салынган. Һәр тартмада ничәшәр карандаш?



Чишү:

```
_416 к. | 2
 4      |------
 --     |208 к.
 _16
  16
  --
   0
```

Бүлү гамәле ничек эшләнгән? Өлештә уннар урынына ни өчен нуль куелган?

359.	612 : 2	828 : 4	742 : 7	745 : 5	536 : 8
	927 : 3	648 : 6	963 : 9	872 : 8	861 : 7
	540 : 5	921 : 3	864 : 8	954 : 9	576 : 6

360. Укучылар 735 *г* кукуруз орлыгын тигез итеп 7 пакетка салдылар да, 4 пакетны үзләренә алып, калганын бала-

лар йортына бүләк иттеләр. Укучылар балалар йортына ничә грамм орлык бүләк иттеләр?

361. Колхоз бакчасында бер көнгә 216 *кг* җир җиләге җыйдылар. Барлык җиләкнең яртысын 4 әр *кг* сыешлы ящикларга салдылар. Ничә...?

Сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

362. Түбәндә кыскача язылган шартлар буенча мәсьәләләр төзергә:

1)	2)
5 капчык 350 *кг*	5 сәгать 350 *км*
7 капчык x *кг*	7 сәгать x *км*

363. Пионер бер көндә 8 *кг*, бер атнада 192 *кг* металл ватыклары җыйды. Пионер, бер көнгә караганда, бер атнада ничә тапкыр артыграк металл ватыклары җыйган?

364.

$436:4$	$648:6$	$675:5$	$106\times 6:3$
$530:5$	$836:4$	$954:6$	$126\times 7:3$
$856:8$	$972:9$	$896:7$	$132\times 6:3$

Барлык гамәлләргә мәсьәләләр һәм мисаллар.

Телдән чишү өчен.

365.

$65:5\times 6+22$	$(240+360):5$	$60\times 6:4$
$72:6\times 7-18$	$(180+450):7$	$80\times 6:3$
$96:24\times 13+19$	$(600-520)\times 6$	$560:7\times 9$
$84:14\times 12-29$	$(310-180)\times 4$	$680:4\times 5$

366. 1) Нинди ике санны тапкырлагач, 48 чыга? 75? 84? 96?

2) Нинди ике санны тапкырлагач, 180 килеп чыга? 240? 360? 450?

367. 1) Берсе икенчесеннән 15 кә кечерәк булган ике сан әйтергә.

2) Берсе икенчесеннән 8 тапкыр кечерәк булган ике сан әйтергә.

368. 1) 6 ны 15 тапкыр зурайтырга, килеп чыккан санны 6 га зурайтырга, яңа килеп чыккан санны 4 тапкыр кечерәйтергә.

2) 58 не 16 га кечерәйтергә, чыккан санны 3 тапкыр кечерәйтергә, яңа килеп чыккан санны 5 тапкыр зурайтырга.

369. Түгәрәкләү юлы белән чишәргә:

35 + 19	63 + 99	52 − 19	145 − 99
47 + 29	75 + 98	67 − 39	230 − 98
58 + 36	99 + 54	81 − 58	423 − 99
69 + 25	98 + 85	93 − 79	654 − 98

370. 1) Түгәрәкләү юлы белән чишәргә уңайлы итеп, кушу гамәленә мисаллар төзергә.

2) Шундый ук мисалларны алу гамәленә карата да төзергә.

371. Мәктәптәге рәсемнәр күргәзмәсенә икенче класс 28 рәсем, өченче класс, икенчегә караганда, ике тапкыр артыграк, ә дүртенче класс, икенче һәм өченче класслар биргәнгә караганда, 2 рәсем артыграк бирде. Дүртенче класс ничә рәсем биргән?

372. Чишү юлы үткән мәсьәләгә охшаган мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.

373. Бер пионер — 45 *кг*, икенчесе — 68 *кг*, өченчесе 90 *кг* металл ватыклары җыйган. Өченче пионер икенчесеннән ничә килограмм артыграк җыйган? Өченче пионер, беренчегә караганда, ничә тапкыр артыграк металл ватыгы җыйган?

374. Физкультурачы 1000 *м* йөгерергә тиеш иде. Ул инде озынлыгы 400 *м* лы әйләнәне 2 тапкыр йөгереп үтте.

Сорау куярга һәм мәсьәләне чишәргә.

375. Слесарь 100 деталь ясады. 3 сәгать буе ул сәгатькә 12 шәр деталь, аннан сәгатькә 16 шар деталь ясады. Барлык детальне ясар өчен күпме вакыт киткән?

376. Чаңгычыларга 50 *км* юл үтәргә кирәк иде. Ике сәгать буена алар сәгатькә 9 ар *км* тизлек белән, аннан соң сәгатькә 8 әр *км* тизлек белән бардылар. Чаңгычылар барлык юлны ничә сәгатьтә үттеләр?

377. Тегүче апа 96 мендәр тышын 6 көн текте. Ул 80 мендәр тышын ничә көндә тегеп бетерер?

378. Тавык йомыркасының авырлыгы 60 *г*. Авырлыкның унынчы өлеше — кабыкка, яртысы — аксымга, ә калганы сарысына туры килә. Йомырканың сарысы нинди авырлыкта булыр?

379. Пионерлар балалар бакчасына 60 уенчык төзәтергә тиеш иделәр. Беренче көнне барлык уенчыкның бишенче өлешен, икенче көнне калган уенчыкларның өченче өлешен төзәттеләр. Алар икенче көнне ничә уенчык төзәткәннәр?

380. Бакчачы бер алмагачтан бер үк зурлыктагы 2 кәрзин белән 60 *кг* алма җыйды. Икенче алмагачтан шундый ук 3 кәрзин алма җыеп алды. Ул ике алмагачтан ничә килограмм алма җыйган? (Ике юл белән чишәргә.)

381. 90 төп агачны тәрбияләп үстерү өчен, укучыларның ике бригадасына бүлеп бирергә кирәк. Беренче бригадада 10, икенчесендә 8 укучы. Һәр укучыга тигез эшләргә туры килсен өчен, бер укучыга ничә агач беркетергә кирәк?

382. Балалар бакчасы өчен 6 *кг* печенье...

Түбәндәгечә чишелерлек итеп, мәсьәләнең шартын тутырып языгыз.

1) 2 сум $\times$ 6 = 12 сум.
2) 33 сум — 12 сум = 21 сум.
3) 21 сум : 3 сум = 7 (*кг*).

Җавап. 7 *кг* конфет алынган.

Язып эшләү өчен.

383.

$356+248+151$	$832-(245+387)$	$641-(810-577)$
$164+409+372$	$754-(96+478)$	$912-(702-436)$
$76+665+88$	$963-(539+67)$	$700-(511-395)$

384.

$148\times3:6$	$632:4\times3$	$918:3:2$	$864:3:4$
$128\times7:8$	$801:9\times7$	$732:4:3$	$522:2:3$
$108\times6:9$	$675:5\times4$	$855:5:9$	$936:2:4$

385. 1) Магазинда октябрь аенда 185 радиоалгыч сатылган, ноябрьда, октябрь аенда сатылганга караганда, 57 гә артыграк, ә декабрьда октябрь һәм ноябрь айларында сатылган кадәр радиоалгыч сатылган. Өч ай эчендә ничә радиоалгыч сатылган?

2) Октябрь аенда магазин 215 радиоалгыч саткан дип, мәсьәләне яңадан чишегез.

386. Китап магазины 3 көндә 910 дәреслек саткан: шулардан беренче көнне 340 дәреслек, икенче көнне, беренче көнгә караганда, 60 дәреслек кимрәк, өченче көнне калганнарын сатып бетергән. Өченче көнне ничә дәреслек сатылган?

387. 1) Класс китапханәсендә 128 китап бар иде. Китапханәне тулыландыру өчен 14 укучы икешәр китап, 18 укучы берәр китап китерде. Китапханәдә хәзер ничә китап булды?

2) Үзегезнен класс китапханәсендәге китаплар саны турында мәсьәлә төзегез.

388. Авыл мәктәбе укучылары Мәскәүгә экскурсиягә киткәннәр. Алар мәктәптән тимер юл станциясенә кадәр сәгатькә 34 *км* тизлек белән 2 сәгать автобуста барганнар. Станциядән Мәскәүгә кадәр сәгатькә 45 *км* тизлек белән 6 сәгать поездда барганнар. Балалар барлыгы ничә километр юл үткәннәр?

389. 5 тавыкка 4 көндә 900 *г* бөртекле ашлык бирелгән. Бер тавыкка бер көнгә күпме ашлык туры килә?

390. 8 сыерга 7 көндә 168 *кг* көрпә ашатканнар. Бер сыерга бер көнгә ничә килограмм көрпә бирелгән?

391. Сыер савучы бер көнгә 174 *л* сөт савып алган: 6 сыер 20 шәр *л*, калганнары 18 әр *л* сөт биргән. Ул ничә сыер сауган?

392. Колхоз бер үк зурлыктагы җиде кисмәккә тутырылган 525 *кг* балны колхозчыларга бүлеп бирде, шундый ук зурлыктагы 2 кисмәк балны умарталарга азык өчен калдырды. Колхозда барлыгы ничә килограмм бал булган? (Мәсьәләне ике юл белән чишәргә.)

393. Мастерской һәр көн 7 шәр трактор ремонтлап, барысы 189 тракторга ремонт ясарга тиеш булган, ә ул көнгә 9 ар трактор ремонтлаган.. Мастерской эшне срогыннан ничә көн элек үтәгән?

394. Мебельләр ясау мастерское 288 шкаф ясарга заказ алган һәм һәр көн 6 шар шкаф ясарга тиеш булган. Әгәр көнгә 8 әр шкаф ясаса, мастерской заказны срогыннан ничә көн элек үтәр?

395. Сәгатькә 50 *км* тизлек белән барып, шофёр шәһәргә 6 сәгатьтә барып житте. Икенче шофёр бу араны 5 сәгатьтә үтәргә тиеш. Ул нинди тизлек белән барырга тиеш?



Бу араны 4 сәгатьтә үтәр өчен, шофёр нинди тизлек белән барырга тиеш?

396. (531 — 162) : 3 540 : 5 × 9 728 : (68 : 17)
(704 — 376) : 4 672 : 7 × 8 609 : (91 : 13)
(822 — 156) : 6 567 : 9 × 7 834 : (90 : 15)
(976 — 288) : 8 732 : 6 × 5 905 : (65 : 13)

397. Тегү фабрикасы башта 408 *м*, аннан соң 136 *м* артыграк материя алган. Барлык материядән күлмәкләр теккән. Һәрбер күлмәккә 4 әр *м* материя киткән.

Сорау куярга һәм мәсьәләне чишәргә.

398. Мебель магазинында 126 шар сумнан 15 шкаф бар иде. Көн азагына 9 шкаф калды. Магазин шкафлар сатудан күпме акча алган?

399. Чишү юлы югарыдагы мәсьәләгә охшаган бер мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.

400. Бер автомобиль 288 *км* юлны 3 сәгатьтә, икенчесе 4 сәгатьтә үткән. Кайсы автомобильнең бару тизлеге зуррак һәм сәгатенә ничә километрга артыграк?

401. Колхозда сарыклардан барлыгы 949 *кг* йон кыркып алганнар. 116 сарыктан 4 әр *кг*, калган сарыкларның һәркайсыннан 5 әр *кг* йон алганнар. Барлыгы ничә сарыкның йонын кырыкканнар?

402. Бер участоктан 5 капчык, икенчесеннән шундый ук 4 капчык бәрәңге алганнар. Ике участоктан алынган бәрәңге 468 *кг* булган. Бер капчыкка ничә килограмм бәрәңге сыйган?

403. Тегү мастерское 216 пальтоны 27 көндә тегеп бетерергә йөкләмә алган иде. Мастерской көнгә 9 ар пальто текте. Йөкләмә срогыннан ничә көн элек үтәлгән?

404. Бер мәктәптәге 140 пионерның дүртенче өлеше картларга һәм инвалидларга яшелчә бакчаларын эшкәртүдә булышканнар, бишенче өлеше кышка ягулык хәзерләгәннәр, калган пионерлар яшелчә җыйганнар. Һәр эштә ничә пионер катнашкан?

405. Укучылар 465 *г* яшелчә орлыгы хәзерләгәннәр. Орлыкларның өченче өлеше кыяр орлыгы, 130 *г* ы кишер орлыгы, калганнары чөгендер орлыгы булган. Укучылар күпме чөгендер орлыгы хәзерләгәннәр?

406. Иң яхшы дәфтәрләр күргәзмәсенә бер класстан 174 дәфтәрнең өченче өлешен, икенче класстан 180 дәфтәрнең дүртенче өлешен алганнар. Күргәзмәгә кайсы класстан күбрәк һәм ничә дәфтәр артыграк алганнар?

407. Аучылар артеле хәзерләү пунктына 435 тире тапшырган. Тапшырылган тиреләрнең бишенче өлеше төлке тиресе, 185 е куян тиресе, ә калганнары тиен тиреләре иде. Тиен тиресе ничә булган?

408. Укучыларга 108 агачның төбен йомшартырга кирәк иде. Алар беренче көнне барлык агачның алтынчы өлешенең төбен, ә икенче көнне калган агачларның өченче өлешенең төбен йомшарттылар. Балалар икенче көнне ничә агач төбен йомшартканнар?

409. Бер кыз коедан ике тапкыр су алып кайтты. Кое өйдән 56 *м* ераклыкта. Бу кыз барлыгы ничә метр юл үткән?

410. Фәрит сарайдан өйгә ике тапкыр утын кертте һәм ул барысы 116 *м* юл үтте. Өйдән сарайга кадәр ничә метр?

411.

$356 + 247 + 98$	$632 : 8 \times 9 - 409$
$960 - (75 + 588)$	$123 \times 8 : 6 - 87$
$705 - (814 - 696)$	$801 : 9 \times 8 - 379$
$912 - (623 - 387)$	$736 : 4 \times 5 - 538$

412.

$124 \times 6 : 4 + 196$	$848 : 8 \times 9 - 186$
$132 \times 7 : 3 + 188$	$732 : 3 \times 4 - 298$
$248 \times 4 : 2 - 167$	$822 : 6 \times 5 - 389$
$237 \times 4 : 3 - 159$	$912 : 3 \times 2 - 277$

413.

$(169 + 187) \times (78 : 39)$	$(724 - 388) : (96 : 24)$
$(501 - 395) \times (81 : 27)$	$(882 - 186) : (84 : 14)$
$(810 - 685) \times (85 : 17)$	$(900 - 395) : (80 : 16)$
$(976 - 288) : (96 : 12)$	$(712 - 496) : (92 : 23)$

414. Мисаллар дөрес чишелгәннәрме?

$(512 - 257) \times (72 : 24) = 765$	$(856 : 8) \times (95 : 19) = 535$
$(904 - 328) : (68 : 17) = 144$	$(936 : 2) : (87 : 29) = 156$
$(913 - 198) : (75 : 15) = 143$	$(912 : 4) : (94 : 47) = 114$
$(834 - 216) : (57 : 19) = 206$	$(804 : 3) : (76 : 19) = 67$

415. 1) Кушу һәм алу гамәлләре белән чишелә торган мәсьәлә төзергә.

2) Тапкырлау һәм бүлү гамәлләре белән чишелә торган мәсьәлә төзергә.

3) Кушу һәм тапкырлау гамәлләре белән чишелә торган мәсьәлә төзергә.

4) Алу һәм бүлү гамәлләре белән чишелә торган мәсьәлә төзергә.

Күбурынлы саннар.

Күбурынлы саннар нумерациясе.

416. Бер дистәдә ничә берәмлек? Бер йөздә ничә дистә? Бер меңдә ничә йөз?



417. Бер бәйләмдә 1 000 карандаш бар. Шундый ике бәйләмдә ничә карандаш булыр? 3 тә? 4 тә? 5 тә? 6 да? 7 дә? 8 дә? 9 бәйләмдә ничә карандаш булыр?

418. 1) Счётта бер берәмлекне салырга. Бу берәмлеккә, 10 берәмлек килеп чыкканчы, берәр берәмлекне куша барырга. 10 берәмлекне бер дистә белән алмаштырырга.

2) Йөз килеп чыкканчы, счётта дистәгә берәр дистәне куша барырга. Мең килеп чыкканчы, бер йөзгә йөзәрләп кушарга. Тугыз мең килеп чыкканчы, меңгә меңәрләп кушарга.

3) Ике мең килеп чыкканчы, меңгә йөзәрләп кушарга.

419. Сигез мен килеп чыкканчы, меңгә 500 ләп кушарга. Тугыз мең килеп чыкканчы, сигез меңгә 200 ләп кушарга.

420. Бер мең егерме килеп чыкканчы, меңгә берәмләп кушарга.

421. Рәсемдә ничә таякчык?



1 3 4 5

Рәсем астындагы санны укырга.

422. Таблицада язылган саннарны укырга. Аларны счётта салырга.

Берәмлек меңнәр	Йөзләр	Дистәләр	Берәмлекләр
3	4	5	6
6	2	0	5
5	0	4	8
8	0	0	4
5	0	3	0
7	2	0	0

423. Саннарны укырга һәм аларны счётта салырга:

2 768; 4 281; 3 560; 6 400; 1 704; 6 085; 9 040; 7 010; 8 002; 5 003; 4 000; 7 000.

424. Бер мең 3 йөз 6 дистә 2 берәмлектән торган санны әйтергә. 4 мең 7 йөз 5 берәмлектән; 6 мең 9 дистә 1 берәмлектән; 5 мең 4 йөздән; 7 мең 8 дистәдән; 2 мең 9 берәмлектән торган саннарны әйтергә.

425. Түбәндәге саннарны счётта салырга һәм цифрлар белән язарга: өч мең дүрт йөз сиксән бер; алты мең биш йөз; ике мең утыз сигез; биш мең кырык алты; жиде мең егерме; дүрт мең алты; тугыз мең.

426. Бөек Октябрь социалистик революциясе бер мең тугыз йөз унжиденче елда булды.

Бу саннарны цифрлар белән язарга.

427. Үзегез туган елны, мәктәпкә укырга кергән елны цифрлар белән язарга.

428. Түбәндәге саннарны цифрлар белән язарга: өч мең тугыз йөз сиксән җиде; алты мең сигез йөз; биш мең егерме дүрт; ике мең туксан; тугыз мең дүрт; җиде мең сигез; алты мең.

429. (Телдән.) $3\,000+4\,000$ $\quad 1\,000\times5$ $\quad 4\,000:2$

$8\,000-2\,000$ $\quad 4\,000\times2$ $\quad 3\,000:3$

$9\,000-4\,000$ $\quad 3\,000\times3$ $\quad 8\,000:4$

$7\,000-3\,000$ $\quad 2\,000\times4$ $\quad 5\,000:5$

430. 1) Бер километрда 1 000 метр. 3 *км* да ничә метр? 7 *км* да? 9 *км* да?

Язу үрнәге: 3 *км* = 3 000 *м*.

2) 1 *км* 240 *м* ничә метр була? 4 *км* 375 *м*? 6 *км* 80 *м*? 8 *км* 36 *м*? 7 *км* 5 *м*?

Язу үрнәге: 1 *км* 240 *м* = 1 240 *м*.

431. Бер килограммда 1 000 грамм. 2 *кг* да ничә грамм була? 3 *кг* да?

432. (Телдән.) Колхозда 1000 тавык бар иде. Бер елдан соң аларның саны икеләтә артты, ә тагын бер елдан соң 7000 гә артты (узган ел белән чагыштырганда). Колхозда ничә тавык булды?

433. (Телдән.) $5\,000+1\,000-4\,000+3\,000$

$2\,000\times4 : 2+1\,000$

$6\,000 : 3\times4-5\,000$

$8\,000 : 4 : 2-1\,000$

434. 9 берәмлеккә 1 берәмлекне кушсаң, ничә була? Әгәр 9 меңгә 1 меңне кушсаң, ничә була?

435. Бер ящикта 10 мең карандаш бар. Шундый ике ящикта күпме карандаш булыр?

3 тә? 4 тә? 5 тә? 6 да? 7 дә? 8 дә? 9 ящикта ничәшәр карандаш булыр?

436. 1) Дистә мең килеп чыкканчы, счётта бер меңгә меңәрләп кушарга.

2) Тугыз дистә мең килеп чыкканчы, дистә меңгә дистә меңләп кушарга.

437. 1) Егерме мең килеп чыкканчы, счётта ун меңгә 1 000 әрләп кушарга кирәк.

2) Туксан мең килеп чыкканчы, егерме меңгә 5 000 ләп кушарга.

438. Таблицага язылган саннарны укырга. Ул саннарны счётта салырга.

Дистә меңнәр	Берәмлек меңнәр	Йөзләр	Дистәләр	Берәмлекләр
3	5	4	8	2
7	6	0	2	4
5	3	0	0	8
1	0	0	0	0
8	0	5	0	6
3	8	0	7	0

439. Түбәндәге саннарны укырга һәм счётта салырга: 11 111; 34 268; 85 400; 90 803; 72 045; 46 020; 5 100; 50 100; 72 003; 91 000; 8 025.

440. Түбәндәге саннарны счётта салырга һәм цифрлар белән язарга: кырык сигез мең өч йөз сиксән; егерме мең алты йөз утыз; туксан өч мең ике йөз биш; утыз алты мең илле; алтмыш мең сигез; җитмеш мең.

441. Завод җидееллыкның беренче елында унсигез мең өч йөз машина, икенче елында егерме биш мең биш йөз машина эшләп чыгарган. Шушы саннарны цифрлар белән язарга.

442. Түбәндәге саннарны цифрлар белән язарга: утыз биш мең дүрт йөз уналты; сиксән мең өч йөз туксан биш; илле бер мең йөз кырык; җитмеш мең алты йөз; егерме сигез мең утыз биш; туксан мең алтмыш; кырык мең биш; сиксән мең.

443. (Телдән.) 12 000 + 16 000   7 000 × 5   24 000 : 4
28 000 — 13 000   12 000 × 4   68 000 : 2
75 000 — 20 000   16 000 × 6   75 000 : 3

444. (Телдән.) Балалар санаториясе өчен 6 000 сум, пионерлар лагере өчен 2 тапкыр артыграк акча тотылган. Икесенә бергә күпме акча тотылган?

445. (Телдән.) Консерв фабрикасы эшчеләре 4 көндә 12 000 банка консерв хәзерләгәннәр. Әгәр алар һәр көн шулай эшләсәләр, 6 көндә ничә банка консерв хәзерләрләр? 9 көндә ничә банка хәзерләрләр?

446. 9 дистәгә 1 дистәне кушсаң ничә булыр? 9 дистә меңгә 1 дистә меңне кушсаң, ничә булыр?

447. План буенча завод бер айда 100 000 электр лампочкасы эшләп чыгарырга тиеш. Ул 2 айда ничә лампочка эшләргә тиеш? 3 айда? 4 айда? 5 айда? 6 айда? 7 айда? 8 айда? 9 айда ничә лампочка эшләп чыгарырга тиеш?

448. 1) Йөз мең килеп чыкканчы, счётта дистә меңгә дистә меңләп куша барырга.

2) Ун йөз мең яки бер миллион килеп чыкканчы, счётта йөз меңгә йөзәр меңне куша барырга.

449. 1) Ике йөз мең килеп чыкканчы, счётта йөз меңгә 10 000 әрләп куша барырга.

2) Тугыз йөз илле мең килеп чыкканчы, счётта ике йөз меңгә 50 000 әрне куша барырга.

450. Таблицага язылган саннарны укырга. Аларны счётта салырга.

Йөз меңнәр	Дистә меңнәр	Берәмлек меңнәр	Йөзләр	Дистәләр	Берәмлекләр
3	2	5	1	4	0
2	6	1	8	0	0
4	0	5	3	2	0
6	3	0	0	5	0
8	0	0	0	0	0
2	0	0	4	5	0

451. Түбәндәге саннарны укырга һәм аларны счётта салырга:

111 111; 186 436; 214 800; 530 705; 40 060; 600 480; 910 025; 702 008; 500 090; 100 000; 10 001; 320 047; 999 999.

452. Түбәндәге саннарны счётта салырга һәм цифрлар белән язарга: сигез мең биш; кырык җиде мең унике; өч йөз кырык алты мең ике йөз утыз; сигез йөз ун мең дүрт йөз; җиде йөз ике мең өч йөз унике; дүрт йөз мең биш йөз кырык; өч йөз өч мең биш; җиде йөз мең.

453. Барлык цифрларны тәртип буенча язып чыгарга.

Саннар цифрлар белән языла лар.

Бер цифр белән языла торган сан **берурынлы сан** дип атала. Ике цифр белән языла торган саннар **икеурынлы сан** дип атала. Өч цифр белән языла торган саннар **өчурынлы сан** дип атала һ. б. ш.

454. 2, 3, 7, 5 цифрлары белән берничә сан язарга. Алардан иң зурысы кайсы? Иң кечкенәсе кайсы?

455. Иң зур өчурынлы сан язарга; иң зур дүртурынлы сан язарга.

Иң кечкенә бишурынлы сан язарга; иң кечкенә алтыурынлы сан язарга.

456. Китапханәдә йөз утыз сигез мең җиде йөз биш китап бар.

Бу саннарны цифрлар белән язарга. Бу сан ничә цифр белән языла?

457. Түбәндәге саннарны цифрлар белән язарга: биш йөз унике мең сигез йөз уналты; дүрт йөз мең биш йөз җитмеш; бер йөз дүрт мең өч йөз; җиде йөз мең биш йөз; туксан җиде мең алтмыш; алты йөз егерме мең сигез; сигез йөз мең.

458. (Телдән.) Аяк киемнәре фабрикасы бер ел эчендә 60 000 пар ирләр аяк киеме, аңа караганда 40 000 пар артыграк хатын-кызлар аяк киеме, хатын-кызлар аяк киеменә караганда 2 тапкыр артыграк балалар аяк киеме эшләп чыгарды. Фабрика бер ел эчендә ничә пар балалар аяк киеме эшләп чыгарган?

459. (Телдән.)

$200\,000 + 300\,000$	$100\,000 \times 8$	$800\,000 : 2$
$700\,000 - 400\,000$	$300\,000 \times 2$	$600\,000 : 3$

460. 10 *км* ничә метр була? 48 *км*? 72 *км*? 100 *км*? 10 *км* 500 *м* ничә метр була? 32 *км* 200 *м*? 56 *км* 860 *м*? 40 *км* 75 *м*? 60 *км* 50 *м*? 100 *км* 400 *м*?

461. 10 *кг* ничә грамм була? 26 *кг*? 50 *кг*?

462. Саннарны укырга:

2	200	20 000
20	2 000	200 000

463. Түбәндәге саннарны цифрлар белән язарга: 6 берәмлек; 6 дистә; 6 йөз; 6 мең; 6 дистә мең; 6 йөз мең.

464. Саннарны язганда, берәмлекләр уңнан ничәнче урында язылалар? Дистәләр? Йөзләр? Берәмлек меңнәр? Дистә меңнәр? Йөз меңнәр?

> **Гади берәмлекләр** 1 нче разряд берәмлекләре дип аталалар һәм уң яктан **беренче** урында язылалар.
>
> **Дистәләр** 2 нче разряд берәмлекләре дип аталалар һәм **икенче** урында язылалар.
>
> **Йөзләр** 3 нче разряд берәмлекләре дип аталалар һәм **өченче** урында язылалар.
>
> **Берәмлек меңнәр** 4 нче разряд берәмлекләре дип аталалар һәм **дүртенче** урында язылалар.
>
> **Дистә меңнәр** 5 нче разряд берәмлекләре дип аталалар һәм **бишенче** урында язылалар.
>
> **Йөз меңнәр** 6 нчы разряд берәмлекләре дип аталалар һәм **алтынчы** урында язылалар.

465. Уңнан беренче урында торганда, 4 ле цифр нинди санны аңлата? Икенче урында торганда? Өченче урында? Дүртенче урында? Бишенче урында? Уңнан алтынчы урында торганда?

466. 3 нче разрядның 8 берәмлегеннән; 4 нче разрядның 6 берәмлегеннән; 5 нче разрядның 7 берәмлегеннән; 6 нчы разрядның 9 берәмлегеннән торган саннарны цифрлар белән язарга.

467. Түбәндәге саннарны цифрлар белән язарга: җиде мең сиксән; унбиш мең өч йөз; йөз мең дүрт йөз сигез; биш йөз мең туксан алты; өч йөз уналты мең дүрт.

468. 2 нче разрядның 6 берәмлеген; 4 нче разрядның 3 берәмлеген; 5 нче разрядның 1 берәмлеген; 6 нчы разрядның 8 берәмлеген эченә алган саннарны цифрлар белән язарга.

> Разрядлар өчәр разрядтан торган **классларга** төркемләнәләр.
>
> Берәмлекләр, дистәләр һәм йөзләр **берәмлекләр классын** яки **беренче классны** төзиләр.
>
> Берәмлек меңнәр, дистә меңнәр, йөз меңнәр **меңнәр классын** яки **икенче классны** төзиләр.

469. Түбәндәге таблица юлларына язылган саннарны укыгыз. Берәмлектән башлап йөз меңгә кадәр разрядларны тәртип буенча әйтегез. Беренче класс разряд берәмлекләрен һәм икенче класс разряд берәмлекләрен әйтегез.

Икенче класс — меңнәр			Беренче класс — берәмлекләр		
йөзләр	дистәләр	берәмлекләр	йөзләр	дистәләр	берәмлекләр
3	4	5	2	7	6
1	9	0	4	2	5
7	0	0	0	0	0

470. Дәфтәрегезгә класслар һәм разрядлар таблицасын сызыгыз. Күбурынлы биш сан уйлагыз һәм ул саннарны таблицага языгыз.

471. Түбәндәгеләрне эченә алган саннарны цифрлар белән язарга:

1) икенче классның 156 берәмлеген һәм беренче классның 840 берәмлеген;

2) икенче классның 180 берәмлеген һәм беренче классның 300 берәмлеген;

3) икенче классның 92 берәмлеген һәм беренче классның 50 берәмлеген;

4) икенче классның 8 берәмлеген һәм беренче классның 6 берәмлеген.

472. 1) Тәртип буенча санагыз һәм саннарны языгыз:

998 дән башлап 1 003 кә кадәр
9 997 дән „ 10 002 гә „
99 998 дән „ 100 005 кә „

2) Берәмлеккә киметә барып, кирегә санагыз һәм саннарны языгыз:

1 002 дән баш. 996 га кадәр
10 003 тән „ 9 998 гә „
100 004 тән „ 99 997 гә „

473. 1) Йөз меңнән 2 берәмлеккә кимрәк булган санны языгыз.

2) Ун меңнән 3 берәмлеккә кимрәк булган санны языгыз.

3) 9 998 дән соң килә торган өч сан языгыз.

474. Дистәдә ничә берәмлек бар? Йөздә ничә дистә? Меңдә ничә йөз? Дистә меңдә ничә мең? Йөз меңдә ничә дистә мең?

475. 1) Ничә берәмлек бар: 1 дистә 6 берәмлектә? 4 дистә 8 берәмлектә? 7 дистә 5 берәмлектә?

2) Ничә дистә бар: 1 йөз 4 дистәдә? 3 йөздә? 9 йөз 3 дистәдә?

3) Ничә йөз бар: 1 мен 5 йөздә? 2 меңдә? 6 мең 7 йөздә?

4) Ничә мең бар: 1 дистә мең 8 меңдә? 5 дистә мең 4 меңдә?

476.

1) 40 бер. = ... дистә	30 йөз = ... мең.
78 бер. = ... дис. ...бер.	70 йөз = ... мең.
20 дис. = ... йөз.	14 йөз = ... мең ... йөз.
60 дис. = ... йөз.	20 мең = ... дис. мең.
17 дис. = ... йөз ... дис.	25 мең = ... дис. мең ... мең.

2) Түбәндәге саннарның һәрберсендә ничә дистә бар:

72; 354; 600; 1 725; 24 380; 465 825?

3) Түбәндәге саннарның һәрберсендә ничә йөз бар:

100; 800; 925; 2 520; 36 800; 57 284?

477. (Телдән.) Мастерскойда сентябрь аенда 8 000 данә ёлка уенчыгы, октябрьда 4 000 гә артыграк, ноябрьда, сентябрьгә караганда, 2 тапкыр артыграк уенчык хәзерләнгән. Өч айда барысы ничә уенчык хәзерләнгән?

478. Ике магазинның берсенә 3 ящикта, икенчесенә шундый ук 4 ящикта барлыгы 14 000 линейка җибәрелгән. Һәр магазин ничәшәр линейка алган?

479.

324 + 476 + 85	962 — (518 — 379)
290 + 68 + 537	504 — (830 — 648)
816 — (256 + 187)	701 — (912 — 507)
930 — (168 + 375)	621 — (724 — 589)

480.

174 × 5 : 3	528 : 4 × 6	930 : 5 : 3	714 : 3 : 2
246 × 4 : 6	740 : 5 × 3	816 : 2 : 6	912 : 4 : 3
96 × 9 : 8	872 : 8 × 5	756 : 4 : 9	792 : 2 : 9
84 × 6 : 8	792 : 3 × 2	522 : 3 : 2	708 : 4 : 3

481.

(932 — 256) : (68 : 17)	(414 — 135) : 3 × 7
(830 — 345) : (75 : 15)	(906 — 258) : 6 × 9
(915 — 168) : (87 : 29)	(328 + 576) : 2 : 4
(864 — 288) : (84 : 14)	(368 + 496) : 4 : 3

Озынлык үлчәү берәмлекләре.

Дециметр



482. Кәгазьдән дециметр ясагыз, аны сантиметрларга бүлегез. Бер дециметрда ничә сантиметр бар?

Сантиметрны 10 тигез өлешкә бүлегез.

Сантиметрның унынчы өлеше миллиметр дип атала. „Миллиметр" сүзе сан янында килгәндә кыскача *мм* (нокта куелмыйча) дип языла: мәсәлән, 2 *мм*, 6 *мм*, 39 *мм*.

1 *см* = 10 *мм*.

483. Бер сантиметрда 10 *мм* була; 2 *см*; 4 *см*; 8 *см* һәм 5 сантиметрның һәрберсендә ничәшәр миллиметр була?

1 *дм*; 4 *дм*; 7 *дм* ның һәркайсында ничәшәр миллиметр була?

1 *м*; 2 *м*; 5 *м*; 7 *м*; 9 метрның һәркайсында ничәшәр миллиметр була?

484. Дәфтәр һәм дәреслекнең буен, иңен, карандаш һәм каләмнең озынлыгын үлчәп, миллиметрлар белән әйтегез.

485. Түбәндәге сызыкларны үлчәгез һәм аларның ничә миллиметр икәнен әйтегез:

Озынлык үлчәү берәмлекләре таблицасы.

Исемнәрнең тулы язылышы	Исемнәрнең кыскача язылышы
1 километр = 1 000 метрга	1 *км* = 1 000 *м*
1 метр = 10 дециметрга, яки 100 сантиметрга	1 *м* = 10 *дм* = 100 *см*
1 дециметр = 10 сантиметрга	1 *дм* = 10 *см*
1 сантиметр = 10 миллиметрга	1 *см* = 10 *мм*

486. Калын кәгазь яки картоннан метр ясагыз. Аны дециметр һәм сантиметрларга бүлегез. Бер сантиметрны миллиметрларга бүлегез.

487. Класс бүлмәсенең һәм класс тактасының буен, иңен үлчәгез. Үлчәү нәтиҗәсен метрлар һәм сантиметрлар белән әйтегез.



488. Бүлмәгезнең буен һәм иңен үлчәгез. Үзегезнең буегызны үлчәгез. Үлчәү нәтиҗәләрен дәфтәрегезгә язып куегыз.

489. Рәсемдә күрсәтелгән кадакның, шөрепнең һәм заклепканың озынлыгын үлчәп, миллиметрлар белән әйтегез.

490. 1) Тактага 1 *дм* озынлыктагы; 4 *дм*, 5 *дм* 6 *см* озынлыктагы туры сызыклар сызыгыз.

2) Дәфтәрегезгә 1 *дм* 2 *см*; 4 *см* 8 *мм*; 4 *мм* озынлыктагы туры сызыклар сызыгыз.

491. Өстәлнең буен һәм иңен, дәфтәрнең буен һәм иңен, карандашның озынлыгын күз белән чамалап билгеләгез, аннан соң һәрберсен үлчәп, тикшереп карагыз. Сез ялгышкансызмы һәм күпмегә ялгышкансыз?

492. Күз белән чамалап ишек алды яки яшелчә бакчагызның озынлыгын билгеләгез. Соңыннан метр белән үлчәп карагыз. Күпмегә ялгышкансыз?

493. 1) Линейкада 2 *дм* ны күрсәтегез. Бу ничә сантиметр була? Ничә миллиметр була?

2) Линейкада 2 *дм* 8 *см* ны күрсәтегез. Бу ничә сантиметр була? Ничә миллиметр була?

494. Эре үлчәү берәмлекләрен ваграк үлчәү берәмлекләре белән алмаштырыгыз:

1)	5 *км* = 5 000 *м*	2 *м* = 200 *см*	3 *см* = 30 *мм*
	9 *км* =	7 *м* =	5 *см* =
	2 *км* =	4 *м* =	8 *дм* =
	4 *км* =	6 *м* =	9 *дм* =
2)	1 *км* 500 *м* =	2 *м* 50 *см* =	1 *дм* 5 *мм* =
	4 *км* 750 *м* =	5 *м* 28 *см* =	1 *см* 5 *мм* =
	6 *км* 258 *м* =	8 *м* 75 *см* =	6 *см* 8 *мм* =

495. 1) Кирпечнең буе 2 *дм* 5 *см*, иңе 1 *дм* 2 *см*, калынлыгы 6 *см* 2 *мм*. Кирпечнең буен, иңен, калынлыгын миллиметрларда әйтегез.

2) Тәрәзә пыяласының буе 1 *м* 3 *см*, иңе 6 *дм*, калынлыгы 2 *мм*. Пыяланың буен, иңен, калынлыгын миллиметрларда әйтегез.

496. Ике йөзүче бер-берсенә каршы йөзеп килә. Башта йөзүчеләр арасында ераклык 1 *км* иде. Бер йөзүче 360 *м*, икенчесе 400 *м* йөзгәч, алар арасындагы ераклык ничә метр калган?

497. Эшчеләр бер көндә 2 *км* таш юлны төзәттеләр. Моннан соң тагын 200 *м* юл төзәтәселәре калды. Аларга барлыгы ничә метр юл төзәтергә кирәк булган?

498. Пионерлар походта 7 *км* 500 *м* юл үттеләр. Бу ничә метр була?

499. Метрда 80 *см* ны күрсәтегез. Бу ничә дециметр була?

Метрда 200 *мм* ны күрсәтегез. Бу ничә дециметр була? Ничә сантиметр була?

500. 3 000 *м* да, 5 000 *м* да, 9 000 *м* да ничәшәр километр була? 400 *см* да, 600 *см* да, 800 *см* да ничә метр?

30 *мм* да, 60 *мм* да, 100 *мм* да, 200 *мм* да ничәшәр сантиметр була?

501. Вак үлчәү берәмлекләрен эрерәк үлчәү берәмлекләре белән алмаштырыгыз:

4 000 *м* = 4 *км*	200 *см* = 2 *м*	50 *мм* = 5 *см*
7 000 *м* =	800 *см* =	90 *мм* =
10 000 *м* =	1 000 *см* =	120 *мм* =
25 000 *м* =	1 800 *см* =	200 *мм* =

502. ТУ-104 самолёты 12 000 *м* биеклектә оча. Бу ничә километр була?

503. 1) Буйга сикерүнең иң зуры 813 *см*, биеклеккә сикерүнең — 222 *см* (бөтендөнья рекордлары). Бу зурлыкларны метрлар һәм сантиметрларда аңлатыгыз. Үзегезнең классыгызда күрсәтегез.

2) Буйга һәм биеклеккә сикерүдә сезнең казанышларыгыз ничек?

504. Укучы рәсемдәгечә итеп китап шүрлеге ясарга теләи. Аны ясар өчен, ничә метр такта кирәк булыр?





505. Бер малай, рәсемдә күрсәтелгәнчә итеп, чана ясарга уйлый. Шундый чана ясау өчен, ничә метр такта кирәк булыр?

506.

$(258+693):3$	$(348+594):6$	$845:5\times3$
$(185+590):5$	$(912-144):4$	$288:3\times4$
$(455+189):7$	$(704-136):8$	$658:7\times8$
$(378+534):6$	$(981-567):9$	$856:8\times9$

Авырлык үлчәү берәмлекләре.

507. 1 *кг* ком, 300 *г* ком, 750 *г* ком үлчәгез.

508. 1) Рәсемгә карап капчыктагы ярманың нинди авырлыкта икәнен белегез.

2) Буш шешәнең авырлыгы 310 *г* килә. Шешәдәге майның авырлыгын белегез.





509. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә 500 *г* лы гер, икенче тәлинкәсенә 300 *г* шикәр куелган. Үлчәү тигезләнсен өчен ничә грамм шикәр өстәргә кирәк?

510. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә бал салынган банка, икенче тәлинкәсенә 1 *кг* лы гер куелган. Үлчәү тәлинкәләре

тигез торалар. Әгәр банка 300 *г* авырлыкта булса, бал нинди авырлыкта булыр?

511. Кечкенә уенчык үлчәү ясагыз.



Җиңел әйберләрне килограмм һәм граммнар белән, авыр әйберләрне **центнерлар** һәм **тонналар** белән үлчиләр.

Центнерда 100 килограмм.

Тоннада 1000 килограмм.

„Центнер“ сүзе сан янында килгәндә кыскача *ц* дип (нокта куймыйча) языла. Мәсәлән: 3 *ц*, 6 *ц*, 19 *ц*.

„Тонна“ сүзе сан янында килгәндә кыскача *т* дип (нокта куймыйча) языла. Мәсәлән: 4 *т*, 7 *т*, 15 *т*.

512. Укып чыгыгыз:

1 *ц*	1 *т*	2 *ц* 10 *кг*	3 *т* 6 *ц*
6 *ц*	8 *т*	10 *ц* 5 *кг*	5 *т* 8 *ц*
9 *ц*	16 *т*	3 *ц*	9 *т* 4 *ц*

Авырлык үлчәү берәмлекләре таблицасы.

Исемнәрнең тулы язылышы	Исемнәрнең кыскача язылышы
1 тонна = 1 000 килограмм, яки 10 центнер	1 *т* = 1 000 *кг* = 10 *ц*
1 центнер = 100 килограмм	1 *ц* = 100 *кг*
1 килограмм = 1 000 грамм	1 *кг* = 1 000 *г*

513. Бер центнер булсын өчен, 50 *кг* лы ничә капчык бәрәңге алырга кирәк?



514. Бер тонна булсын өчен, 100 әр *кг* лы ничә капчык шикәр комы алырга кирәк?

515. 2 *т*, 5 *т*, 8 *т*, 10 тоннаның һәркайсында ничәшәр килограмм?

3 *ц*, 6 *ц*, 9 *ц*, 10 центнерның һәркайсында ничәшәр килограмм?

516.

2 *т* = 20 *ц*	3 *т* = 3 000 *кг*	2 *ц* = 200 *кг*
4 *т* =	5 *т* =	4 *ц* =
6 *т* =	7 *т* =	7 *ц* =
8 *т* =	9 *т* =	5 *ц* =

517.

2 *т* 8 *ц* = 28 *ц*	3 *ц* 50 *кг* = 350 *кг*	4 *т* 200 *кг* = 4 200 *кг*
5 *т* 5 *ц* =	6 *ц* 20 *кг* =	5 *т* 400 *кг* =
8 *т* 4 *ц* =	8 *ц* 45 *кг* =	8 *т* 756 *кг* =

518. 3 *ц* 26 *кг* да ничә килограмм бар? 8 *ц* 50 *кг* да? 4 *т* 200 *кг* да? 7 *т* 856 *кг* да?

519. Колхоз кышка түбәндәге яшелчәләрне хәзерләде:

Бәрәңге	15 *т*
Кәбестә	28 *т*
Кыяр	9 *ц*
Кишер	7 *ц*
Суган	5 *ц*

Барлык яшелчәләрне түбәндәге үрнәк буенча килограммнар белән күрсәтегез:

15 *т* = 15 000 *кг*.

520. Колхозда хезмәт көненә ашлык бүлделәр:

бер колхозчыга... 4 *ц* 85 *кг*,
икенче колхозчыга... 5 *ц* 50 *кг*,
өченче „ „ ... 6 *ц* 78 *кг*.

Һәрбер колхозчы ничә килограмм ашлык алган?

521. 3 000 *кг* ның; 6 000 *кг* ның; 9 000 *кг* ның һәрберсендә ничәшәр тонна бар? 200 *кг* ның; 500 *кг* ның; 700 *кг* ның һәрберсендә ничәшәр центнер бар?

2 000 *г*; 4 000 *г*; 8 000 *г* ның һәрберсе ничә килограммга тигез булыр?

522. Йөк автомобиленә 4 600 *кг* бәрәңге төяделәр. Бу йөк ничә тонна һәм ничә килограмм булыр?

523. Җирнең Советлар иле җибәргән өченче ясалма иярчене 1 327 *кг* авырлыкта. Бу үлчәүне тонна һәм килограммнарда әйтегез.

524. Магазин 3 көндә 1 *т* шикәр сатты. Беренче көнне 300 *кг*, икенче көнне 2 тапкыр артыграк. Өченче көнне ничә килограмм шикәр сатылган?

525. Өч участоктан 1 *т* бәрәңге җыйганнар; беренче участоктан 450 *кг*, икенчесеннән 3 тапкыр кимрәк. Өченче участоктан ничә килограмм бәрәңге җыелган?

526. Икенче классның 40 берәмлеген һәм беренче классның 76 берәмлеген;

икенче классның 806 берәмлеген һәм беренче классның 5 берәмлеген эченә алган саннарны цифрлар белән язарга.

527. 567 + 389	139 + 206 + 387	325 + 47 + 288
608 + 298	405 + 168 + 54	96 + 175 + 549
487 + 96	194 + 307 + 86	85 + 667 + 54
75 + 829	77 + 584 + 59	49 + 708 + 66

Күбурынлы саннарны кушу.

528. Укучыларның бер бригадасы колхозда 1 312 хезмәт көне, икенчесе 1 245 хезмәт көне эшләде. Ике бригада ничә хезмәт көне эшләгән?

529. Беренче кушылучы 3 241, икенче кушылучы 1 635. Бу саннарның суммасын табарга.

530. 7 346 + 1 452	34 265 + 23 724	324 715 + 253 164
6 581 + 315	80 461 + 19 328	456 028 + 42 051
9 065 + 723	56 070 + 3 624	35 704 + 124 085
841 + 4 057	7 306 + 41 092	8 092 + 631 607

531. Типография бер көндә 13 140 дәреслек, икенче көнне 1 205 дәреслек артыграк басып чыгарды. Мәсьәләгә, ике гамәл белән чишелерлек итеп, сорау куегыз.

532. Бер китапханәдә 40 750 китап, икенчесендә 24 135, өченчесендә 32 608 китап бар иде. Бер ел эчендә беренче китапханәгә 4 235 китап, икенчесенә — 5 360, өченчесенә 6 090 китап өстәлде. Шуннан соң һәрбер китапханәдә ничәшәр китап булган?

533. Телдән чишегез:

8 + 7	80 + 70	800 + 700	8 000 + 7 000
6 + 9	60 + 90	600 + 900	6 000 + 9 000

534.

3 462 + 5 218	45 824 + 32 069
2 634 + 6 293	241 452 + 56 397
7 456 + 830	604 736 + 103 853
935 + 8 625	74 527 + 806 371

535. Завод сентябрь аенда 1 380 машина, октябрьда, сентябрьгә караганда, 250 машина артыграк, ноябрьда, октябрьга караганда, 275 машина артыграк эшләп чыгарды. Завод ноябрь аенда ничә машина эшләп чыгарган?

536. 1) Кукурузның яшел массасын бер участоктан 12 340 *ц*, икенче участоктан 4 850 *ц* артыграк җыеп алдылар. Ике участоктан күпме яшел масса җыеп алганнар?

2) Бер участоктан 1 065 *ц*, икенчесеннән 328 *ц* артыграк кукуруз бөртеге җыеп алдылар. Ике участоктан күпме кукуруз бөртеге җыеп алганнар?



537.

37 284 + 2 507
5 052 + 32 675
248 724 + 534 163

128 × 6 + 950
932 − 186 + 872
705 − 248 + 529

538. 1) Бу квадратлар кызыклы квадрат була алалармы, тикшереп карагыз

100	800	300
600	400	200
500	0	700

600	100	800
700	500	300
200	900	400

2) Беренче квадраттагы һәрбер санга 100 әрне кушыгыз, килеп чыккан кызыклы квадратны дәфтәрегезгә язызыз. Һәрбер рәттәге саннарны кушудан килеп чыккан нәтиҗәне күңелдән исәпләгез.

3) Шул юл белән тагын берничә кызыклы квадрат төзегез һәм теләсә нинди рәттәге саннарны кушкач, ничә килеп чыкканын исәпләгез.

539.

$865 + 479$	$423\,486 + 59\,344$
$3\,725 + 4\,185$	$82\,764 + 647\,538$
$7\,856 + 308$	$574\,807 + 346\,196$
$297 + 9\,856$	$5\,098 + 726\,907$

540. Совхоз дәүләткә өч көндә 286 шар *т* ашлык тапшырган. Шуннан соң тагын 750 *т* ашлык тапшырасы калган. Совхоз дәүләткә барлыгы ничә тонна ашлык тапшырырга тиеш булган?

541. Колхозда дүрт айда 236 шар *т* силос тотылган. Ай саен 245 әр *т* тотылса, калган силос тагын 3 айга җитәчәк. Колхоз барысы күпме силос хәзерләгән?

542.

$45\,968 + 7\,275$	$834 : 6 \times 4 + 978$
$72\,405 + 89\,097$	$576 : 4 \times 5 + 865$
$356\,078 + 495\,824$	$900 - 356 + 759$

543. Түгәрәкләү юлы белән телдән чишегез:

$36 + 19$	$58 + 99$	$199 + 65$	$199 + 135$
$49 + 28$	$99 + 73$	$399 + 86$	$248 + 199$

544. Кушу гамәлен счётка салып эшләгез һәм дөреслеген телдән яки язып тикшерегез:



6 + 3	6 + 4	7 + 8
42 + 4	2 + 8	9 + 6
30 + 20	76 + 4	36 + 28
56 + 23	57 + 33	65 + 27
600 + 300	80 + 20	80 + 60
546 + 253	126 + 174	185 + 368
328 + 460	482 + 318	274 + 507

545. 14 һәм 18 саннарының суммасы ничәгә тигез?
18 һәм 14 саннарының суммасы ничәгә тигез?

546. Кушылучыларны төрле тәртиптә куеп, кушып карагыз:

$$1)\ \begin{array}{r} +\,3\,256 \\ 2\,731 \\ \hline \end{array} \qquad 2)\ \begin{array}{r} +\,2\,731 \\ 3\,256 \\ \hline \end{array}$$

Кушылучыларның урыннарын алмаштырудан сумма үзгәрми.

Кушуның дөреслеген тикшерү өчен, кушылучыларның урыннарын алмаштырып кушалар. Әгәр шул ук сумма килеп чыкса, гамәл дөрес эшләнгән була.

547. Кушыгыз һәм дөреслеген тикшерегез:

5 764 + 4 385	67 485 + 93 076	135 476 + 674 865
9 807 + 6 098	9 758 + 74 509	706 593 + 95 308

548. Урманның бер участогында 1 645 төп агач үсә иде, алар янына тагын 1 280 төп агач утырттылар. Икенче участокта 1 280 төп агач үсә иде, тагын элеккедән 365 төп артыграк агач утырттылар. Утыртканнан соң һәрбер участокта ничә төп агач булды?

Ни өчен ике очракта да бер үк сумма килеп чыкты?

549. Кушылучыларның урыннарын алмаштыру юлы белән телдән чишегез:

$92 + 56 + 8 = (92 + 8) + 56 = 100 + 56 = 156$

95 + 67 + 5	64 + 77 + 36	75 + 56 + 25 + 44
88 + 53 + 12	52 + 93 + 48	6 + 87 + 13 + 94

550.

3 576 + 4 892 + 540 + 62	37 284 + 65 704 + 8 056
6 954 + 276 + 9 085	7 720 + 36 455 + 270 590
2 896 + 675 + 8 049	45 638 + 240 196 + 755
507 + 9 478 + 637	186 512 + 7 028 + 76 093

551. Аяк киемнәре мастерскоенда бер айда 940 пар ирләр аяк киеме, аңа караганда 185 пар кимрәк хатын-кызлар аяк киеме, хатын-кызлар аяк киеменә караганда 236 парга кимрәк балалар аяк киеме төзәткәннәр. Бер айда барлыгы ничә пар аяк киеме төзәткәннәр?

552. Колхоз 1 126 *т* бодай, аннан 178 *т* кимрәк арыш, арыштан 2 тапкыр кимрәк арпа җыеп алган. Колхоз барлыгы күпме ашлык җыеп алган?

553. Дубовкадан Аксёновка кадәр 176 *км*, Аксёновтан Берёзовкага кадәр ике тапкыр якынрак, Берёзовкадан Колосовога кадәр, Дубовка белән Аксёнов арасына караганда, өч тапкыр ераграк, Дубовкадан Колосовога кадәр булган ераклыкны билгеләргә.



554.

488 + 573 + 6 345	942 — 576 + 1 548	625 — 386
42 755 + 37 648 + 8 470	801 — 465 + 75 634	902 — 798
36 080 + 9 875 + 7 069	732 — 335 + 68 049	514 — 388
8 475 + 53 098 + 3 706	900 — 597 + 92 708	700 — 406

555. Машиналар төнлә гаражда булганнар. Иртә белән 12 машина эшкә чыккан, 3 машина гаражда калган. Төнлә гаражда ничә машина булган?

Бу мәсьәләдә барлык машиналар саны б и л г е с е з. Бу билгесез машиналар санын x (икс) хәрефе белән күрсәтәбез дә мәсьәләнең шартын түбәндәгечә язабыз:

$$x - 12 = 3.$$

Бу мәсьәләдә билгесезне табу өчен гаражда калган 3 машина санына эшкә чыгып киткән 12 машина санын кушарга кирәк.

3 маш. + 12 маш. = 15 маш.

Димәк, билгесез машиналар саны (x) 15 кә тигез.

$$x = 15.$$

Дөреслеген тикшерү өчен, мәсьәләнең шартына x урынына 15 санын куйсак:

$$15-12=3$$

килеп чыга.

556. Түбәндәге мисалларның һәрберсендә нәрсә билгеле, нәрсә билгесез:

$x-18=6$	$x-120=40$	$x-978=1\,232$
$x-25=75$	$x-360=140$	$x-769=864$
$x-86=14$	$x-400=600$	$x-827=3\,038$

Билгесез санны табыгыз, аннан соң дөреслеген тикшерегез.

557. Кушу гамәлен башта счётта эшләгез, аннан соң язып дөреслеген тикшерегез:

$364+230$	$234+416$	$464+328$
$214+475$	$625+581$	$571+258$
$1\,342+2\,647$	$1\,546+3\,436$	$4\,398+3\,476$
$3\,526+4\,343$	$4\,738+5\,170$	$2\,724+5\,197$

Күбурынлы саннарны алу.

558. Укучылар 1 675 *кг* көл җыярга булдылар. Алар инде 1 250 *кг* җыйдылар. Аларның тагын ничә килограмм көл җыясылары калды?

559. 1) Кимүче 5 786, киметүче 3 152. Аерманы табарга.

2) Кимүче 9 768, киметүче 527. Аерманы табарга.

560.

$74\,685-32\,565$	$38\,726-15\,714$	$568\,794-315\,402$
$48\,906-5\,703$	$65\,907-4\,305$	$685\,307-24\,105$

561. Складта 1 875 *т* нефть, аңа караганда 623 *т* кимрәк бензин, нефтькә караганда 744 *т* кимрәк керосин бар. Складта барлыгы ничә тонна нефть, бензин һәм керосин бар?

562.

$487\,045-236\,025$	$5\,760+34\,896-10\,546$
$960\,876-45\,621$	$54\,805-3\,602+78\,968$

563. 1) Кимүче 110, киметүче 30. Аерманы табарга.

2) Аермалары 50 гә тигез булган ике сан әйтегез.

564. Кассада 5 872 сум акча булган. Шуннан 2 348 сумы бирелгән. Кассада күпме акча калган?

565.

$8\,756-4\,128$	$54\,728-31\,564$	$64\,059-50\,724$
$9\,580-6\,345$	$85\,607-20\,350$	$96\,408-32\,905$

566. 460 785 — 315 412   856 948 — 675 302   35 784 — 8 560
581 398 — 238 176   609 703 — 188 401   286 320 — 54 910

567. Кирпеч кипкәнче 4 500 *г* авырлыкта килә. Кипкәннән соң 800 *г* авырлыгын югалта, яндыргач, тагын 200 *г* авырлыгын югалта. Яндырылган кирпеч нинди авырлыкта булыр?

568. Тегермән бер айга план буенча 2 795 *ц* он тартырга тиеш иде. Айның беренче яртысында 1 460 *ц*, ә икенче яртысында 35 *ц* га артыграк он тартты. Айлык план ничә центнерга арттырып үтәлгән?

569. 36 836 — 5 219   372 : 4 × 9 — 375
87 504 — 63 283   855 : 9 × 7 — 490
376 160 — 35 420   736 : 8 × 9 — 356

570. Кызыклы квадратларда нинди саннар җитми?

30	100	50
70		90

40		80
	50	
		60

571. Аралары 1 382 *км* булган ике шәһәрдән бер-берсенә каршы ике пароход юлга чыккан. Очрашканга кадәр беренче пароход 756 *км* юл үткән. Икенче пароход ничә километр юл үткән? (Мәсьәләгә сызым сызыгыз.)

572. 4 324 — 186   34 820 — 756   320 425 — 2 235
9 540 — 375   68 702 — 3 982   572 348 — 7 199
8 127 — 4 937   92 376 — 80 288   814 603 — 48 572
7 230 — 6 895   89 480 — 52 584   634 270 — 218 894

573. 1) Мәскәүдән Чиләбегә кадәр 1 909 *км*. Мәскәүдән Ульяновскига 894 *км*, Ульяновскидан Уфага 626 *км*. Уфадан Чиләбегә кадәр ничә километр?

2) Сезгә якын тимер юл буенда булган шәһәрләр арасындагы ераклык турында мәсьәлә төзегез.

574. 5 214 − 834 42 352 − 560 351 614 − 744
6 022 − 4 516 75 134 − 9 728 816 276 − 29 498
7 286 − 6 295 81 263 − 18 894 638 547 − 560 478

575. 1) Чаңгычылар ярышында шәһәр мәктәпләреннән 200 укучы, авыл мәктәпләреннән 180 укучы катнашты. Бу ярышта барлыгы ничә укучы катнашкан?

2) Чаңгычылар ярышында 380 укучы катнашты, шулардан 200 укучы шәһәр мәктәпләреннән, калганнары авыл мәктәпләреннән. Чаңгы ярышына авыл мәктәпләреннән ничә укучы катнашкан?

Бу мәсьәләләрнең чишелешләрен чагыштырып карагыз. Әгәр суммадан ике кушылучының берсен алсаң, нәрсә килеп чыга? Билгесез кушылучыны ничек табып була?

576. Һәр мисалда нәрсә билгеле һәм нәрсә билгесез:

$30 + x = 80$ $x + 60 = 100$ $x + 752 = 930$
$25 + x = 40$ $x + 50 = 120$ $684 + x = 1\,190$

Билгесез санны табарга, соңыннан аның дөреслеген тикшереп карарга.

577. 1) Кушу: Кушуның дөреслеген тикшерү:
$25 + 17 = 42$ $42 - 25 = 17$ яки $42 - 17 = 25$

2) Кушу: Кушуның дөреслеген тикшерү:

$$\begin{array}{r} 356 \\ +\ 238 \\ \hline 594 \end{array} \qquad \begin{array}{r} 594 \\ -\ 356 \\ \hline 238 \end{array} \quad \text{яки} \quad \begin{array}{r} 594 \\ -\ 238 \\ \hline 356 \end{array}$$

Ике кушылучы суммасының дөреслеген тикшерү өчен, суммадан кушылучыларның берсен алалар. Шуннан соң икенче кушылучы килеп чыкса, гамәл дөрес эшләнгән була.

578. Кушу гамәлен эшләгез һәм дөреслеген алу гамәле белән тикшерегез:

1 356 + 5 238 356 472 + 21 815
37 642 + 1 285 632 543 + 239 306

Кушуның дөреслеген тагын ничек тикшереп була?

579. Кушу гамәлен эшләгез һәм дөреслеген кушу белән тикшерегез:

7 536 + 5 960 32 148 + 19 237 756 237 + 109 794

580. Кушу гамәлен эшләгез һәм башта кушу белән, аннан соң алу белән дөреслеген тикшерегез:

$5\,708 + 6\,970$	$37\,653 + 96\,077$	$247\,380 + 39\,605$
$28\,954 + 4\,280$	$215\,488 + 56\,904$	$805\,692 + 190\,706$

581. (Телдән.) Велосипедта баручы 3 сәгатьтә 37 *км* юл үткән. Беренче сәгатьтә 14 *км*, ә беренче һәм икенче сәгатьләрдә 26 *км* юл үткән. Ул икенче сәгатьтә һәм өченче сәгатьтә ничәшәр километр юл үткән?



582. Өч отряд пионерлары 160 *кг* гөлҗимеш җыйганнар. Беренче отряд 63 *кг*, беренче белән икенче отряд бергә 112 *кг* җыйганнар. Икенче отряд күпме һәм өченче отряд күпме гөлҗимеш җыйган? (Мәсьәләгә сызым сызыгыз.)

583. Эшче алган хезмәт хакының 28 сумын саклык кассасына салды. Шуннан соң аның үзендә 72 сум акчасы калды. Эшче күпме хезмәт хакы алган?

584. Һәрбер мисалда нәрсә билгеле, нәрсә билгесез:

$x - 40 = 60$	$x - 200 = 300$	$x - 258 = 134$
$x - 90 = 20$	$x - 140 = 120$	$x - 365 = 280$
$x - 80 = 80$	$x - 530 = 680$	$x - 254 = 636$

Билгесез санны табыгыз, аннан соң тикшереп карагыз, дөрес табылганмы?

585. Колхозда терлекләр өчен кыш буена 560 *т* печән һәм 825 *т* тамыразык тотылган. Язга 148 *т* печән һәм 215 *т* тамыразык калган. Күпме печән һәм күпме тамыразык хәзерләнгән булган?

586. Колхозда терлекләр өчен 708 *т* печән һәм 1 040 *т* тамыразык хәзерләнгән булган. Язга 148 *т* печән һәм 215 *т* тамыразык калган. Кыш буенча терлекләргә күпме печән һәм күпме тамыразык ашатылган?

587. Түгәрәкләү юлы белән телдән чишегез:

$74 - 9$	$96 - 39$	$126 - 99$	$235 - 99$
$53 - 19$	$94 - 69$	$168 - 99$	$618 - 99$

588. Алу: Алуның дөреслеген тикшерү:

$$\begin{array}{r} - \begin{array}{r} 782 \\ 524 \\ \hline 258 \end{array} \end{array} \qquad \begin{array}{r} + \begin{array}{r} 524 \\ 258 \\ \hline 782 \end{array} \end{array}$$

Алу гамәленең дөреслеген тикшерү өчен, киметүче белән аерманы кушарга кирәк.

Әгәр кимүче килеп чыкса, гамәл дөрес эшләнгән була.

589. Алу гамәлен эшләгез һәм дөреслеген кушу юлы белән тикшерегез:

7 892 — 3 578 35 680 — 15 496 136 857 — 82 385

590. Варенье кайнату өчен фабрикага 9 *ц* кура җиләге китерелгән иде. Көн азагына 20 шәр *кг* лы 7 кәрзин кура җиләге калды. Бер көндә ничә килограмм кура җиләге кайнатылган? (9 *ц* ны килограммнар белән алмаштырырга.)

591. Пекарняга 1 380 *кг* он китерелгән. Көн азагына анда 72 шәр *кг* лы 8 капчык он калган. Бер көн эчендә ничә килограмм он тотылган?

592. Алу гамәлен эшләгез һәм кушу юлы белән дөреслеген тикшерегез:

36 786 — 3 958 128 490 — 65 385 275 682 — 136 496

593. Кушу гамәлен эшләгез һәм алу юлы белән дөреслеген тикшерегез:

45 385 + 78 109 236 720 + 58 096 314 945 + 146 038

594. Алу гамәлен счётта эшләгез һәм нәтиҗәнең дөреслеген телдән исәпләп тикшерегез:

8 — 3	10 — 8	12 — 8	85 — 37
36 — 4	10 — 6	16 — 9	61 — 24
50 — 30	10 — 4	15 — 7	92 — 56
68 — 42	20 — 7	25 — 8	72 — 36
700 — 300	50 — 8	62 — 4	100 — 74
685 — 243	100 — 2	100 — 20	100 — 82
964 — 702	100 — 8	100 — 80	100 — 29

595. Телдән чишегез:

1 дис.— 1 бер.	40 — 1	4 000 — 2
1 йөз — 1 дис.	200 — 1	6 000 — 5
1 мең — 1 йөз	3 000 — 1	8 000 — 4

596.

4 001 — 5	5 000 — 24	3 000 — 238	7 010 — 809
7 100 — 8	7 003 — 76	6 004 — 654	9 200 — 436
8 010 — 8	9 102 — 57	8 102 — 308	5 010 — 678

597.

804 — 36	5 004 — 8	8 010 — 5 076	7 000 — 5 692
701 — 428	6 005 — 36	9 004 — 6 908	4 000 — 1 079
900 — 708	7 001 — 275	5 003 — 4 048	9 000 — 3 096
600 — 356	8 003 — 386	7 005 — 3 407	6 000 — 4 805

598. Колхозчыларның хезмәт көннәренә 1 000 *т* бодай, бодайга караганда 673 *т* ким арыш, арышка караганда өч тапкыр ким арпа бирелгән. Колхозчыларга барлыгы күпме ашлык бирелгән?

599. 8, 864 һәм 2 400 саннары бирелгән. Беренче сан икенче саннан ничә тапкыр кечерәк? Икенче сан өченче саннан ничәгә кечерәк?

600.

4 025 — 1 680	8 000 — 2 946	7 002 — 3 458	134 × 6 — 596
3 042 — 2 792	6 000 — 4 085	9 004 — 6 082	139 × 7 — 178

601. (Телдән.) Түбәндәге саннарның һәрберсен 2 берәмлеккә киметергә: 5 000, 8 600, 10 000, 100 000.

602.

30 004 — 6	42 003 — 365	80 100 — 4 768	200 000 — 38 604
50 100 — 9	75 000 — 684	53 004 — 8 096	920 000 — 40 592
91 002 — 37	60 201 — 162	70 201 — 5 965	804 004 — 86 096
40 010 — 56	10 100 — 875	60 001 — 7 006	408 010 — 73 508

603. Кимүче 60 005, киметүче 80. Аерманы табарга.

604.

40 001 — 4	70 100 — 32 065	300 000 — 135 246
60 004 — 86	99 010 — 64 928	400 005 — 75 098
80 003 — 908	50 100 — 7 096	600 010 — 95 492
40 000 — 756	10 000 — 9 072	100 000 — 59 605

605. Өч баржада 3 020 *т* ашлык китерелгән: беренче баржада 1 306 *т*, икенчесендә, беренчегә караганда, 128 *т* кимрәк. Өченче баржада күпме ашлык китерелгән?

Күрсәтмә. Чишелешнең дөреслеген тикшерегез. Өч баржаның һәрберсендә китерелгән барлык ашлыкны кушыгыз. Әгәр суммада 3 020 *т* килеп чыкса, мәсьәлә дөрес чишелгән булыр.



606. Урманның өч участогында 5 060 төп агач үсә: шулардан беренче участокта 1 570 төп агач, икенче участокта, беренчегә караганда, 240 төп агач артыграк үсә. Өченче участокта ничә төп агач үсә? (Чишелешнең дөреслеген тикшерегез.)

607.

70 000 — 56 082	500 100 — 84 796	234 × 3 — 493
80 002 — 48 944	900 010 — 370 568	118 × 6 — 549
60 100 — 3 908	701 001 — 398 025	176 × 4 — 308
20 000 — 5 964	600 000 — 529 720	326 × 3 — 506

608.

27 000 — 19 824	301 000 — 75 408	992 : 4 — 198
39 100 — 24 386	405 100 — 37 006	784 : 2 — 296
75 001 — 36 792	800 001 — 130 708	864 : 3 — 189
80 030 — 59 864	604 105 — 265 007	972 : 2 — 307

609. Алу гамәлен счётта эшләгез һәм дөреслеген язып тикшерегез:

984 — 342	840 — 328	724 — 509	400 — 246
756 — 525	760 — 547	645 — 356	802 — 576
4 075 — 3 024	3 480 — 1 356	7 245 — 1 088	4 600 — 2 428
5 696 — 4 506	9 870 — 6 529	9 425 — 3 642	8 904 — 6 875

610. Фабрика посёлогында 2 иске мәктәп һәм 3 яңа мәктәп бинасы бар. Иске бинаның һәрберсендә 135 әр бала укый. Яңа биналарның берсендә 685 бала, икенчесендә 756 бала, өченчесендә, икенчегә караганда, 119 бала артыграк укый. Яңа биналарның барсында, иске биналарга караганда, ничә бала артыграк укый?

611. Лётчик өч көндә 5 960 *км* очкан. Беренче һәм икенче көннәрдә ул барлыгы 3 800 *км* очкан. Әгәр ул икенче көнне 2 000 *км* очкан булса, беренче көнне ничә километр һәм өченче көнне ничә километр очкан булыр?

612. Өч сыер абзарында 490 сыер бар: беренче абзарда 168 сыер, ә беренче белән икенчесендә 318 сыер бар. Икенче абзарда һәм өченче абзарда ничәшәр сыер булган?

613. Бер артель, укучылар өчен, 6 400 фуражка тегәргә, икенче артель 7 250 фуражка тегәргә заказ алды. Бер айдан соң беренче артельнең 586 фуражка, икенчесенең 1 760 фуражка тегәсе калды. Бер айда беренче артель, икенчесенә караганда, ничә фуражка артыграк теккән?

614. 1) Фабрикада кышка 840 *т* күмер хәзерләнгән иде. Хәзерләнгән күмернең дүртенче өлеше язга калды. Кыш буе күпме күмер ягылган?

2) Фабрикада 840 *т* түгел, ә аннан 328 *т* артыграк күмер хәзерләнгән дип исәпләп мәсьәләне яңадан чишегез.

615. 1) 46 028 һәм 45 360 саннарының аермасын 4 кә бүләргә.

2) 300 012 һәм 299 250 саннарының аермасын 3 тапкыр кечерәйтергә.

616. 75 486 + (56 120 − 39 576) 56 480 − (28 176 − 10 498)
84 659 + (92 180 − 18 092) 73 245 − (96 010 − 32 596)
60 729 + (40 305 − 25 728) 81 000 − (42 000 − 18 723)
91 086 + (70 020 − 36 485) 67 010 − (50 705 − 16 910)

617. 630 126 − (75 684 + 149 076) 57 × 2 × 6
142 511 − (9 147 + 68 069) 63 × 4 × 3
810 236 − (156 032 − 75 098) 144 × 6 : 9
910 004 − (630 050 − 529 178) 132 × 7 : 4

Мәсьәләләр.

618. Әнисе күлмәк тегү өчен зур кызына 4 *м*, кечкенә кызына 3 *м* материя сатып алган. Ул барлык материя өчен 14 сум акча түләгән. Материянең бер метры күпме тора?

619. Бер кыз үзе өчен 4 төймә, иптәш кызы өчен 3 төймә сатып алган. Төймәләр өчен 84 тиен акча түләгән. 4 төймә ничә тиен тора? 3 төймә ничә тиен тора?



620. Ике апа бергә 10 сумга бер кәрзин җиләк сатып алдылар һәм берсенә 4 *кг*, икенчесенә 6 *кг* итеп җиләкне үзара бүлештеләр.

Беренче апа күпме акча түләргә тиеш?

Икенче апа күпме акча түләргә тиеш?

621. Пионерларның ике отряды бергә 300 *кг* имән чикләвеге җыйганнар. Беренче отряд 2 капчык, икенче отряд шундый ук 3 капчык имән чикләвеге җыйган. Һәр отряд ничә килограмм имән чикләвеге җыйган?



622. Октябрятларның ике звёздочкасын; гөмбә җыеп тапшырган өчен, 12 сум акча белән бүләкләгәннәр. Бер звёздочкада 5 октябрят, икенчесендә 7 октябрят булса, бу сумманы звёздочкалар арасында ничек бүләргә кирәк?

623. Берсендә 19 пионер, икенчесендә 21 пионер булган ике отряд 80 төп агачны тәрбияләргә алалар.

Һәр пионерга беркетелгән агачлар саны тигез булсын өчен, беренче отрядка һәм икенче отрядка ничәшәр төп агач беркетергә кирәк?

624. Укучыларның ике бригадасына 11 әр *м* озынлыгында булган 9 түтәлне утарга кирәк. Әгәр бер бригадада 17 укучы, икенче бригадада 16 укучы булса, һәр укучы бертигез эшләрлек итеп, һәр бригадага ничәшәр метр беркетергә кирәк булыр?

625. Ике яшүсмер колхозда эшләп 16 сум акча алды. Әгәр аларның берсе 5 хезмәт көне, икенчесе 3 хезмәт көне эшләгән булса, алар бу акчаны үзара ничек бүләргә тиеш? Чишелешнең дөреслеген ничек тикшерергә?

626. Ике балта остасы мебельләр төзәткән өчен 35 сум акча алды. Аларның берсе 3 көн, икенчесе 4 көн эшләде. Сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

627. Чаңгычылар командасы бер үк тизлек белән 63 *км* юл үтте. Алар тукталышка кадәр 4 сәгать, тукталыштан соң 3 сәгать бардылар. Тукталыштан соң команда ничә километр юл үтте?



628. Үзегезнең класс яки мәктәп тормышыннан нинди булса да берәр эшне яки материалны укучылар арасында бүлүгә мәсьәлә төзегез.

629. Укучылар бер участоктан 5 кәрзин, икенчесеннән шундый ук 4 кәрзин кишер җыйдылар. Җыелган кишер барлыгы 270 *кг* булды. Һәр участоктан ничәшәр килограмм кишер җыйганнар?

630. 180 партаны ике авыл мәктәбенә класслар санына карап бүләргә кирәк. Бер мәктәптә 4 класс, ә икенчесендә 5 класс. Беренче мәктәп ничә парта алырга тиеш?

631. Түбәндәге кыскача язылган шарт буенча мәсьәлә төзегез:

Бер участоктан 6 капчык, икенчесеннән шундый ук 3 капчык бәрәңге җыйдылар.	Барлыгы 450 *кг*	? ?

Күбурынлы саннарны тапкырлау.

Берурынлы санга тапкырлау.

632. (Телдән.)

8×6	80×6	800×6	$8\,000 \times 6$
7×9	70×9	700×9	$7\,000 \times 9$
5×8	50×8	500×8	$5\,000 \times 8$

633. Совхоз һәрберсенә 3 132 шәр *кг* төяп, өч йөк автомобиле белән шәһәргә алма җибәрде. Совхоз барлыгы ничә килограмм алма җибәргән?

Чишү:
3 132 *кг*
3 132 *кг*
3 132 *кг*
9 396 *кг*

яки
$\times \begin{array}{r} 3\,132 \text{ кг} \\ 3 \\ \hline 9\,396 \text{ кг} \end{array}$

634. Колхоз шәһәргә 1 314 *кг* груша һәм 2 тапкыр артыграк алма җибәрде. Колхоз шәһәргә ничә килограмм алма җибәргән?

635. 1 213 санын кушылучы итеп 3 тапкыр кабатларга, 1 112 санын кушылучы итеп 4 тапкыр кабатларга. Гамәлнең нәтиҗәләрен белергә.

636. 1) Тапкырланучы 627, тапкырлаучы 3. Тапкырчыгышны табарга.

2) 714 × 6   619 × 5   562 × 4   974 × 2
826 × 3   923 × 4   683 × 3   461 × 5

637. Бер участоктан 448 *т*, икенчесеннән, беренчегә караганда, ике тапкыр артыграк, өченче участоктан беренче ике участокның икесеннән җыйган кадәр бодай җыеп алдылар. Өч участоктан барлыгы күпме бодай җыеп алдылар?

638. А дан Б га кадәр 328 *км*, Б дан В гә кадәр 3 тапкыр артыграк, ә В белән Г арасы А белән В арасына тигез. А дан Г га кадәр ничә километр? (Мәсьәләгә сызым сызыгыз һәм аны чишегез.)

639. 513 × 7   742 × 4   618 × 5   644 : 4 × 8
816 × 6   892 × 3   942 × 4   543 : 3 × 7

640. Телдән чишегез:

1) 6 × 7 + 9   70 × 9   600 × 4   400 × 7
9 × 5 + 7   80 × 7   300 × 5   500 × 6

2) Тапкырланучы 50, тапкырлаучы 8. Тапкырчыгышны табарга.

641. 534 × 7   672 × 5   2 875 × 4   3 756 × 9
245 × 6   784 × 6   1 968 × 6   5 698 × 7

642. Бер районда элек 588 йөк машинасы һәм 246 җиңел машина бар иде. Соңгы елларда йөк машиналары 3 тапкыр, ә җиңел машиналар 456 га артты. Районда хәзер барлыгы ничә машина булды?

643. Бер районда элек тәгәрмәчле тракторлар 156 һәм чылбырлы тракторлар 468 булган. Соңгы елларда тәгәрмәчле тракторлар саны 125 кә, чылбырлы тракторлар саны ике тапкыр артты. Районда хәзер барлыгы ничә трактор булды?




644. 396×8 $\quad 2\,482 \times 7$ $\quad 4\,675 \times 9$ $\quad 976 : 2 \times 8$
654×6 $\quad 6\,538 \times 5$ $\quad 7\,897 \times 6$ $\quad 956 : 4 \times 9$

645. Тапкырланучы 34 269, тапкырлаучы 3. Тапкырчыгышны табарга.

646. $51\,425 \times 4$ $\quad 31\,425 \times 7$ $\quad 127\,856 \times 6$ $\quad 118\,967 \times 8$
$24\,532 \times 6$ $\quad 52\,634 \times 8$ $\quad 139\,487 \times 5$ $\quad 116\,895 \times 7$

647. Комсомоллар яңа парк төзегәндә 3 көн 348 әр төп агач утырттылар. Моннан соң аларның тагын 470 төп агач утыртасылары калды. Комсомоллар барлыгы ничә төп агач утыртырга тиеш булганнар?

648. Тегү фабрикасы беренче 6 көндә һәр көн 235 пальто, аннан соңгы 8 көндә һәр көн 256 пальто текте. Моннан соң тагын 375 пальто тегәсе калды. Фабрика барлыгы ничә пальто тегәргә тиеш булган? (Өч гамәл белән чишегез.)

649. $182\,356 \times 4$ $\quad 119\,897 \times 6$ $\quad x + 35\,678 = 91\,206$
$137\,965 \times 5$ $\quad 112\,365 \times 8$ $\quad x - 17\,346 = 50\,214$
$238\,975 \times 3$ $\quad 125\,869 \times 7$ $\quad 39\,278 + x = 82\,004$

650. Телдән чишегез:

0×6 $\quad 0 \times 5 + 6$ $\quad 0 \times 7 + 8$
0×9 $\quad 0 \times 8 + 9$ $\quad 0 \times 9 + 1$

651. (Телдән.) Завод бер көнгә 204 сабан эшләп чыгара. Бер атнага ничә сабан эшләп чыгарыр? (Атнада 6 эш көне.)

652. 307 × 5 608 × 6 4 003 × 5 8 006 × 5
205 × 9 507 × 8 7 004 × 4 4 007 × 8

653. 1) Мәктәпкә мебельләр сатып алдылар. Мебель магазинының мәктәпкә биргән счётын тикшерергә.

Счёт.

Товарның исеме	Саны	Бәясе		Суммасы	
		сум	тиен	сум	тиен
Өстәлләр	8	13	—	104	—
Шкафлар	4	48	—	192	—
		Барлыгы		296 сум	

2) Мәктәбегездә булган берничә счётның дөреслеген тикшерегез.

654. 1) Балалар йортында тәрбияләнүчеләр өчен 25 әр сумнан 9 пальто, 12 шәр сумнан 7 костюм, һәм 9 ар сумнан 8 күлмәк сатып алганнар. Сатып алынган әйберләргә счёт языгыз.

2) Мәктәпкә яки гаиләгездә сатып алынган әйберләргә берничә счёт языгыз.

655. 405 × 9 3 004 × 7 4 056 × 8 927 : 3 × 7
408 × 5 5 006 × 9 7 608 × 6 812 : 2 × 6

656. 1) Тапкырланучы 15 076, тапкырлаучы 3. Тапкырчыгышны табарга.

2) 16 085 × 7 75 004 × 8 304 006 × 3 126 005 × 7
24 608 × 6 90 007 × 4 200 568 × 4 100 706 × 9

657. Шикәр заводы элек бер елга 7 095 *т* кисәкле шикәр һәм 12 075 *т* шикәр комы эшләп чыгара иде. Яңа машиналар куелгач, завод кисәкле шикәрне 3 тапкыр, шикәр комын 4 тапкыр артыграк эшләп чыгара башлады. Кисәкле шикәрнең һәм шикәр комының еллык эшләп чыгарылышы аерым-аерым ничә тоннага арткан?

658. 1) Совхоз, ящикларны һәр машинага тигез санда төяп, башта 4 йөк машинасы, аннан 3 йөк машинасы белән шәһәргә барлыгы 756 ящик виноград җибәргән. Совхоз һәр җибәрүдә ничәшәр ящик виноград җибәргән?

2) Совхоз беренче җибәрүдә 5 машина, икенчесендә 4 машина белән җибәргән дип, мәсьәләне яңадан чишегез.

659. Мисаллар дөрес чишелгәнме?

$9\,006 \times 4 \times 3 = 108\,072$ $\qquad$ $(3\,758 + 38\,249) \times 8 = 336\,056$

$8\,009 \times 5 \times 7 = 280\,315$ $\qquad$ $(153\,080 - 3\,036) \times 6 = 909\,264$

660. Мисаллар дөрес чишелгәнме?

1) $6 \times 7 = 7 \times 6$ $\qquad$ 2) $2 \times 8 \times 5 = 8 \times 5 \times 2 = 5 \times 2 \times 8$

$8 \times 9 = 9 \times 8$ $\qquad$ $3 \times 6 \times 4 = 4 \times 3 \times 6 = 6 \times 4 \times 3$

Тапкырлашучыларның урыннарын алмаштырудан тапкырчыгыш үзгәрми.

661. Тапкырлашучыларның урыннарын алмаштыру үзлегеннән файдаланып мисалларны телдән чишегез:

$$25 \times 7 \times 4 = 25 \times 4 \times 7 = 100 \times 7 = 700$$

$20 \times 9 \times 5$ $\qquad$ $15 \times 7 \times 4$ $\qquad$ $16 \times 4 \times 5$

$8 \times 7 \times 5$ $\qquad$ $25 \times 3 \times 4$ $\qquad$ $50 \times 9 \times 2$

Тапкырлауның дөреслеген тикшерү өчен, тапкырлашучыларның урыннарын алмаштырып, икенче тәртиптә тапкырлыйлар. Әгәр шул ук тапкырчыгыш килеп чыкса, гамәл дөрес эшләнгән була.

662. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

356×3 $\qquad$ 5×427 $\qquad$ $4 \times 2\,788$ $\qquad$ $7 \times 48\,256$

3×356 $\qquad$ 8×635 $\qquad$ $6 \times 3\,062$ $\qquad$ $9 \times 13\,004$

663. 1) 280 пионер күчмә китапханә өчен китаплар җыйды. Алардан 74 пионер 3 әр китап, калганнары 2 шәр китап китерде. Пионерлар барлыгы ничә китап җыйганнар?

2) Үзегезнең җәмгыятькә файдалы эшләрегез турында мәсьәлә төзегез.

664. 350 укучы колхозга бәрәңге алуда булышты. Алардан 45 кеше 6 шар *ц*, калганнары 8 әр *ц* бәрәңге жыйдылар? Укучылар барлыгы ничә центнер бәрәңге жыйганнар?

665. 2 × 978   4 × 3 685   3 × 48 257   5 × 128 572
6 × 507   7 × 2 096   8 × 16 009   9 × 103 084

666. 38 046 һәм 9 саннарының тапкырчыгышыннан 94 788 не алырга.

667. 7 һәм 80 705 саннарының тапкырчыгышыннан 564 159 ны алырга һәм чыккан аерманы 8 гә бүләргә.

Мәсьәләләр.

668. Ике малай бер үк бәядән карандашлар сатып алган. Малайларның берсе 6 карандаш артык алган һәм 12 тиен артыграк түләгән. Бер карандаш ничә тиен торган?

669. Бер апа 3 кәтүк җеп сатып алган. Икенче тапкыр тагын шундый ук 5 кәтүк җеп алган һәм, беренчегә караганда, 18 тиен артыграк түләгән. Бер кәтүк җеп ничә тиен торган?



670. Колхозчыларга яшелчә җыюда булышып, укучыларның бер бригадасы 5 кәрзин кишер, икенче бригадасы шундый ук 9 кәрзин кишер җыйган. Икенче бригада беренчедән 96 *кг* кишер артыграк җыйган. Һәр бригада ничә килограмм кишер җыйган?



Мәсьәләнең кыскача язылган шарты түбәндәгечә:

I бригада — 5 кәрзин II бригада — 9 кәрзин	96 *кг* артыграк	Һәрбер бригада ничәшәр килограмм җыйган?

План һәм мәсьәләне чишү:

1) Икенче бригада, беренчегә караганда, ничә кәрзин артыграк җыйган?

$$9 \text{ к.} - 5 \text{ к.} = 4 \text{ к.}$$

2) Бер кәрзингә ничә килограмм кишер салганнар?

$$96 \textit{ кг} : 4 = 24 \textit{ кг.}$$

3) Беренче бригада ничә килограмм кишер җыйган?

$$24 \textit{ кг} \times 5 = 120 \textit{ кг.}$$

4) Икенче бригада ничә килограмм кишер җыйган?

$$24 \textit{ кг} \times 9 = 216 \textit{ кг.}$$

Җавап: I бригада — 120 *кг*; II бригада — 216 *кг*.

671. Балалар бакчасы өчен бер тапкыр 5 шкаф, икенче тапкыр тагын шундый ук 2 шкаф сатып алганнар. Шкафлар өчен беренче алуда, икенчесенә караганда, 96 сум акча артыграк түләгәннәр. Шкафлар өчен беренче һәм икенче алуда ничәшәр сум түләнгән?

672. Ике буяучы, көнлек эш хакын бертигез алып, идәннәр буяганнар. Бер буяучы 7 көн, икенчесе 4 көн эшләгән. Икенче буяучы, беренчегә караганда, 12 сум акча кимрәк алган. Беренче буяучы ничә сум акча алган?

673. Санаторий август аенда 7 ящик груша һәм сентябрьдә шундый ук 9 ящик груша алган. Сентябрьдә, августка караганда, 30 *кг* груша артыграк алынган. Санаторий августта ничә килограмм һәм сентябрьдә ничә килограмм груша алган?

674. Мәктәп ашханәсенә бер тапкыр 5 бидон, икенче тапкыр шундый ук 9 бидон сөт китерделәр. Беренче китерүдә, икенчегә караганда, 140 *л* сөт кимрәк китерделәр. Беренче тапкыр ничә литр сөт китергәннәр?

675. Бер үк төр ике кисәк материя сатып алганнар. Беренче кисәктә 5 *м*, ә икенче кисәктә 3 *м* материя булган.

Ике кисәк өчен 32 сум акча түләгәннәр. Һәр кисәк күпмешәр тора?

676. Бер үк тәрдән ике кисәк материя сатып алынган. Бер кисәктә 5 *м*, икенчесендә 3 *м* материя булган. Беренче кисәк өчен, икенчегә караганда, 32 сум акча артыграк түләнгән. Һәр кисәк ничәшәр сум тора?

677. Кошлар фабрикасы кошларга ашату өчен 5 вагон тары ярмасы, 4 вагон арпа алган. Һәр вагонга бертигез төялгән, ә барлык ашлык 450 *т* булган. Кошлар фабрикасы ничә тонна тары ярмасы һәм ничә тонна арпа алган? (Чишелешнең дөреслеген тикшерегез.)

678. Бер тракторда 16 сәгать, икенчесендә 9 сәгать эшләделәр. Икенче тракторда, беренчегә караганда, ягулык 49 *л* азрак тотылды. Икенче тракторда ничә литр ягулык тотылган? (Ягулык ике тракторда да сәгатькә бер үк үлчәүдә китә.)

679. Бер поезд 7 сәгать, икенчесе 4 сәгать юлда булды. Икенче поезд, беренчегә караганда, 120 *км* кимрәк юл үтте. Әгәр аларның бару тизлеге сәгатькә бертигез булса, һәр поезд ничәшәр километр юл үткән булыр? (Чишелешнең дөреслеген тикшерегез.)

680. Ике шофер хәзерләү пунктына ашлык ташыган. Беренче шофер 4 тапкыр, икенчесе 6 тапкыр барып кайткан. Икенче шофер, беренчегә караганда, 60 *ц* ашлык артыграк ташыган. Әгәр алар һәр баруда ашлыкны бертигез салып илткән булсалар, һәр шофер ничәшәр тонна ашлык ташыган булыр?

681. Түбәндәге мәсьәләне тулыландырыгыз һәм чишегез.

Бер кыз бала 4 дәфтәр, икенчесе шундый ук 7 дәфтәр сатып алган. Беренче кыз үзенең дәфтәрләре өчен, икенчегә караганда,... түләгән. Кызлар дәфтәрләр өчен ничәшәр тиен акча түләгәннәр?

682. Мәсьәләгә сорау куегыз һәм чишегез:

Бер үк тизлек белән баручы ике поезд юлга чыкты. Поездларның берсе 6 сәгать, икенчесе 9 сәгать юлда булды. Беренче поезд икенчесеннән 150 *км* кимрәк юл үтте. Поездларның...?

683. Тиешле саннар табып куегыз да мәсьәләне чишегез:

Бер малай ... карандаш, ә бер кыз шундый ук ... карандаш сатып алды. Малай карандашлары өчен, кызга караганда, ... акча артыграк түләде. Карандашлар өчен малай һәм кыз ничәшәр тиен акча түләгәннәр?

684.

69 576 × 8 + 38 795	864 : 9 × 2 × 8	876 : 6 × 4 × 8
16 485 × 6 − 83 072	912 : 4 × 6 × 5	975 : 5 × 9 × 6
80 065 × 7 − 87 960	785 : 5 × 3 × 9	873 : 3 × 5 × 9
60 908 × 9 − 473 896	537 : 3 × 6 × 7	567 : 9 × 7 × 8

10 га һәм 100 гә тапкырлау.

685. Мәктәп өчен 2 шәр сумнан 10 картина сатып алганнар. Картиналар өчен күпме акча түләгәннәр?

686.

1 × 10	10 × 10	100 × 10	1 000 × 10
3 × 10	40 × 10	500 × 10	2 000 × 10
8 × 10	70 × 10	900 × 10	6 000 × 10

687.

28 × 10	134 × 10	1 324 × 10	42 368 × 10
42 × 10	256 × 10	4 568 × 10	76 005 × 10
74 × 10	418 × 10	8 130 × 10	91 040 × 10
97 × 10	720 × 10	6 400 × 10	80 700 × 10

Санны 10 га тапкырлау өчен, аның уң ягына бер нуль өстәп язарга кирәк.

688. Икмәк заводы 485 әр *ц* төялгән 10 вагон арыш оны һәм 500 әр *ц* төялгән 10 вагон бодай оны алды. Бодай оны, арыш онына караганда, ничә центнер артыграк алынган? (Ике юл белән чишегез.)

689.

75 × 10	4 280 × 10	7 248 × 10 − 65 088
356 × 10	56 072 × 10	24 305 × 10 − 80 697

690. Телдән чишегез:

10 × 10 × 10 × 10 × 10	8 × 10 × 10 × 10 × 10
4 × 10 × 10 × 10 × 10	6 × 10 × 10 × 10 × 10

691. Ашханә өчен 4 әр сумнан урындыклар сатып алынган. Шундый ун урындык күпме торыр? Шундый ун дистә яки йөз урындык күпме торыр?

692.

6 × 100	10 × 100	25 × 100	124 × 100
9 × 100	15 × 100	42 × 100	218 × 100
7 × 100	18 × 100	63 × 100	476 × 100

Санны 100 гә тапкырлау өчен, аның уң ягына ике нуль өстәп язарга кирәк.

693. Вагонга 10 капчык манный ярмасы һәм 100 капчык карабодай ярмасы төяделәр. Бер капчык манный ярмасының авырлыгы 80 *кг*, бер капчык карабодай ярмасының авырлыгы 20 *кг* га кимрәк. Барлык йөк нинди авырлыкта булган?

694. 1) Машинага 10 капчык он һәм 100 капчык көрпә төялгән. Бер капчык он 84 *кг*, ә бер капчык көрпә, бер капчык онга караганда, 2 тапкыр җиңелрәк. Барлык йөкнең авырлыгын табарга.

2) Бер капчык онның авырлыгын 84 *кг* урынына 80 *кг* дип исәпләп, мәсьәләне яңадан эшләгез.

695.

13×100	$1\,568 \times 100$	$334 : 2 \times 100$
38×100	$2\,872 \times 100$	$672 : 4 \times 100$
152×100	$7\,096 \times 100$	$864 : 3 \times 100$

Тулы дистә һәм йөзләргә тапкырлау.

696. Бер тартмада 6 карандаш. Шундый ике тартмада ничә карандаш булыр? Шундый 20 тартмада ничә карандаш булыр?

$$6 \times 20 = 6 \times 2 \times 10 = 120$$

6	6
6	6
6	6
6	6
6	6
6	6
6	6
6	6
6	6
6	6

697. Бер ящик кадакның авырлыгы 32 *кг*. Шундый 40 ящик кадакның авырлыгы күпме булыр?

Чишү:

$$32\ кг \times 40 = 32\ кг \times 4 \times 10 = 1\,280\ кг,$$

яки

$$\times \begin{array}{r} 32\ кг \\ 40 \\ \hline 1\,280\ кг \end{array}$$

698.

7×50	16×30	76×80	135×50
9×40	27×40	97×60	$3\,428 \times 20$
8×60	63×50	88×90	$1\,307 \times 30$

699. 1) Завод төзелеше өчен 26 йөк машинасында цемент китерелгән: шулардан 6 машинада 95 әр капчык, калганнарының һәрберсендә 98 әр капчык цемент булган. Барлыгы ничә капчык цемент китерелгән?

2) Бу мәсьәлә шартындагы 26 санын 36 дип үзгәртеп, мәсьәләне яңадан чишегез.

700. 423×80 $\quad 3742 \times 50$ $\quad 12453 \times 40$ $\quad 756:4 \times 60$

708×60 $\quad 5407 \times 30$ $\quad 16074 \times 50$ $\quad 912:6 \times 90$

701. (Телдән.) 1) Нинди сан 18 дән 2 тапкыр зуррак? 20 тапкыр зуррак?

2) Нинди сан 14 тән 3 тапкыр зуррак? 30 тапкыр зуррак?

702. Май заводына 35 әр литрлы 300 бидон сөт китерелгән. Заводка ничә литр сөт китерелгән?

Чишү:

$$35\ л \times 300 = 35\ л \times 3 \times 100 = 105\ л \times 100 = 10\,500\ л,$$

яки

$$\begin{array}{r} \times\ 35\ л \\ 300 \\ \hline 10\,500\ л \end{array}$$

703. 3×300 $\quad 5 \times 700$ $\quad 14 \times 600$ $\quad 236 \times 400$

6×200 $\quad 8 \times 400$ $\quad 43 \times 800$ $\quad 413 \times 600$

4×400 $\quad 9 \times 500$ $\quad 52 \times 900$ $\quad 508 \times 700$

704. 6 ящик конфет 1 *ц* 8 *кг* авырлыкта килә. Магазинга шундый ук 200 ящик конфет китерелгән. Ничә килограмм конфет китерелгән?

Күрсәтмә. 1 *ц* 8 *кг* ны килограммнарга әйләндерергә.

705. Дүрт кисәктә 180 *м* полотно бар. Шундый 300 кисәктә ничә метр полотно булыр?

706. Магазин көннең беренче яртысында 20 ящик җиләк, икенче яртысында шундый ук 30 ящик җиләк сатты. Көннең икенче яртысында, беренче яртысына караганда, 80 *кг* җиләк артыграк сатылды. Көн буе барлыгы ничә килограмм җиләк сатылган?

707. Мәктәп мастерское бер заказ буенча 86 урындык, икенче заказ буенча шундый ук 96 урындык хәзерләгән һәм икенче заказ өчен 30 сум акча артыграк алган. Мастерской барлык урындыклар өчен күпме акча алган?

708. 69×600 $\quad 428 \times 500$ $\quad 738 + x = 1\,020$

76×800 $\quad 736 \times 400$ $\quad x - 356 = 1\,780$

48×900 $\quad 804 \times 700$ $\quad x + 1\,365 = 2\,010$

Икеурынлы санга тапкырлау.

709. Интернат-мәктәп өчен 32 шәр сумнан 14 өстәл сатып алынган. Бу өстәлләр өчен күпме акча түләнгән?

Чишү:

$$\begin{array}{r} \times\begin{array}{r}32\text{ сум}\\14\end{array} \\ \hline +\begin{array}{r}128\\320\end{array} \\ \hline 448\text{ сум}\end{array} \qquad \text{яки} \qquad \begin{array}{r} \times\begin{array}{r}32\text{ сум}\\14\end{array} \\ \hline +\begin{array}{r}128\\32\end{array} \\ \hline 448\text{ сум}\end{array}$$

Шундый 4 өстәл ничә сум булыр? 10 өстәл? 14 өстәл?

710. 42×14 $\quad 36 \times 23$ $\quad 52 \times 36$ $\quad 68 \times 24$
54×16 $\quad 28 \times 34$ $\quad 43 \times 64$ $\quad 56 \times 32$
43×12 $\quad 24 \times 47$ $\quad 25 \times 33$ $\quad 72 \times 54$

711. Баржага 76 *т* цемент, аңа караганда 18 *т* артыграк известь, известькә караганда 12 тапкыр артыграк ком төялгән. Баржага барлыгы ничә тонна йөк төялгән?

712. 38×13 $\quad 23 \times 45$ $\quad 72 \times 36$ $\quad 94 \times 43$
56×14 $\quad 36 \times 25$ $\quad 45 \times 53$ $\quad 68 \times 26$
75×18 $\quad 47 \times 38$ $\quad 84 \times 27$ $\quad 76 \times 54$

713. 1) Тапкырланучы 47, тапкырлаучы 28. Тапкырчыгышны табарга.

2) 67×55 $\quad 65 \times 88$ $\quad 89 \times 76$ $\quad 99 \times 68$
94×67 $\quad 77 \times 96$ $\quad 47 \times 95$ $\quad 78 \times 96$

714. Фабрика план буенча бер айга 2 250 *т* кәгазь эшләп чыгарырга тиеш иде. Ул һәр көн 94 *т* кәгазь эшләп чыгарды. Әгәр бер айда 26 эш көне дип исәпләсәк, фабрика планнан тыш күпме кәгазь эшләп чыгарган булыр?

715. Завод план буенча бер айда 1 580 печән чапкыч эшләп чыгарырга тиеш иде. Ул һәр көн 75 әр печән чапкыч эшләп чыгарды. Әгәр бер айда 27 эш көне булса, завод планнан тыш ничә печән чапкыч эшләп чыгарган булыр?

716. 56×88 $\quad 84 \times 77$ $\quad 69 \times 83$ $\quad 388 : 4 \times 56$
95×97 $\quad 68 \times 56$ $\quad 76 \times 98$ $\quad 632 : 8 \times 75$

717. 256×44 $\quad 326 \times 32$ $\quad 874 \times 68$ $\quad 508 \times 37$
438×15 $\quad 654 \times 57$ $\quad 968 \times 75$ $\quad 806 \times 94$

718. 1) Самолёт сәгатькә 625 *км* тизлек белән Мәскәүдән Владивостокка очты. Мәскәүдән Владивостокка 9 170 *км*. Әгәр тукталуларга 2 сәгать вакыт киткән булса, юлга чыгудан 14 сәгать үткәч, самолёт Владивостоктан нинди ераклыкта булыр? (Мәсьәләне чишү өчен сызым сызыгыз.)

2) Очу тизлеген сәгатькә 85 *км* га арттырып, самолётның кире кайту юлы турында мәсьәлә төзегез һәм чишегез.

719. 346 × 14   645 × 32   408 × 96   976 : 4 × 67
572 × 18   976 × 65   706 × 58   865 : 5 × 84

720. 1) Тапкырлануы 4 325, тапкырлаучы 26. Тапкырчыгышны табарга.

2) 1 245 × 13   5 436 × 44   4 027 × 68   6 204 × 58
3 648 × 24   7 582 × 56   6 007 × 94   7 005 × 76

721. Бер участокка 314 *ц*, икенчесенә 29 *ц* артыграк бодай чәчтеләр. Беренче участоктан, чәчкәнгә караганда, 21 тапкыр, икенчесеннән 24 тапкыр артыграк бодай җыеп алдылар. Ике участоктан барлыгы күпме бодай җыеп алганнар?

722. Бер участокка 148 *ц*, ә икенчесенә 57 *ц* артыграк тары чәчтеләр. Беренче участоктан, чәчкәнгә караганда, 88 тапкыр, икенчесеннән 95 тапкыр күбрәк тары җыеп алдылар. Ике участоктан барлыгы күпме тары җыеп алганнар?

723. 2 456 × 14   4 036 × 67   (35 010 — 34 338) : 7 × 84
3 748 × 26   8 009 × 95   (108 024 — 107 192) : 4 × 75

724. 3 008 һәм 24 саннарының тапкырчыгышыннан 56 980 не алырга.

725. (Телдән.) 12 × 4   120 × 4   1 200 × 4   12 000 × 4
15 × 3   150 × 3   1 500 × 3   15 000 × 3
24 × 4   240 × 4   2 400 × 4   24 000 × 4

726. Һәрберсенә 720 шәр йомырка тутырып, колхоз шәһәргә 8 ящик йомырка җибәргән. Колхоз барлыгы ничә йомырка җибәргән?

Чишү.

$$\begin{array}{r} \times\ 720 \text{ йомырка} \\ 8 \\ \hline 5\,760 \text{ йомырка.} \end{array}$$

727. 56 × 3   32 × 8   630 × 12   2 600 × 14
560 × 3   3 200 × 8   570 × 24   1 800 × 15

728. Мәктәптән китап магазинына кадәр булган ераклык сызымда кечерәйтелеп күрсәтелгән. Мәктәптән китап магазинына кадәр ничә метр?

729. Мәктәптән өегезгә кадәр булган ераклыкны, кечерәйтеп, туры сызык кисемтәсендә билгеләгез. Урындагы 100 *м* ны кисемтәдә 1 *см* белән билгеләгез.

730. Фабрикага 16 *км* озынлыкта бер колеялы тимер юл тармагы үткәргәннәр. Әгәр бер колеялы юлның бер километрына 1 340 шпал китсә, бу юлга ничә шпал кирәк булган?



731. Заводка 28 *км* озынлыкта ике колеялы тимер юл тармагы үткәрү өчен 16 875 шпал китерелгән. Бер колеялы юлның бер километрына 1 350 шпал китсә, бу юлны үткәреп бетерү өчен тагын ничә шпал китерергә кирәк?

732. Заводка 14 *км* озынлыкта ике колеялы тимер юл тармагы үткәрергә кирәк. Бу төзелеш өчен беренче көнне 4 350 шпал, икенче көнне 8 700 шпал китерелгән. Әгәр бер колеялы юлның бер километрына 1 350 шпал китсә, төзелешкә тагын күпме шпал кирәк булыр?

733. 470×6 $\quad 230 \times 16$ $\quad 680 : 4 \times 15$
$5\,600 \times 8$ $\quad 540 \times 38$ $\quad 810 : 3 \times 58$
$43\,700 \times 7$ $\quad 860 \times 73$ $\quad 950 : 5 \times 67$

734. 1) Тапкырланучы 12 436, тапкырлаучы 14. Тапкырчыгышны табарга.

2) $18\,376 \times 15$ $\quad 17\,405 \times 57$ $\quad 30\,790 \times 28$
$27\,648 \times 24$ $\quad 16\,086 \times 43$ $\quad 59\,800 \times 16$

735. Артель ноябрьда көнгә 165 әр пар, декабрьда 180 шәр пар һәм январьда 216 шар пар коньки эшләп чыгарды. Артель

декабрьда конькиларны, ноябрьга караганда, ничә парга артыграк эшләп чыгарган? Январь аенда, декабрьга караганда, күпмегә артыграк эшләп чыгарган? (Ноябрьда 24, декабрьда 25, январьда 26 эш көне.)

736. $43\,276 \times 17$ $\quad 16\,009 \times 58$ $\quad (72\,315 - 71\,739):9 \times 57$
$27\,942 \times 26$ $\quad 40\,680 \times 19$ $\quad (104\,000 - 103\,073):3 \times 48$

737. Совхоз балалар йортына бүләк итеп алмалар җибәргән: беренче тапкыр 13 ящик, икенче тапкыр шундый ук 17 ящик. Икенче тапкыр, беренчегә караганда, 80 *кг* алма артыграк җибәргән. Совхоз балалар йортына барлыгы ничә килограмм алма җибәргән?

Бу мәсьәләне Камил болай чиште:

1) 17 ящ. — 13 ящ. = 4 ящ.
2) 80 *кг* : 4 = 20 *кг*
3) 20 *кг* × 13 = 260 *кг*
4) 20 *кг* × 17 = 340 *кг*
5) 260 *кг* + 340 *кг* = 600 *кг*

Мәсьәләне Нияз болай чиште:

1) 17 ящ. — 13 ящ. = 4 ящ.
2) 80 *кг* : 4 = 20 *кг*
3) 13 ящ. + 17 ящ. = 30 ящ.
4) 20 *кг* × 30 = 600 *кг*.

Укучылар мәсьәләне чишкәндә ничек фикер йөрткәннәр? Кайсы чишү юлы яхшырак?

738. Пароход, бердәй тизлек белән барып, беренче көн 16 сәгать, икенче көн 20 сәгать юлда булган. Беренче көнне пароход, икенче көнгә караганда, 112 *км* кимрәк юл үткән. Пароход ике көндә барлыгы ничә километр юл үткән?

739. Укучылар 360 *г* чәчәк орлыклары җыйганнар һәм һәрберсенә бертигез итеп, пакетларга тутырганнар. 5 пакетны үзләренә алып, калган 3 пакетны балалар йортына бүләк иткәннәр. Алар үзләренә ничә грамм орлык алып калганнар һәм балалар йортына ничә грамм орлык бүләк иткәннәр?

740. Бер чәй кашыгы 30 тиен, 2 аш кашыгының бәясе 3 чәй кашыгы бәясенә тигез. Бер аш кашыгы ничә тиен тора?

741. Бер урындык 6 сум, 2 өстәл бәясе 9 урындык бәясе кадәр. Балалар бакчасы өчен 12 өстәл сатып алганнар. Өстәлләр өчен күпме акча түләнгән?

742. Бер ящик конфет 18 *кг* авырлыкта, 6 ящик печеньеның авырлыгы 4 ящик конфет авырлыгы кадәр була. Ял йорты өчен 15 ящик печенье сатып алганнар. Ничә килограмм печенье сатып алынган?

743. Җилнең тизлеге менә шундый:

Нинди җил	Җилнең тизлеге (секундка метрлар белән)
Әкрен җил (яфракларны селкетә) . .	5
Көчле җил (зур ботакларны тирбәтә)	13
Давыллы җил (түбә калайларын алып ыргыта)	24
Көчле давыллы җил (йортларны җимерә)	35

1) Көчле җилнең тизлеге әкрен җил тизлегеннән минутка ничә метрга артыграк?

2) Давыллы җилнең тизлеге көчле давыллы җил тизлегеннән минутка ничә метрга кимрәк?

Белешмә. Бер минутта 60 секунд.

744. Эшче җәйге ял вакытында, семьясын алып, үз автомобилендә диңгез буена ял итәргә китте. Аңар барлыгы 1 300 *км* юл үтәргә кирәк иде. Алар беренче көнне сәгатькә 65 *км* тизлек белән 8 сәгать, ә икенче көнне шул ук тизлек белән 9 сәгать бардылар. Тагын ничә километр юл үтәселәре калган?

745. Тиз йөрешле поезд сәгатькә ... *км* тизлек белән, ә товар поезды сәгатькә ... *км* тизлек белән барды. Тиз йөрешле поезд бер тәүлектә, товар поездына караганда, ничә километрга артыграк юл үтте?

(Саннар куярга һәм мәсьәләне чишәргә.)

746. $128 \times 12 \times 14$ $\quad 248 \times (612:9)$ $\quad 180 \times (261:3)$
$304 \times 16 \times 13$ $\quad 506 \times (456:6)$ $\quad 620 \times (320:5)$
$708 \times 27 \times 15$ $\quad 692 \times (308:7)$ $\quad 570 \times (504:9)$
$966 \times 34 \times 18$ $\quad 1\,306 \times (616:8)$ $\quad 880 \times (602:7)$

747. $736:4 \times 80$ $\quad (63\,105 - 62\,490):5 \times 46$
$948:6 \times 57$ $\quad (100\,324 - 99\,088):4 \times 75$
$760:5 \times 94$ $\quad (260\,001 - 259\,020):9 \times 84$
$872:8 \times 68$ $\quad (432\,040 - 431\,576):8 \times 99$

Күбурынлы саннарны бүлү.

Берурынлы санга бүлү.

748. Мәктәптә кайнар аш өчен, һәр айда бертигез тотып, 4 айда 4 652 *кг* бәрәңге бетерделәр. Һәр айда ничәшәр килограмм бәрәңге тотканнар?

749. 1) Бүленүче 8 752, бүлүче 4. Өлешне табарга.

2) 8 358 : 2	5 625 : 5	8 520 : 8	7 938 : 7
6 822 : 3	8 576 : 4	6 768 : 6	9 522 : 9

750. ТУ-114 самолёты 2 сәгатьтә 1 748 *км* очты. Бу самолёт бер сәгатьтә ничә километр очкан?

751.

7 360 : 2	8 220 : 3	8 400 : 6	9 310 : 7
9 320 : 4	7 650 : 5	9 600 : 8	8 500 : 5

752.

1 560 : 2	8 610 : 3	5 600 : 7	6 300 : 9
3 720 : 4	4 750 : 5	4 740 : 6	5 760 : 8

753. Тегермән 1 352 *т* бодай оны, бодайга караганда ике тапкыр кимрәк арыш оны, арышка караганда 48 *т* кимрәк солы оны тартты. Тегермән барлыгы күпме он тарткан?

754.

5 396 : 4	9 114 : 6	(43 785 − 38 598) : 3
7 152 : 3	8 862 : 7	(13 009 − 7 485) : 4
8 970 : 5	9 768 : 6	(20 200 − 12 874) : 6

755. Телдән исәпләү өчен бирелгән таблицадан *И* рәтендәге һәрбер санны 4 кә бүләргә (165 нче бит)

756. Бүленүче 85 326, бүлүче 2. Өлешне табарга.

757.

87 452 : 4	10 356 : 6	41 760 : 8	60 760 : 7
67 362 : 3	15 834 : 7	30 510 : 9	49 500 : 5
46 768 : 2	19 425 : 5	50 214 : 6	67 576 : 8

758. Сыер савучы бер елда 9 сыердан 38 070 *л*, ә икенче савучы 8 сыердан 40 960 *л* сөт савып алган. Икенче савучы бер сыердан, беренче савучыга караганда, күпмегә артыграк сөт савып алган?

759. 3 780 не 6 га бүлүдән чыккан өлеш 40 ны 8 гә бүлүдән чыккан өлештән ничә тапкыр зуррак?

760. 72 не 18 гә бүлүдән чыккан өлеш 1 956 ны 3 кә бүлүдән чыккан өлештән ничә тапкыр кечерәк?

761. 36 285 : 5 40 845 : 7 37 080 : 4 568 × 35 : 4
50 352 : 6 65 392 : 8 43 200 : 9 144 × 156 : 9

762. (**Т е л д ә н.**) 120 санының алтынчы өлешен табарга. 200 санының бишенче өлешен табарга.

763. Йорт төзү өчен 453 460 данә кирпеч китерергә кирәк иде. Кирпечнең дүртенче өлешен китерделәр. Тагын күпме кирпеч китерәселәре калды?

764.

698 752 : 2	608 130 : 5	612 352 : 8	402 300 : 9
956 037 : 3	328 272 : 6	435 386 : 7	503 200 : 8
835 928 : 4	483 012 : 9	324 980 : 5	470 322 : 6

765. 1) 1 320 *кг* оннан икмәк пешергәннәр. Пешкәндә арту он авырлыгының өченче өлешенә тигез булган. Күпме икмәк пешерелгән?

2) Әгәр пешкәндә арту барлык онның өченче өлешенә тигез булса, 2 280 *кг* оннан күпме пешкән икмәк чыгар?

766. Икмәк заводында 1 710 *кг* оннан икмәк пешергәннәр. Пешкәндә арту барлык онның өченче өлешен төзегән. Әгәр бер кирпеч икмәкнең авырлыгы 2 *кг* булса, барлыгы ничә кирпеч икмәк пешергәннәр?

767. 147 240 санының дүртенче өлешен табарга. 329 166 санының алтынчы өлешен табарга. 352 476 санының тугызынчы өлешен табарга. 463 256 санының сигезенче өлешен табарга.

768. 8 саны килеп чыксын өчен, нинди санны 5 кә бүләргә кирәк?

$$x : 5 = 8$$

769. Бу мисалларда нәрсә билгеле һәм нәрсә билгесез?

$x:4=9$	$x:5=18$	$x:2=80$	$x:5=284$
$x:3=15$	$x:6=20$	$x:7=30$	$x:8=137$
$x:2=48$	$x:4=50$	$x:9=40$	$x:7=256$

Билгесез саннарны табарга, аннан соң дөреслеген тикшереп карарга. Дөрес табылганнармы?

770. 1) Бүлүче 6, өлеш 15. Бүленүчене табарга.

2) Бүлүче 8, өлеш 136. Бүленүчене табарга.

771. (**Т е л д ә н.**) Түбәндәге бирелгәннәрдән чыгып мәсьәләләр төзегез һәм чишегез:

1 *м* ның бәясе	Метрлар саны	Суммасы
25 сум	3 *м*	x
x	3 *м*	75 сум
25 сум	x	75 сум

772. Ял йорты өчен 4 радиоалгыч һәм 150 шәр сумнан 3 телевизор алып, барысы өчен 642 сум акча түләгәннәр. Бер радиоалгычның бәясен белергә.

773. Балалар йорты өчен 165 сумга 15 әр сумнан 7 данә балалар костюмы һәм 4 әр сумнан берничә күлмәк сатып алганнар. Ничә күлмәк сатып алганнар?

774. $56:7$ $\quad 84:7$ $\quad 60:12$ $\quad 72:18$ $\quad 91:13$

7×8 $\quad 7\times 12$ $\quad 12\times 5$ $\quad 18\times 4$ $\quad 13\times 7$

775. 1) Бүлү: Бүлүнең дөреслеген тикшерү:

$$\begin{array}{r|l} 12\,828 & 6 \\ \underline{8} & 2\,138 \\ 22 & \\ \underline{48} & \\ 00 & \end{array} \qquad \begin{array}{r} 2\,138 \\ \times\ 6 \\ \hline 12\,828 \end{array}$$

2) $1\,329:3$ $\quad 1\,860:5$ $\quad 1\,512:8$

443×3 $\quad 372\times 5$ $\quad 189\times 8$

Бүлүнең дөреслеген тикшерү өчен, бүлүчене өлешкә тапкырлыйбыз. Әгәр бүленүче килеп чыкса, гамәл дөрес эшләнгән була.

776. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

4 360 : 5	35 728 : 4	170 568 : 8	296 380 : 7
5 826 : 3	40 362 : 6	607 608 : 9	451 200 : 8
7 336 : 8	28 143 : 9	423 725 : 5	337 026 : 6

777. 1) 9 тукучы 6 көнгә 1 890 *м* тукыма тукыды. Бер тукучыга бер көнгә ничәшәр метр тукыма туры килә?

2) Әгәр һәрбер тукучы көнгә 35 әр *м* тукыма тукый алса, 9 тукучы 6 көнгә ничә метр тукыма әзерләр?

778. (Телдән.)

45 : 3	60 : 5	216 : 2	540 : 5	618 : 6
72 : 4	91 : 7	315 : 3	824 : 4	714 : 7

779.

9 621 : 3	6 438 : 6	3 520 : 5	7 049 : 7
7 535 : 5	8 352 : 8	8 127 : 9	5 640 : 8

780. 5 640 санын 8 тапкыр кечерәйтсәң, күпме булыр? 6 349 санының җиденче өлеше ничәгә тигез булыр? 4 527 эчендә ничә тапкыр 9 бар? 4 842 саны 6 дан ничә тапкыр зуррак? 6 саны 4 842 дән ничә тапкыр кечерәк?

781. Эшчеләргә 1 224 *м* озынлыктагы юлны төзәтергә кирәк иде. Беренче көнне алар барлык юлның алтынчы өлешен төзәттеләр, юлның калган өлешен, һәр көн бертигез эшләп, 3 көндә төзәтеп бетерделәр. Эшчеләр бу өч көндә ничәшәр метр юл төзәткәннәр?

782. Пассажир самолёты, һәр көн бер үк тизлек белән очып, беренче көн 7 сәгать, ә икенче көн 12 сәгать һавада булды. Беренче көнне, икенче көнгә караганда, 1 540 *км* кимрәк очты. Бу ике көндә самолёт ничәшәр километр очкан?

783.

9 624 : 3	6 270 : 6	7 035 : 7	5 280 : 4
4 020 : 5	4 856 : 8	9 081 : 9	8 560 : 8

784. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

$3\,576 + 6\,984$ $\quad$ $7\,020 - 4\,857$ $\quad$ 234×74 $\quad$ $3\,628 : 4$

785.

24 328 : 4	58 440 : 8	396 276 : 4	564 200 : 7
36 210 : 6	34 356 : 7	512 016 : 8	891 720 : 9

786. Түбәндәге бирелмәләр буенча мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез:

Бер сәгатькә бару тизлеге	Бару вакыты	Ераклык
12 *км*	4 сәг.	*x*
x	4 сәг.	48 *км*
12 *км*	*x*	48 *км*

787. Моторлы көймә, сәгатькә 30 *км* тизлек белән барып, ике пристань арасын 4 сәгатьтә үтте. Кире кайтканда бу араны 5 сәгатьтә үтте. Көймәнең кире кайткандагы тизлеген белергә.

788. Диңгез пароходы, тәүлеккә 576 шар *км* барып, ике шәһәр арасындагы юлны барганда 11 тәүлектә, кайтканда 9 тәүлектә үтте. Кайтканда бер тәүлеккә ничә километр юл үткән?

789. 48 162 : 3   270 030 : 5   328 290 : 6   523 × 609 : 7
71 256 : 4   392 576 : 8   414 054 : 9   705 × 248 : 8

790. Авыл советыннан колхоз идарәсенә кадәр булган юлга асфальт җәйделәр. Беренче 3 көндә һәр көнне 125 әр *м* җәйделәр, юлның калган өлешен, һәр көнне бертигез эшләп, 4 көндә бетерделәр. Соңгы 4 көндә ничәшәр метр юлга асфальт җәйгәннәр?



791. 1) Сөтчелек фермасында бер көнгә 1 680 *кг* сөт савып алдылар. Бу сөттән алынган каймак барлык сөт авырлыгының сигезенче өлешенә, ә май каймак авырлыгының өченче өлешенә тигез. Күпме май алынган?

2) Әгәр фермада бер көнгә 1 680 *кг* урынына 768 *кг* артыграк сөт савып алсалар, күпме май алырлар иде?

792. А һәм Б шәһәрләре арасындагы ераклык 360 *км* га тигез. Б һәм В арасындагы ераклык А белән Б арасының 5 нче өлешен, ә Б һәм Г арасы — өченче өлешен төзиләр. Б дан Г га кадәр булган ераклыкны табарга.



793. Мисаллар дөрес чишелгәнме?

1 368 : 8 × 504 = 86 184   15 345 : 5 : 9 × 606 = 206 646
3 681 : 9 × 328 = 134 152   24 288 : 8 : 6 × 702 = 355 212

794. Беренче участокта 10 820 төп агач, икенчесендә 1 976 төп кимрәк, ә өченчесендә, беренче һәм икенче участокларның икесендәгегә караганда, 2 тапкыр кимрәк агач бар. Өч участокта барлыгы ничә төп агач бар?

795. Сазлыкны киптерү өчен 3 640 *м* озынлыкта канау казырга кирәк иде. Беренче көнне бишенче өлешен, икенче көнне барлык канауның дүртенче өлешен казыдылар. Икенче көнне, беренче көнгә караганда, ничә метр артыграк казыганнар?

796. Фабрикага кыш ягу өчен 2 088 *т* торф хәзерләнгән иде. Беренче айда анын алтынчы өлешен, икенче айда барлык торфнын сигезенче өлешен яктылар. Күпме торф калган?

797. 1) Колхозда кышка 450 *т* тукранбаш печәне һәм 1 310 *т* болын печәне хәзерләнгән. Тукранбаш печәненең — алтынчы өлеше, болын печәненең бишенче өлеше язга калган. Кыш буе күпме тукранбаш печәне һәм күпме болын печәне тотылган?

2) Колхозда кышка 570 *т* тукранбаш печәне һәм 1 480 *т* болын печәне хәзерләнгән дип исәпләп, мәсьәләне яңадан чишегез.

798. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә бал тутырылган бер үк зурлыктагы 2 банка, икенче тәлинкәсенә 500 әр *г* лы 2 гер куелган. Буш банка 125 *г* авырлыкта килә. Һәр банкада ничәшәр грамм бал булган?

799. Үлчәүнең бер тәлинкәсенә көнбагыш мае салынган бердәй ике шешә куелган. Икенче тәлинкәсенә 1 *кг* һәм 200 *г* лы герләр куйгач, үлчәү тәлинкәләре тигезләнде. Буш шешәнең авырлыгы 175 *г*. Һәр шешәдә ничәшәр грамм май булган?

800. Бер токарь көнгә 138 деталь кыра. Икенче токарь (Коммунистик хезмәт бригадасы члены) беренче токарь 8 көндә кырган шундый ук детальләрне 6 көндә кырып өлгертә. Икенче токарь бер көнгә ничә деталь кыра?

801.

$(4879+137096):5$	$385\times 63:7:5$
$(120345-56727):3$	$492\times 75:4:3$
$(310020-84006):6$	$608\times 36:8:9$
$(732006-158940):9$	$804\times 305:6:5$

10 га һәм 100 гә бүлү.

802. 1) Колхоз бакчасында 10 рәт кура җиләге утыртылган. Һәр рәттә 75 әр төп булса, барлыгы ничә төп кура җиләге утыртылган?

2) 750 төп кура җиләген, һәр рәткә тигез итеп, 10 рәткә утыртканнар. Һәр рәткә ничәшәр төп кура җиләге утыртканнар?

803.

38×10	94×10	126×10	$2\,356\times 10$
$380:10$	$940:10$	$1\,260:10$	$23\,560:10$

804.	150 : 10	1 560 : 10	43 430 : 10	286 750 : 10
	320 : 10	4 800 : 10	72 080 : 10	609 800 : 10
	660 : 10	7 230 : 10	53 600 : 10	135 040 : 10

805. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

640 : 10   3 240 : 10   28 710 : 10   640 230 : 10

806. 1) Эшчеләрнең бер бригадасы 10 көн эчендә 7 360 *м*, икенчесе 450 *м* га артыграк тимер юл салды. Һәр бригада көнгә ничәшәр метр тимер юл салган?

2) Мәсьәлә шартындагы 7 360 санын 8 780 саны белән алмаштырып, мәсьәләне яңадан чишегез.

807. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

3 786 + 2 098   6 010 − 3 795   350 × 24   6 380 : 10

808. Телдән чишегез:

100 000 : 10 : 10 : 10 : 10 : 10   30 000 : 10 : 10 : 10 : 10
500 000 : 10 : 10 : 10 : 10 : 10   60 000 : 10 : 10 : 10 : 10

809. 1) Тегү мастерское өчен метры 24 әр сумнан 100 *м* тукыма сатып алганнар. Бу тукыма өчен күпме акча түләгәннәр?

2) Тегү фабрикасы өчен 2 400 сумга 100 *м* тукыма сатып алганнар. Бер метр тукыма ничә сум тора?

810.	45 × 100	72 × 100	135 × 100	648 × 100
	4 500 : 100	7 200 : 100	13 500 : 100	64 800 : 100

811.	1 000 : 100	10 000 : 100	100 000 : 100	693 500 : 100
	1 800 : 100	15 600 : 100	132 400 : 100	710 100 : 100
	4 900 : 100	62 100 : 100	257 300 : 100	900 000 : 100
	7 000 : 100	98 000 : 100	460 000 : 100	800 300 : 100

812. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

930 : 10   7 500 : 10   43 200 : 100   270 400 : 100

813. Бер автомашинага 3 000 *кг*, икенчесенә 5 000 *кг* шикәр комы төяделәр. Әгәр һәр капчыкта 100 әр *кг* шикәр комы булса, беренче машинага, икенчесенә караганда, ничә капчык кимрәк төялгән булыр?

814. Ике совхозның берсенә 48 мичкә, икенчесенә шундый ук 52 мичкә белән барлыгы 19 200 *л* керосин китерделәр. Һәр совхоз ничәшәр литр керосин алган?

815. 70 400 не 100 гә бүлүдән чыккан өлешне 96 га тапкырларга. Тапкырчыгыш 67 584 булырга тиеш. Сезнең дә шулай чыктымы?

816. 70 : 10 160 : 10 1 350 : 10 42 840 : 10
74 : 10 168 : 10 1 356 : 10 42 845 : 10

817. 600 : 100 1 500 : 100 32 400 : 100 125 600 : 100
675 : 100 1 580 : 100 32 410 : 100 125 636 : 100

818. 7 248 : 10 128 096 : 10 43 568 : 100 150 396 : 100
53 062 : 10 401 008 : 10 28 920 : 100 643 790 : 100

819. 1) Түбәндәге саннарның һәрберсендә ничә дистә бар:

3 780, 5 648, 45 035, 123 702?

2) Бу саннарның һәрберсендә ничә йөз бар?

820. (Телдән.) 1 200 тиен ничә сум була? 1 800 тиен? 2 500 тиен?

821. 900 *см* = ... *м* 60 *ц* = ... *т* 700 *кг* = ... *ц*
1 300 *см* = ... *м* 280 *ц* = ... *т* 3 200 *кг* = ... *ц*
1 800 *см* = ... *м* 460 *ц* = ... *т* 5 400 *кг* = ... *ц*

822. 5 396 : 10 54 620 : 100 43 280 : 10 : 4
48 072 : 10 273 946 : 100 298 400 : 100 : 8

Тулы дистәләргә һәм йөзләргә бүлү.

823. Телдән чишәргә:

60 : 20 80 : 20 30 × 8 60 × 7 50 × 9
60 : 30 90 : 30 40 × 9 90 × 6 70 × 8

824. 120 дә ничә тапкыр 40 бар?



120 : 40 =
12 дис : 4 дис. =

825. 120 *кг* сливаны, һәрберсенә 20 шәр *кг* салып, ящикларга тутырырга кирәк. Барлыгы ничә ящик кирәк булыр?

826.

150 : 30	240 : 60	320 : 40	400 : 80	270 : 90
140 : 20	210 : 70	350 : 50	360 : 90	420 : 60
120 : 30	250 : 50	320 : 80	490 : 70	560 : 80

827. Автомобиль 5 сәгатьтә 300 *км* юл үтте. Әгәр шул ук тизлек белән барса, 420 *км* юлны ул ничә сәгатьтә үтәр?

828. Түбәндәге кыскача язылган шарт буенча мәсьәлә төзегез:

200 сум — 5 *м*
320 сум — x

829.

180 : 30	480 : 60	450 : 50	560 : 70	350 : 70
160 : 20	270 : 30	640 : 80	360 : 40	630 : 90
300 : 50	280 : 40	540 : 60	720 : 90	480 : 80

830. 1) Бүленүче 170, бүлүче 30. Өлешне табарга.

2)

160 : 40	210 : 70	420 : 60	640 : 80	450 : 90
185 : 40	253 : 70	475 : 60	705 : 80	536 : 90

831. Өлешне һәм калдыкны табарга:

378 : 50	308 : 40	654 : 70	675 : 80	612 : 90
292 : 30	504 : 60	583 : 90	592 : 60	609 : 70

832.

2 160 : 40	6 840 : 90	45 500 : 70	576 000 : 80
3 180 : 60	6 720 : 70	53 280 : 80	364 740 : 60

833. Тегүче кул белән теккәндә бер минутка 50 чәнчем, гади тегү машинасында 1 500 чәнчем һәм тиз әйләнешле машинада 4000 чәнчем ясый ала. Тегүче машиналарның һәрберсендә, кул белән тегүгә карагандa, минутына ничә тапкыр артыграк чәнчем ясый?





834. 1) Тимер юлда һәр вагонга 60 ар *т* төяп 2 700 *т* күмер һәм һәрберсенә 50 шәр *т* төяп шулкадәр үк күмер озатылган. Нинди вагон күбрәк һәм ничәгә күбрәк булган?

2) Әгәр 2 700 *т* урынына 600 *т* кимрәк күмер озатсалар, нинди вагон күбрәк һәм ничәгә күбрәк кирәк булыр иде?

835. 2 340 : 30	29 340 : 60	73 760 : 40 + 29 785
4 320 : 80	43 650 : 50	135 780 : 60 — 1 906
5 310 : 90	397 600 : 80	485 640 : 90 — 2 078

836. 600 дә ничә тапкыр 200 бар?



600 : 200 =

6 йөз : 2 йөз =

837. 1 500 : 500	2 100 : 300	4 000 : 800	1 800 : 300
2 400 : 400	1 800 : 600	4 900 : 700	4 500 : 500
3 600 : 900	4 500 : 500	6 300 : 700	4 800 : 800

838. Өлешне һәм калдыкны табарга:

1 700 : 200	2 600 : 300	3 940 : 700	2 306 : 500
3 700 : 400	3 900 : 600	5 310 : 800	2 758 : 400
2 800 : 600	5 800 : 700	4 806 : 900	5 028 : 600
3 600 : 800	4 700 : 700	3 728 : 600	6 152 : 900

839. Укучылар санына карап, ике мәктәпкә дәфтәрләр бүлеп бирелгән. Беренче мәктәптә 528 укучы, икенче мәктәптә 128 укучы булган. Әгәр икенче мәктәп, беренчесенә караганда, 2 400 дәфтәр кимрәк алган булса, һәр мәктәп ничәшәр дәфтәр алган булыр?

840. Телдән чишәргә:

300 × 4	700 × 7	58 : 6	43 : 9
500 × 8	900 × 6	47 : 7	70 : 8

841. 1 520 : 200	2 070 : 300	3 150 : 500	3 840 : 400
15 200 : 200	20 700 : 300	31 500 : 500	38 400 : 400

842. 37 500 : 500	58 800 : 700	524 100 : 300	595 000 : 700
52 200 : 600	62 400 : 800	658 500 : 500	378 000 : 900
57 600 : 800	61 200 : 900	745 600 : 800	684 000 : 600

843. Бер самолёт 6 000 *км* араны сәгатькә 600 *км* тизлек белән, икенче самолёт шул ук араны сәгатькә 400 *км* тизлек белән очкан. Кайсы самолёт озаграк һәм ничә сәгать артыграк очкан?

844. 37 600 : 400	552 000 : 300	648 × 600 : 800
41 400 : 600	431 900 : 700	576 × 700 : 600
52 200 : 900	475 200 : 800	405 × 800 : 900

Икеурынлы санга бүлү.

845. Телдән чишәргә:

240 : 40	320 : 80	26 : 3	38 : 4	52 × 7	63 × 6
420 : 70	450 : 90	42 : 5	50 : 8	34 × 5	88 × 4

846. Поезд сәгатькә 52 *км* тизлек белән барса, 156 *км* юлны ничә сәгатьтә үтәр?

847. 1) 129 : 43	192 : 32	195 : 65	364 : 52	387 : 43
147 : 21	212 : 53	360 : 72	675 : 75	378 : 63
208 : 52	230 : 46	504 : 84	752 : 94	430 : 86

2) 430 да ничә тапкыр 86 бар? 430 саны 86 дан ничә тапкыр зур? 430 ны 86 тапкыр киметсәң, ничә була?

Бу сораулар нинди гамәл белән чишеләләр?

848. Колхоз 364 *т* бодай, аңар караганда 76 *т* кимрәк арыш, арышка караганда 32 тапкыр кимрәк карабодай сатты. Сорау куярга һәм мәсьәләне чишәргә.

849. Пароходка 176 *т* он, онга караганда 22 тапкыр кимрәк ярма, ярмага караганда 2 *т* кимрәк шикәр төяделәр. Пароходка барлыгы ничә тонна азык төягәннәр?

850. 136 : 34	476 : 68	510 : 85	(6 351 — 5 379) : 54
270 : 45	828 : 92	448 : 56	(8 260 — 7 924) : 56
285 : 57	532 : 76	679 : 97	(10 000 — 9 335) : 95

851. (Телдән.) 45 не 5 кә, 6 га, 7 гә, 8 гә, 9 га бүләргә. 38 не дә шул саннарның һәркайсына бүләргә.

852. Бүленүче 190, бүлүче 45. Өлешне һәм калдыкны табарга.

853. Өлешне һәм калдыкны табарга:

270 : 52	330 : 63	358 : 44	510 : 83	142 : 42
190 : 46	260 : 32	462 : 85	623 : 76	487 : 94

854. 1) 1 428 : 42	1 485 : 33	3 420 : 76	5 544 : 84
1 584 : 22	4 482 : 54	2 924 : 68	6 080 : 95

2) 6 080 не 95 тапкыр кечерәйтсәң, ничә булыр?

6 080 эчендә ничә тапкыр 95 бар?

6 080 саны 95 тән ничә тапкыр зур?

855. Колхоз бакчасында 1 476 төп җимеш агачын рәт-рәт итеп утыртканнар. 510 төп агачны һәр рәткә 34 әр төп, ә калганнарын һәр рәткә 42 шәр төп итеп утырткан булсалар, бакчада барлыгы ничә рәт агач бар?

856. 2 116 ны 92 гә бүлүдән чыккан өлеш 1 092 не 84 кә бүлүдән чыккан өлештән ничәгә зур?

857. 2 080 не 65 кә бүлүдән чыккан өлеш 1 152 не 72 гә бүлүдән чыккан өлештән ничә тапкыр зур?

858.	1 155 : 21	2 074 : 34	3 905 : 55	(70 010 — 66 542) : 68
	1 344 : 42	4 316 : 52	5 978 : 61	(30 104 — 27 332) : 33
	3 392 : 64	3 124 : 71	3 996 : 74	(51 480 — 43 200) : 72

859. (Телдән.) 1) 48 не 5 кә, 7 гә, 8 гә, 9 га бүләргә һәм калдыкны әйтергә.

2) 52 не 6 га, 7 гә, 8 гә, 9 га бүләргә һәм калдыкны әйтергә.

860.	15 120 : 42	29 736 : 56	229 620 : 43
	34 020 : 63	62 269 : 73	438 900 : 95
	46 084 : 82	62 664 : 84	136 576 : 64

861. Һәр йөк автомобиленә 3 әр *т* күмер төяп, көненә 5 әр тапкыр барып кайтсалар, 540 *т* күмерне өч йөк автомобиле белән ничә көндә ташып бетерергә мөмкин?

862. Совхоз шәһәргә 1 344 *т* бәрәңге җибәрергә тиеш. Әгәр һәр йөк автомобиленә 4 әр тонна бәрәңге төяп көнгә 3 тапкыр барсалар, бу бәрәңгене 8 йөк автомобиле белән ничә көндә ташып бетерергә мөмкин?

863. Мисалларны чишәргә һәм дөреслеген тикшерергә:

24 300 : 75	32 384 : 92	349 800 : 66	369 260 : 74

864. (Телдән.) 64, 75, 90 саннары нинди саннарга калдыксыз бүленә?

865. (Телдән.) 24×6 26×8 34×6 63×9 48×7
43×4 35×5 53×7 72×8 94×6

866. Өлешне һәм калдыкны табарга:

270 : 56	385 : 65	318 : 35	272 : 98	377 : 57
230 : 34	457 : 58	266 : 47	360 : 76	428 : 88

867.	3 212 : 44	1 254 : 38	3 854 : 47	7 081 : 73
	2 520 : 35	4 558 : 53	7 220 : 76	6 141 : 69

868. (Телдән.) Түбәндә бирелгәннәрдән чыгып, мәсьәләләр төзегез һәм аны чишегез:

Тизлек	Вакыт	Юл
Сәгатькә 40 *км*	7 сәгать	*x*
Минутка 5 *км*	30 минут	*x*
x	3 сәгать	180 *км*
x	10 минут	20 *км*
Сәгатькә 50 *км*	*x*	200 *км*
Сәгатькә 12 *км*	*x*	60 *км*

869. Пароход 32 сәгатькә 768 *км* юл үткән. Әгәр ул бару тизлеген сәгатькә 3 *км* га арттырса, 1 764 *км* юлны ничә сәгатьтә үтәр?

870.

1 998 : 37	5 610 : 66	23 832 : 36	378 000 : 45
4 350 : 58	5 304 : 78	11 475 : 27	501 600 : 57
2 538 : 47	3 060 : 68	30 576 : 49	524 400 : 69

871. Мисаллар дөрес чишелгәнме?

$7\,906 : 59 \times 87 = 11\,658$ $\qquad$ $6\,612 : 87 \times 98 = 7\,448.$

872. Өлешне һәм калдыкны табарга:

340 : 48	416 : 57	251 : 39	678 : 98	606 : 68
212 : 36	554 : 66	365 : 48	749 : 87	912 : 96

873.

20 044 : 37	15 625 : 25	619 348 : 67	352 608 : 48
42 572 : 58	33 948 : 46	753 028 : 79	531 328 : 56

874. Әгәр бодайны тарттырганда барлык бодайның алтынчы өлеше көрпәгә киткән булса, һәм һәрбер капчыкка 75 әр *кг* он салган булсалар, 1 620 *кг* бодайдан ничә капчык он чыккан?

875. Әгәр барлык тарының бишенче өлеше кибәккә китсә һәм һәрбер капчыкка 84 әр *кг* ярма салынса, 1470 *кг* тарыдан ничә капчык ярма чыккан булыр?

876.

17 696 : 28	38 385 : 45	114 291 : 27	575 416 : 68
48 952 : 58	26 784 : 36	368 632 : 59	729 846 : 78

877. (Телдән.) 1) 12 санын берурынлы саннарның һәрберсенә тапкырларга.

2) 14 не 3 кә, 5 кә, 7 гә тапкырларга.

3) 19 ны 2 гә, 4 кә, 5 кә тапкырларга.

Дөрес тапкырлагансызмы, 2 нче номерлы таблица буенча (165 нче биттә) тикшерегез.

878. (Телдән.)

72 : 12	52 : 13	48 : 16	90 : 18
720 : 12	520 : 13	480 : 16	900 : 18

879.

690 : 15	5 760 : 18	6 810 : 15	84 564 : 27
490 : 14	9 760 : 16	3 791 : 17	98 592 : 16
689 : 13	7 980 : 19	6 688 : 19	63 576 : 18

880. Инкубаторга бер ел эчендә 14 тапкыр 840 ар йомырка куйганнар. Барлык йомыркаларның уникенче өлешеннән чебешләр чыкмаган. Бер ел эчендә ничә чебеш чыккан?



881. 4 зур инкубаторга 52 000 әр йомырка куйганнар. Әгәр һәр утырган тавык астына 16 шар йомырка куйсаң, инкубаторга куйган йомыркаларны бастыру өчен ничә тавык кирәк булыр иде?

882. 7 560 саны 18 дән ничә тапкыр зуррак?

7 560 саны 18 дән ничәгә зуррак?

883.

945 : 15	6 120 : 18	7 296 : 16	60 125 : 13
702 : 13	5 950 : 17	6 517 : 19	93 852 : 18
616 : 14	8 060 : 13	4 572 : 18	63 456 : 19

884. (Телдән.) 15, 17 саннарын берурынлы саннарның һәрберсенә тапкырларга.

885. 110 *кг* помидорны һәрберсенә 12 шәр *кг* итеп ящикларга тутырырга кирәк. Ничә тулы ящик булыр? Ничә килограмм помидор артып калыр?

886. Өлешне һәм калдыкны табарга:

105 : 12	110 : 14	125 : 16	141 : 17	146 : 28
132 : 15	126 : 13	135 : 18	135 : 19	218 : 26

887.

1 260 : 15	1 134 : 14	1 536 : 16	30 100 : 35
1 118 : 13	1 314 : 18	1 615 : 17	24 700 : 26

888. 1) Укучыларның ике бригадасы колхоз бакчасында слива җыюда булышкан. Беренче бригада 40 ящик слива, икенчесе шундый ук 22 ящик слива җыеп алган. Беренче бригада икенчесеннән 252 *кг* слива артыграк җыйган. Һәр бригада ничәшәр килограмм слива җыйган?

2) Үзегезнең җәмгыятькә файдалы эшләрегез турында мәсьәлә төзегез.

889. Колхозчыларның ике бригадасы бергә 4 400 *кг* бәрәңге алган. Беренче бригада 43 капчык, икенчесе шундый ук 45 капчык бәрәңге алган булса, һәр бригада ничәшәр килограмм бәрәңге алган?

890. 1 104 : 12   2 324 : 28   1 242 : 18   12 350 : 19
1 309 : 17   1 176 : 14   2 548 : 26   22 320 : 36

891. (Телдән.) Абыйсы сеңелесе белән 60 ар *м* озынлыктагы ике түтәлне утарга тиеш иде. Эшнең беренче сәгатендә абыйсы түтәлнең унынчы өлешен, ә сеңелесе — уникенче өлешен утады. Эшнең беренче сәгатендә аларның кайсы күбрәк һәм ничә метр артыграк утаган?

892. 120 санының унынчы өлешен табарга. 96 санының уникенче өлешен табарга. 11 184 санының уникенче өлешен табарга.

893. Төзелешкә 1 680 *т* төзү материаллары китерделәр. Барлык йөкнең унынчы өлеше известь, уникенче өлеше цемент, калганы таш. Ничә тонна таш китерелгән? (Чишелешнең дөреслеген тикшерегез.)

894. 14 784 : 16   11 610 : 18   254 306 : 26   239 686 : 37
18 900 : 25   11 088 : 12   597 090 : 39   327 870 : 45

895. 751 464 : 84   117 782 : 14 $5\,040 \times 56 : 28$
649 512 : 93   124 686 : 18 $4\,860 \times 81 : 27$

896. (Телдән.) Түбәндә бирелгәннәрдән чыгып, мәсьәләләр төзегез һәм чишегез:

Бер предметның хакы	Предметның саны	Бәясе
20 сум 18 тиен	6 4	x x
x x	3 5	45 тиен 60 сум
8 тиен 30 сум	x x	40 тиен 120 сум

897. (Телдән.) Бер апа 36 тиенгә 9 ар тиеннән стаканнар сатып алган. Икенче апа 54 тиенгә шундый ук берничә стакан сатып алган. Бу апалар ничәшәр стакан алганнар?

898. (Телдән.) Ике кыз бергә 10 *м* тасма сатып алган. Кызларның берсе 90 тиен, икенчесе 60 тиен акча түләгән. Кызлар ничәшәр метр тасма алганнар?

899. 48 *м* һәм 54 *м* лы ике кисәк тукымадан бердәй 34 күлмәк тектеләр. Һәр кисәктән ничәшәр күлмәк теккәннәр?

900. Туку фабрикасы бер тапкыр 84 *ц*, икенче тапкыр 108 *ц*, һәрберсе тигез авырлыкта булган 96 кип мамык алган. Фабрика беренче һәм икенче тапкыр алуда ничәшәр кип мамык алган?



901. Завод ике көндә 81 ящик кадак: беренче көнне 1 344 *кг*, ә икенче көнне 1248 *кг* кадак хәзерләгән. Завод беренче көнне ничә ящик һәм икенче көнне ничә ящик кадак хәзерләгән?

902. Һәрбер мисалда нәрсә билгеле, нәрсә билгесез:

$$x + 23\,576 = 40\,218 \qquad x - 4\,729 = 15\,040$$
$$13\,680 + x = 25\,014 \qquad x : 475 = 615$$

Билгесез санны табыгыз һәм соңыннан тикшерегез, дөрес табылганмы?

903. 5 760 ны 45 кә бүлгәч чыккан өлеш 1 152 не 18 гә бүлгәч чыккан өлештән ничә тапкыр артыграк?

904. Совет самолёты тукталмыйча 21 сәгатькә 16 947 *км* очты. Самолётның бер сәгатькә очу тизлеген исәпләргә.

905. 20 852 : 52 120 135 : 15 390 520 : 65 780 702 : 78
57 288 : 44 162 072 : 18 499 296 : 96 970 582 : 97

906. 25 680 не 16 га бүлүдән чыккан өлеш 18 675 не 25 кә бүлүдән чыккан өлештән ничәгә зуррак?

907. 10 896 : 12 11 951 : 17 477 959 : 59 282 094 : 47
43 290 : 18 13 052 : 26 380 684 : 76 602 086 : 86

908. $84\,560 : 14 \times 65$ $17\,875 : 13 : 11 \times 60$
$36\,144 : 72 \times 88$ $182\,400 : 24 : 25 \times 70$

909. 1) 28 булсын өчен, нинди санны 4 кә тапкырларга кирәк?

$$x \cdot 4 = 28$$

2) 72 булсын өчен 8 не нинди санга тапкырларга кирәк?

$$8 \cdot x = 72$$

910. 1) Тапкырлanучы 12, тапкырчыгыш 156. Тапкырлаучыны табарга.

2) Тапкырлашучыларның берсе 16, тапкырчыгыш 240. Икенче тапкырлашучыны табарга.

3) $7 \cdot x = 231$. $15 \cdot x = 240$ $36 \cdot x = 504$

Тапкырлау:	Дөреслеген тикшерү:
1) $7 \cdot 9 = 63$	1) $63 : 7 = 9$ яки $63 : 9 = 7$
2) $36 \cdot 24 = 864$	2) $864 : 36 = 24$ яки $864 : 24 = 36$

Тапкырлауның дөреслеген тикшерү өчен, тапкырчыгышны тапкырлашучыларның берсенә бүләләр. Әгәр икенче тапкырлашучы килеп чыкса, тапкырлау дөрес эшләнгән була.

911. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген бүлү белән тикшерегез:

14×26 24×15 72×18 56×38
17×12 36×16 94×15 84×46

912. (Телдән.) Бер малай 44 тиенгә, икенчесе 72 тиенгә төсле карандашлар сатып алды. Икенче малай, беренчегә караганда, 7 карандаш артыграк алды. Һәр малай ничәшәр карандаш алган?

913. 20 *кг* чия вареньесын һәм 32 *кг* кура җиләге вареньесын бер үк зурлыктагы банкаларга бүлеп салганнар. Әгәр кура җиләге вареньесының, чиягә караганда, 3 банка артыграк икәне билгеле булса, теге һәм бу варенье ничәшәр банка булган?

914. 1) Комсомоллар һәм пионерлар совхозда фрукты җыярга булышканнар. Комсомоллар 600 *кг*, ә пионерлар 360 *кг* фрукты җыйганнар. Комсомоллар, пионерларга караганда, 12 ящик фрукты артыграк җыйганнар. Әгәр фруктылар һәр ящикта бертигез булсалар, комсомоллар һәм пионерлар ничәшәр ящик фрукты җыйганнар?

2) Зурларга хезмәттә булышуыгыз турында мәсьәлә төзегез.

915. Май заводы беренче көнне 840 *кг* май, икенче көнне 1 080 *кг* май хәзерләде. Икенче көнне, беренче көнгә караганда, 2 мичкә май артыграк хәзерләде. Әгәр барлык мичкәләрдә дә май бертигез булса, завод икенче көнне ничә мичкә май хәзерләгән булыр?

916. 13 560 : 15	751 464 : 84	607 992 : 77	943 290 : 47
11 495 : 19	649 512 : 93	481 620 : 69	378 436 : 74

917. 18 108 не 36 га бүлүдән чыккан өлешне 704 кә тапкырларга. Тапкырчыгыш 354 112 булырга тиеш. Синең дә шулай чыктымы?

918. Колхоз бакчасында 84 алмагачтан 60 ар *кг* һәм 96 алмагачтан 56 шар *кг* алма җыеп алдылар. Әгәр ящикка 28 әр *кг* алма салсалар, җыелган алмаларны озату өчен ничә ящик кирәк булыр?

919. Шахтада февраль аеның беренче 15 көнендә һәр көнне 360 шар *т*, калган 9 көнендә һәр көнне 400 әр *т* күмер чыгарганнар. Әгәр һәр вагонга 50 шәр *т* күмер төясәләр, бу айда чыгарылган күмерне җибәрү өчен ничә вагон кирәк булыр?

920. Эшчеләрнең ике бригадасы телефон линиясе өчен 1 260 багана хәзерләде. Бер бригада көнгә 28 багана, икенче бригада 42 багана хәзерләде. Баганалар ничә көндә хәзерләнгән?

921. Колхозчыларның ике бригадасы, бер үк вакытта эшләп, 492 *ц* орлык чистартты. Бер бригада көнгә 40 *ц*, ә икенчесе

көнгә 42 *ц* орлык чистартты. Орлык чистарту ничә көндә үтәлгән? Һәр бригада ничәшәр центнер орлык чистарткан?

922. Бер амбарда 730 *ц* орлык булган, аннан унынчы өлешен алганнар. Икенче амбарда 912 *ц* орлык булган, аннан уникенче өлешен алганнар. Ике амбардан барлыгы ничә центнер орлык алганнар?

923. (Телдән.) Комсомоллар чаңгыда походка киткәннәр. Аларга 36 *км* юл үтәргә кирәк булган. Беренче 12 *км* ны алар сәгатькә 6 *км* тизлек белән үткәннәр. Барлык юлны 5 сәгатьтә үтү өчен, юлның калган өлешен сәгатькә нинди тизлек белән барырга тиешләр?



924. Ике пристань арасы 672 *км*. Шуннан 168 *км* араны катер сәгатькә 28 *км* тизлек белән үтте. Бу юлның барысын 20 сәгатьтә үтәр өчен, катер калган юлны сәгатькә нинди тизлек белән барырга тиеш? (Мәсьәләне чишү өчен сызым сызыгыз.)

925. Ике порт арасы 504 *км*. Диңгез пароходының капитаны бер порттагы йөкне икенче портка 18 сәгать эчендә илтеп җиткерергә йөкләмә алды. Пароход 312 *км* ны сәгатькә 26 *км* тизлек белән барды. Йөкләмәне билгеләнгән срокта үтәр өчен, калган юлны ул нинди тизлек белән барырга тиеш?

926. Эшчеләрнең ике бригадасы 360 *км* озынлыкта телефон линиясе үткәрде. Беренче бригада ай саен 34 *км*, икенче бригада 38 *км* үткәрде. Әгәр ике бригаданың эшләгән айлар саны бертигез булса, һәр бригада ничәшәр километр телефон линиясе үткәргән булыр?

927. Прицеплы автомашина белән 1 008 капчык солыны ташырга кирәк. Һәр баруда машинага 56 шар капчык, ә прицепка ике тапкыр кимрәк төяделәр. Барлык солыны ташып бетерер өчен, машина ничә тапкыр барып кайтырга тиеш?

928. Сатин юрганның берсе 6 сум тора, шундый 12 юрган акчасына 8 йон юрган алып була. Интернат-мәктәп өчен 60 данә йон юрган алганнар. Бу юрганнар өчен күпме акча түләнгән?

929. $(650\,004 - 9\,396) : 12$ $216 \times 72 : 32$
$(120\,402 - 13\,860) : 18$ $632 \times 57 : 24$
$(172\,000 - 8\,675) : 25$ $756 \times 90 : 56$
$(840\,060 - 219\,168) : 36$ $384 \times 76 : 48$

930. $512 \times 65 : 16$ $645 \times 95 : 75$ $648 \times 58 : 18 : 12$
$448 \times 70 : 28$ $308 \times 75 : 35$ $315 \times 95 : 45 : 15$
$630 \times 72 : 45$ $909 \times 51 : 27$ $603 \times 82 : 18 : 67$
$416 \times 88 : 32$ $678 \times 84 : 36$ $768 \times 57 : 24 : 96$

Кара-каршы хәрәкәткә мәсьәләләр.

I.

931. Мәсьәләдә поездның нинди тизлек белән баруы һәм күпме вакыт юлда булуы билгеле. Ераклыкны нинди гамәл ярдәмендә белеп булыр? (Шундый мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.)

932. Ике жәяүле бер үк вакытта ике авылдан бер-берсенә каршы юлга чыккан һәм 3 сәгатьтән соң алар очрашканнар. Беренче жәяүле сәгатькә 4 *км*, икенчесе 5 *км* юл барган. Бу авыллар арасындагы ераклыкны табарга?

Бу мәсьәләне Барый белән Наилә икесе ике төрле чишкән:



Барый болай чишкән:

1) $4\ км \times 3 = 12\ км$
2) $5\ км \times 3 = 15\ км$
3) $12\ км + 15\ км = 27\ км$

Наилә болай чишкән:

1) $4\ км + 5\ км = 9\ км$
2) $9\ км \times 3 = 27\ км$

Мәсьәләне чишкәндә Барый ничек фикер йөрткән? Наилә ничек фикер йөрткән? Кайсы юл белән чишү яхшырак?

933. Ике пристаньнан бер үк вакытта ике пароход бер-берсенә каршы юлга чыккан һәм алар 7 сәгатьтән соң очрашканнар. Беренче пароход сәгатькә 22 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 27 *км* тизлек белән барган. Ике пристань арасы нинди ераклыкта булган?

934. Ике шәһәрдән бер үк вакытта ике жиңел автомашина бер-берсенә каршы юлга чыккан һәм алар 4 сәгатьтән соң

очрашканнар. Машиналарның берсе сәгатькә 65 *км* тизлек белән, ә икенчесе сәгатькә 10 *км* га артыграк тизлек белән барган. Бу шәһәрләр арасындагы ераклыкны табарга.

935. Мәскәүдән һәм Ленинградтан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан. Аларның берсе сәгатькә 48 *км* тизлек белән, икенчесе 3 *км* кимрәк тизлек белән барган. 7 сәгать баргач, поездлар очрашканнар. Мәскәүдән Ленинградка кадәр ничә километр?

936. Ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан һәм икесе дә сәгатькә 52 шәр *км* тизлек белән хәрәкәт иткән. 5 сәгатьтән соң поездлар очрашканнар. Ике шәһәр арасындагы ераклыкны табарга.

937. Ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике автомобиль юлга чыккан һәм 4 сәгатьтән соң алар очрашканнар. Берсе сәгатькә 48 *км*, икенчесе 6 *км* артыграк барган. Шәһәрләр арасы нинди ераклыкта?

938. Ике аэродромнан бер үк вакытта ике самолёт күтәрелеп, бер-берсенә каршы оча башлый. Бер самолётның очу тизлеге сәгатькә 320 *км*, икенчесенең очу тизлеге өч тапкыр артыграк. Самолётлар 2 сәгатьтән соң очрашканнар. Очрашканга кадәр һәр самолёт ничәшәр километр юл үткән?

939. Түбәндәге сызым буенча мәсьәлә төзегез һәм чишегез.



940. Әтисе һәм ун яшьлек улы бер үк вакытта ике авылдан бер-берсенә каршы юлга чыктылар һәм... сәгатьтән соң очраштылар. Әтисе сәгатькә ... *км* тизлек белән, улы сәгатькә ... *км* тизлек белән барды. Сорау куегыз, кирәкле саннарны куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

II.

941. Мәсьәләдә пароходның нинди ераклыкны үткәне һәм нинди тизлек белән үткәне билгеле. Пароходның күпме вакыт барганын нинди гамәл белән белеп булыр? (Шундый мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.)

942. Пионерларның ике отряды аралары 21 *км* булган А һәм Б авылларыннан бер үк вакытта бер-берсенә каршы юлга чыккан. Беренче отряд пионерлары сәгатькә 4 *км* тизлек белән, икенче отряд пионерлары 3 *км* тизлек белән барганнар.

1) Пионерлар 1 сәгатьтә бер-берсенә ничә километрга якынлашканнар?

2) Алар ничә сәгатьтән соң очрашканнар?



943. Аралары 520 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан. Беренче поезд сәгатькә 50 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 54 *км* тизлек белән барган. Поездлар ничә сәгатьтән соң очрашканнар?

944. Эшчеләрнең ике бригадасы бер үк вакытта 20 *км* озынлыгындагы тимер юл тармагының ике башыннан бер-берсенә каршы төзәтеп килә. Беренче бригада һәр көн 2 *км* юлны, икенче бригада 3 *км* юлны төзәтә. Ике бригада ремонт эшен ничә көннән соң тәмамлар?

945. Ике йөзүче бер үк вакытта бер-берсенә каршы йөзеп китте. Берсе минутка 95 *м*, икенчесе 85 *м* тизлек белән йөзә. Алар арасындагы ераклык башта 3 600 *м* иде. Йөзүчеләр ничә минуттан соң очрашырлар?

946. Аралары 736 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыккан. Беренче поезд сәгатькә 47 *км*, ә икенчесе сәгатькә 45 *км* тизлек белән барган. Очрашканчы һәр поезд ничә километр юл үткән?

947. Аралары 33 *км* булган ике авылдан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике җәяүле юлга чыкты. Аларның берсе сәгатькә... *км*, икенчесе ... *км* юл үтте. Җәяүлеләр ничә сәгатьтән соң очрашырлар?

Саннар куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

III.

948. Мәсьәләдә поездның нинди ераклыкны үткәне һәм хәрәкәт вакыты билгеле. Бу бирелмәләрдән нәрсәне белеп була? Нинди гамәл белән эшләнә? (Шундый мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.)

949. Мәскәүдән Тулага кадәр 180 *км*. Бу шәһәрләрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике йөк автомобиле юлга чыккан. Алар 2 сәгатьтән соң очрашканнар. Аларның берсе сәгатькә 40 *км* үткән. Икенче машина бер сәгатькә ничә километр юл үткән?



950. Аралары 72 *км* булган А һәм Б пунктыннан бер үк вакытта бер-берсенә каршы чаңгычыларның ике командасы юлга чыкты һәм алар 4 сәгатьтән соң очраштылар. Беренче команда сәгатькә 10 *км* үтте. Икенче команда сәгатькә ничә километр үткән?

951. Мәскәүдән һәм Ленинградтан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыкты һәм алар 7 сәгатьтән соң очраштылар. Мәскәү поезды сәгатькә 45 *км* тизлек белән барды. Ленинград поезды нинди тизлек белән барган? (Мәскәүдән Ленинградка кадәр 651 *км*.)

952. Аралары 36 *км* булган ике авылдан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике җәяүле юлга чыкты һәм ... сәгатьтән соң алар очраштылар. Бер юлчы сәгатькә ... *км* тизлек белән барды. Сорау куегыз, саннар куегыз һәм чишегез.

953. Түбәндәге сызым буенча мәсьәлә төзегез һәм аны чишегез.



IV.

Сез хәрәкәткә карата мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә чишә аласызмы, үзегезне тикшереп карагыз.

954. Ике пароход бер үк вакытта ике пристаньнан бер-берсенә каршы юлга чыккан һәм алар 2 сәгатьтән соң очрашканнар. Бер пароход сәгатькә 25 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 30 *км* тизлек белән барган. Пристаньнар арасындагы ераклыкны табарга.

955. Ике пристаньнан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике пароход юлга чыккан. Пароходлар 6 сәгатьтән соң очрашканнар. Пароходларның берсе сәгатькә 24 *км*, икенчесе 20 *км* тизлек белән барса, бу пристаньнар арасындагы ераклык күпме булыр?

956. Чаңгычыларның ике командасы аралары 60 *км* булган ике авылдан бер үк вакытта бер-берсенә каршы юлга чыкты. Беренче команда сәгатькә 11 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 9 *км* тизлек белән барды. Алар ничә сәгатьтән соң очрашканнар? Очрашканчы һәр команда ничә километр юл үткән?

957. Моторлы ике көймә бер үк вакытта аралары 280 *км* булган ике пристаньнан бер-берсенә каршы юлга чыккан. Көймәләр 4 сәгатьтән соң очрашканнар. Беренче көймә сәгатькә 33 *км* тизлек белән барган. Икенче көймә нинди тизлек белән барган?

958. $(79\,608 + 265\,976 + 7\,090) - (31\,000 - 5\,906)$
$(420\,010 - 380\,698) - (100\,900 - 70\,890)$

959. $428 \times 68 : 32 \times 47$ $\quad 609 \times 76 : 14 \times 57$
$315 \times 89 : 35 \times 79$ $\quad 645 \times 98 : 15 \times 87$

960. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

$30\,708 + 94\,059$ $\quad 485 \times 87$ $\quad 932\,750 : 25$
$75\,062 - 48\,395$ $\quad 640 \times 38$ $\quad 630\,540 : 45$

Кабатлау.

Телдән чишү өчен.

961. $24 \times 3 : 6 + 48$ $\quad 60 \times 9 : 3 + 120$
$65 : 5 \times 6 - 29$ $\quad 30 \times 8 : 2 - 90$
$45 : 3 \times 5 - 36$ $\quad 540 : 2 \times 3 - 210$
$84 : 6 \times 3 - 18$ $\quad 640 : 4 \times 2 - 180$

962. 1) 80 не 6 тапкыр зурайтырга, килеп чыккан санны 3 тапкыр кечерәйтергә, яңа чыккан санны 120 гә зурайтырга.

2) 420 не 7 тапкыр кечерәйтергә, килеп чыккан санны 4 тапкыр зурайтырга, яңа килеп чыккан санны 80 гә кечерәйтергә.

963. 840 дәфтәрне, класстагы укучылар санына карап, ике класска бүлеп бирергә кирәк. Бер класста 40 укучы, икенчесендә 44 укучы бар. Һәр класс ничәшәр дәфтәр алырга тиеш?

964. Пионерлар ике көн походта булдылар. Беренче көнне алар 24 *км*, икенче көнне 16 *км* юл үттеләр. Әгәр бер үк тизлек белән барлыгы 10 сәгать барган булсалар, пионерлар беренче көнне ничә сәгать һәм икенче көнне ничә сәгать барган булырлар?

965. Бер участоктан 5 кәрзин, икенчесеннән шундый ук 3 кәрзин җир җиләге җыйдылар. Беренче участоктан, икенчегә караганда, җир җиләген 30 *кг* артыграк җыйдылар. Һәр участоктан ничәшәр килограмм җир җиләге җыелган?

966. Бер участоктан 90 *кг*, икенчесеннән 60 *кг* җир җиләге җыйдылар. Беренче участоктан, икенчесенә караганда, 2 кәрзин җир җиләге артыграк җыелган. Әгәр һәр кәрзингә җир җиләген бертигез салган булсалар, һәр участоктан ничәшәр кәрзин җиләк җыйганнар?

967. Шофёр 70 *т* ашлык ташырга тиеш иде. Иген ташу эшен тизләтү өчен, ул 3 прицептан файдаланды. Һәр баруда машинага 5 әр *т*, һәр прицепка 3 әр *т* ашлык төяде. Ул бөтен игенне ничә баруда ташып бетерде?

968. Эшчеләрнең ике бригадасы, бер үк вакытта эшләп, электрүткәргеч өчен 150 багана утыртты. Бер бригада һәр көнне 26 шар багана, икенчесе 24 әр багана утыртты. Һәр бригада ничәшәр көн эшләгән?

969. Совхоздан фабрикага 40 *т* йон илтергә кирәк иде. Йонны ике йөк машинасы белән ташыдылар. Һәр баруда бер йөк машинасына 2 шәр *т*, икенчесенә 3 әр *т* йон төяделәр. Машиналар ясаган рейслар саны тигез булса, һәр машина күпмешәр йон илткән булырлар?

970. Колхозчыларның ике бригадасы, бергә эшләп, 900 *т* силос хәзерләгән. Беренче бригада һәр көнне 40 ар *т*, икенче бригада 50 шәр *т* силос хәзерләгән. Әгәр аларның эш көннәре саны бертигез булса, һәр бригада ничәшәр тонна силос хәзерләгән булыр?

971. 150 *кг* помидорны ящикларга тутырдылар. 60 *кг* помидорны һәр ящикка 10 ар *кг* итеп, калганнарын һәр ящикка 9 ар *кг* итеп тутырдылар. Барлык помидор өчен ничә ящик кирәк булган?

972. Җәяүлегә 24 *км* юл үтәргә кирәк иде. Бу юлның яртысын ул сәгатькә 4 *км* тизлек белән үтте. Барлык юлны 5 сәгатьтә үтәр өчен, калган юлны ул сәгатькә ничә километр тизлек белән үтәргә тиеш?

973. Мебель фабрикасы 480 партаны 15 көндә эшләп бетерергә йөкләмә алган. Фабрика эшчеләре көнгә 40 ар парта эшләгәннәр. Алар йөкләмәне ничә көн элек үтәгәннәр?

974. Мастерской 280 чәчкеч ремонтларга тиеш булган. Ул һәр көнне 20 шәр чәчкеч ремонтлаган. Әгәр бу эшне план буенча 17 көндә бетерергә тиеш булган булса, ремонтны ул срогыннан ничә көн элек бетергән булыр?

975. 1) Моторлы көймәгә 220 *км* юл үтәргә кирәк булган. Беренче 60 *км* ны ул сәгатькә 30 *км* тизлек белән, калган юлны сәгатькә 40 *км* тизлек белән үткән. Көймә барлык юлны ничә сәгатьтә үткән?

2) Мәсьәлә шартындагы 220 саны урынына 300 санын куеп, мәсьәләне яңадан чишегез.

976. Велосипедта баручылар ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы юлга чыктылар. Аларның берсе сәгатькә 13 *км*, икенчесе 15 *км* юл үтте. 3 сәгатьтән соң алар очраштылар. Ике шәһәр арасындагы ераклыкны табарга.

977. Завод эшчеләре апрель аеның беренче 16 эш көнендә 320 станок, аннан соң элеккегедән көнгә 5 станок артыграк эшләп чыгара башладылар. Завод бу айның калган 10 эш көнендә ничә станок эшләп чыгарды?

Счётта исәпләү өчен мисаллар.

978.	462 + 537	724 + 256	146 + 538
	264 + 325	316 + 590	524 + 585
	4 372 + 2 626	4 572 + 3 218	3 247 + 4 539
	5 014 + 3 683	1 634 + 5 275	2 198 + 3 240
979.	724 − 513	630 − 218	572 − 438
	948 − 327	904 − 463	864 − 592
	4 289 − 1 174	2 470 − 1 356	4 738 − 3 529
	5 496 − 4 085	3 708 − 2 584	9 647 − 2 085
980.	476 + 389	600 − 328	345 − 186
	529 + 295	501 − 476	624 − 478
	4 375 + 2 486	2 300 − 1 124	2 472 − 1 398
	5 289 + 3 596	4 804 − 2 486	7 648 − 2 459

Язып чишү өчен.

981 дән 994 кә кадәр булган мисал һәм мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә эшләгез.

981. 365 028 + 406 785 — 196 459   175 601 — 89 076 + 56 475
700 000 — 169 708 + 58 736   901 010 — 72 406 + 24 786
300 100 — 40 265 + 75 608   804 100 — 635 096 + 135 678

982. 357 × 48 : 24   756 × 57 : 76   2 576 × 68 : 46
246 × 64 : 48   846 × 87 : 58   4 392 × 70 : 36
627 × 65 : 39   954 × 45 : 54   2 240 : 35 × 95

983. 372 × 65 : 39   48 735 : 45 × 87 — 4 975
248 × 84 : 56   63 864 : 36 × 76 — 8 096
620 × 78 : 52   75 402 : 18 × 68 — 9 878

984. Лётчик беренче көнне 6 сәгать, икенче көнне 9 сәгать очты. Беренче көнне, икенче көнгә караганда, ул 1 275 *км* кимрәк очты. Әгәр очу тизлеген үзгәртмәсә, лётчик бу ике көннең һәрберсендә ничәшәр километр очкан булыр?

985. Бер интернат-мәктәп 330 сумга 55 урындык, икенчесе шундый ук 75 урындык сатып алды. Икенче мәктәп, беренчегә караганда, урындыклар өчен күпме акча артыграк түләгән? (Мәсьәләне ике юл белән чишегез.)

986. Бер төрле ике кисәк материя сатып алдылар. Барлык материя 72 *м.* Бер кисәк өчен 960 сум, икенче кисәк өчен 480 сум түләделәр. Һәр кисәктә ничәшәр метр материя булган?

987. Поезд бердәй тизлек белән беренче көнне 900 *км*, икенче көнне 765 *км* юл үтте. Беренче көнне поезд, икенче көнгә караганда, 3 сәгать артыграк барды. Поезд һәр ике көнне ничәшәр сәгать юлда булган?

988. Ике пристаньнан бер үк вакытта бер-беренә каршы ике пароход юлга чыкты. Беренче пароход сәгатькә 27 *км* тизлек белән, икенчесе 21 *км* тизлек белән барды. Әгәр пристаньнар арасындагы ераклык 576 *км* булса, пароходлар ничә сәгатьтән соң очрашканнар?

989. Бер мәктәп 28 өстәл һәм 12 шкаф өчен 636 сум түләде. Икенче мәктәп шундый ук 15 шкаф өчен 375 сум түләде. Бер өстәл күпме тора?

990. Ике китап шкафында 1 536 китап бар иде. Беренче шкафтан 156 китап, икенчесеннән 3 тапкыр артыграк китап

алгач, аларда китаплар саны тигезләнде. Һәр шкафта ничәшәр китап калган?

991. Бер завод 27 ящик, икенчесе шундый ук 18 ящик кадак алды. Барлык кадакның авырлыгы 1 080 *кг.* Беренче завод, һәр айда бертигез тотып, кадакларны ике айда тотып бетерде. Беренче завод бер айда ничә килограмм кадак тотты?

992. Мастерской беренче 16 көндә китапханәдәге 1 376 китапны төпләде, аннан соң көнгә 24 әр китап артыграк төпли башлады һәм калган китапларны 10 көндә төпләп бетерде. Мастерской барлыгы ничә китап төпләгән?

993. 1) Поезд 32 сәгатьтә 1 620 *км* юл үтәргә тиеш иде. Ул шуның 540 *км* ын сәгатькә 45 *км* тизлек белән үтте. Билгеләнгән вакытка барып җитү өчен, калган юлны ул нинди тизлек белән үтәргә тиеш?

2) Мәсьәлә шартындагы 1 620 санын 1 720 саны белән алмаштырып, яңадан чишегез.

994. Диңгез буендагы, аралары 900 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике корабль юлга чыкты. 18 сәгать үткәч, алар очраштылар. Беренче корабль сәгатькә 26 *км* тизлек белән барды, икенче корабльнең тизлеге нинди булган?

Гади вакланмалар.

Вакланмаларның ясалуы.

995. Беренче алма ничә тигез кисәккә бүленгән? Алманың яртысын күрсәтегез. Бөтен алмада ничә ярты бар?



996. Икенче алма ничә тигез кисәккә бүленгән? Алманың чирегең күрсәтегез; ике чиреген; өч чиреген; дүрт чиреген күрсәтегез. Бөтен алмада ничә чирек бар?

997. Беренче түгәрәк ничә тигез кисәккә бүленгән? Икенче түгәрәк? Өченче түгәрәк?



Түгәрәкнең яртысын күрсәтегез; ике чиреген; өч чиреген; дүрт чиреген. Бөтен түгәрәктә ничә чирек бар? Ярты түгәрәктә ничә чирек бар?

Бөтен түгәрәктә ничә сигезенче өлеш бар? Ярты түгәрәктә ничә сигезенче өлеш? Чирек түгәрәктә ничә сигезенче өлеш?

998. 12 *см* озынлыкта туры сызык сызыгыз. Аны ике тигез кисәккә бүлегез һәм икенче кисәген күрсәтегез. Кисемтәне дүрт тигез кисәккә бүлегез (һәр яртыны урталай бүлү юлы белән) һәм бер чиреген күрсәтегез, ике чиреген, өч чиреген, дүрт чиреген күрсәтегез.

Кисемтәне сигез тигез өлешкә булегез (һәр чирекне урталай булу юлы белән) һәм сигездән берен, сигездән икесен, сигездән сигезен курсәтегез.

999. Бер берәмлектә ничә ярты бар? Ничә чирек? Ничә сигезенче өлеш?

1000. Һәр көн тигез укып, бер укучы китапны 4 көндә укып чыккан. Ул 1 көндә китапның нинди өлешен укыган? 2 көндә? 3 көндә?

1001. Самолёт, бер үк тизлек белән очып,ниндидер бер араны 8 сәгатьтә уткән. Самолёт 1 сәгатьтә юлның нинди өлешен уткән? 3 сәгатьтә? 5 сәгатьтә? 7 сәгатьтә?

1002. Ашханә, көн саен бертигез тота барып, бәрәңгене 8 көндә бетергән. 1 көндә ул бәрәңгенең нинди өлешен тоткан? 5 көндә? 3 көндә? 7 көндә?

1003. Туры сызык дүрт тигез кисәккә буленгән. Ике кисәк сызыкның нинди өлешен төзи? Өч кисәк?



1004. Туры сызык кисемтәсе сигез тигез кисәккә буленгән. Биш кисәк барлык кисемтәнең нинди өлешен төзи? Җиде кисәк нинди өлешен төзи?



Вакланма менә болай языла: башта вакланмада ничә өлеш бар икәнен курсәткән санны язалар; аның астына сызык сызалар; сызык астына берәмлекнең ничә тигез кисәккә буленгәнен курсәткән санны язалар. Мәсәлән: сигездән өч $\frac{3}{8}$ рәвешендә языла.

1005. Вакланмаларны укыгыз:

$$\frac{1}{2};\ \frac{1}{4};\ \frac{1}{8};\ \frac{3}{4};\ \frac{5}{8};\ \frac{7}{8};\ \frac{3}{8}.$$

Һәр вакланма ничек килеп чыккан?

1006. Түбәндәге вакланмаларны языгыз: икедән бер; өч чирек; сигездән биш; дүрттән бер; сигездән өч; дүрттән ике; ике чирек; сигездән бер; сигездән җиде.

Бу вакланмаларның һәрберсе ничек ясалды?

1007. Туры сызык кисемтәсе ничә тигез кисәккә бүленгән? Кисемтәнең уннан бер кисәген; уннан ике кисәген; уннан өч һәм уннан ун кисәген күрсәтегез. Бөтен кисемтәдә ничә унынчы өлеш бар?

1008. 1) 1 *см* дециметрның ничәнче өлешен төзи? 2 *см*? 4 *см*? 8 *см*? 6 *см*? 9 *см*?

2) 1 *дм* метрның ничәнче өлешен төзи? 3 *дм*? 5 *дм*? 9 *дм*?

3) 1 *мм* сантиметрның ничәнче өлешен төзи? 3 *мм*? 8 *мм*? 6 *мм*?

1009. 1) Вакланмаларны укып чыгыгыз:

$$\frac{1}{10};\ \frac{3}{10};\ \frac{9}{10};\ \frac{7}{10};\ \frac{5}{8};\ \frac{3}{4}.$$

2) Вакланмаларны цифрлар белән языгыз: уннан ике; уннан җиде; сигездән өч; уннан дүрт; уннан өч.

1010. Берәмлектә сигезенче өлешләр ничә? Унынчы өлешләр ничә?

1011. Бер укучы, һәр сәгатьтә тигез эшләп, түтәлне 4 сәгатьтә казып бетергән. Ул 1 сәгатьтә түтәлнең нинди өлешен казыган? 2 сәгатьтә? 3 сәгатьтә нинди өлешен казыган?

1012. Бер укучы кыз, һәр сәгатьтә эшнең бертигез өлешен үтәп, тегүгә 10 сәгать вакыт үткәрде. Ул 1 сәгатьтә эшенең нинди өлешен үтәгән? 3 сәгатьтә? 5 сәгатьтә?

1013. Бу вакланмаларны укыгыз:

$$\frac{1}{2};\ \frac{3}{10};\ \frac{1}{8};\ \frac{5}{8};\ \frac{3}{4};\ \frac{7}{8};\ \frac{9}{10}.$$

1014. Түбәндәге вакланмаларны языгыз: сигездән бер; уннан бер; өч чирек; уннан өч; сигездән биш; уннан җиде.

1015. 1) Рәсемдә күрсәтелгәнчә бертигез озынлыкта туры почмаклы биш озынчык сызыгыз.



Беренче озынчык берәмлекне күрсәтә. Икенче озынчык ике тигез кисәккә — ике яртыга бүленгән. Өченчесе дүрт тигез кисәккә — дүрт чиреккә бүленгән. Дүртенчесе сигез тигез кисәккә — сигездән сигезгә бүленгән. Бишенчесе ун тигез кисәккә — уннан унга бүленгән.

2) Шушы сызымга карап, түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

Берәмлектә ничә ярты? Берәмлектә ничә чирек? Берәмлектә сигезенче өлешләр ничә? Яртыда сигезенче өлешләр ничә? Берәмлектә унынчы өлешләр ничә? Яртыда унынчы өлешләр ничә?

Санның бер яки берничә өлешен табуга мәсьәләләр.

1016. Партага 16 кубик куегыз. Бу кубикларның $\frac{1}{4}$ ен ничек табарга? Бу ничә кубик булыр?

1017. 12 шакмак озынлыгындагы бер озынчык 4 тигез кисәккә бүленгән һәм аның $\frac{1}{4}$ кисәге штрихланган. Ничә шакмак штрихланган?



1018. 16 шакмактан торган бер озынчык сызыгыз; аның $\frac{1}{4}$ өлешен кызыл төскә, аннан соңгы $\frac{1}{4}$ ен зәңгәр төскә һәм

тагын $\frac{1}{4}$ ен сары төскә буягыз. Бөтен озынчыкның нинди өлеше буялган? Ничә шакмак буялган?

1019. Партага 20 кубик куегыз. 20 кубикның $\frac{3}{4}$ ен алыгыз. Бу ничә кубик булыр?

1020. 8 *см* озынлыгында туры сызык кисемтәсе сызыгыз. Башта кисемтәнең $\frac{1}{4}$ ен, аннан соң кисемтәнең $\frac{3}{4}$ ен табыгыз.

1021. $\frac{1}{2}$ *м* да; $\frac{1}{4}$ *м* да; $\frac{1}{10}$ *м* да; $\frac{3}{10}$ *м* да; $\frac{7}{10}$ *м* да ничәшәр сантиметр? Моны метр өстендә күрсәтегез.

1022. Һәрберсе 40 ар *см* озынлыгында өч кәгазь тасма хәзерләгез. Беренче тасмада озынлыкның $\frac{3}{4}$ ен, икенчесендә $\frac{5}{8}$ ен; өченчесендә $\frac{9}{10}$ ын билгеләгез.

1023. Китапта 128 бит. Беренче көнне укучы китапның $\frac{1}{2}$ ен укыган. Беренче көнне укучы ничә бит укыган?

1024. Тартмада 200 каләм бар иде. Укучыларга январьда барлык каләмнең $\frac{1}{10}$ ен, февральдә барлык каләмнең $\frac{3}{10}$ ен бирделәр. Январьда ничә каләм һәм февральдә ничә каләм бирелгән?

1025. 1) $\frac{1}{2}$ *кг* да ничә грамм? $\frac{1}{4}$ *кг* да; $\frac{3}{4}$ *кг* да; $\frac{1}{10}$ *кг* да; $\frac{3}{10}$ *кг* да ничәшәр грамм?

1026. $\frac{1}{2}$ *т* да ничә килограмм? $\frac{1}{4}$ *т* да; $\frac{3}{4}$ *т* да; $\frac{1}{10}$ *т* да; $\frac{7}{10}$ *т* да ничәшәр килограмм?

1027. $\frac{1}{2}$ *км* да ничә метр? $\frac{1}{4}$ *км* да; $\frac{1}{8}$ *км* да; $\frac{3}{8}$ *км* да; $\frac{3}{10}$ *км* да ничәшәр метр?

1028. Пионерлар лагеренда балалар бер көндә 1 *кг* ромашка җыйганнар. Киптергәндә авырлыкның $\frac{7}{10}$ се югала. Кипкәч күпме ромашка чыгар?

1029. Мәктәп укучыларга айга 380 дәфтәр бирде; дәфтәрнең $\frac{3}{10}$ е юллы, $\frac{1}{4}$ е шакмаклы, ә калганнары ике юллы дәфтәрләр. Ике юллы дәфтәрне ничәне биргәннәр?

1030. $\frac{1}{2}$ сумда ничә тиен? $\frac{1}{4}$ сумда; $\frac{3}{4}$ сумда; $\frac{1}{10}$ сумда; $\frac{7}{10}$ сумда ничәшәр тиен?

1031. $\frac{1}{2}$ *т* да ничә центнер? $\frac{1}{10}$ *т* да; $\frac{3}{10}$ *т* да; $\frac{7}{10}$ *т* да ничәшәр центнер?

1032. Заводта 3 600 эшче бар. Барлык эшчеләрнең дүрттән өче ирләр, калганы хатын-кызлар. Заводта ничә хатын-кыз эшли?

1033. 160 санының $\frac{3}{4}$ ен табарга. 6 800 санының $\frac{5}{8}$ ен табарга.

1034. Укучылар бакчага утырту өчен урманнан чыршы һәм каен агачлары алып кайттылар. Чыршы агачлары 40 төп, каен агачлары чыршылар санының $\frac{5}{8}$ е кадәр булган. Укучылар ничә төп каен агачы алып кайтканнар?

1035. Балалар питомниктан юкә һәм тополь агачлары алып кайттылар. Тополь агачлары 60 төп, юкәләр саны топольләр санының $\frac{3}{4}$ е кадәр. Балалар ничә төп юкә агачы алып кайтканнар?

1036. Магазинда 640 *кг* ярма булган: барлык ярманың $\frac{3}{10}$ е дөге, $\frac{1}{8}$ е тары, калганы карабодай ярмасы булган. Сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

1037. Октябрятларның дүрт йолдызчыгы бер айда 120 шәр *кг* иске кәгазь җыеп тапшырырга булдылар. Беренче атнада: беренче йолдызчык тапшырырга тиешле кәгазьнең $\frac{1}{10}$ ен, икенчесе $\frac{1}{4}$ ен, өченчесе $\frac{1}{8}$ ен, дүртенчесе $\frac{1}{2}$ ен җыйды. Беренче җыю нәтиҗәсендә йолдызчыкларның кайсы беренче урынны, кайсы икенче, кайсы өченче урынны, кайсы дүртенче урынны алган?

1038. Нинди булса да бер санның берничә өлешен табуга мәсьәлә төзегез.

1039. Октябрятларның дүрт йолдызчыгы ашлама өчен көл җыюда ярышка чыкты. Беренче йолдызчык кыш буена 240 *кг* көл җыйнады, икенчесе беренче йолдызчык җыйган көлнең $\frac{1}{4}$ ен, өченчесе $\frac{1}{10}$ ен, дүртенчесе $\frac{1}{8}$ ен җыйды. Бу йолдыз-

чыкларның кайсы беренче урынны алган? Кайсы икенче урынны? Өченче урынны? Дүртенче урынны алган?

1040. Түбәндәге саннарның һәрберсенең $\frac{3}{4}$ ен табыгыз:

72; 360; 280; 732.

1041. Түбәндәге саннарның һәрберсенең $\frac{5}{8}$ ен табыгыз:

48; 240; 584; 928.

1042. Түбәндәге саннарның һәрберсенең $\frac{3}{10}$ ен табыгыз:

70; 400; 650; 780.

1043. 768 санынннан аның сигезенче өлешен алыгыз.

1044. 680 саныннан аның $\frac{3}{4}$ ен алыгыз.

1045. 940 саныннан аның $\frac{7}{10}$ сен алыгыз.

1046. 430 санының яртысына 780 санының яртысын кушыгыз.

Вакыт үлчәү берәмлекләре.

Тәүлек, сәгать, минут, секунд.

Бер тәүлектә 24 сәгать.
Бер сәгатьтә 60 минут.
Бер минутта 60 секунд.

1047. 1) Секунд белән кыска вакыт арасы үлчәнә. Бер секундта 1—2 адым атлап була, 1 *м* юл үтеп була. 10 секунд вакыт эчендә 1 дән 10 га кадәр санап була. 60 секунд эчендә кызу итеп 1—60 ка кадәр санап була.

2) 2 минутта ничә секунд? 5 минутта? 10 минутта? Бер сәгатьтә ничә секунд?

Ничә минут бар:

120 секундта? 180 секундта? 360 секундта? 600 секундта?

1048. 1) Сәгать һәм минут стрелкалары булган циферблат ясагыз (хезмәт дәресендә).

2) Сәгать һәм минут стрелкалары белән файдаланып, вакытны тиз һәм дөрес билгеләргә өйрәнегез.

3) Чирек сәгатьтә ничә минут була? Ике чирек яки ярты сәгатьтә; өч чирек сәгатьтә ничә минут була?

1049. Сәгать 5 сәг. 15 мин. ны күрсәтә. Кыскача моны ничек әйтеп була? (Алтынчы чирек.) Сәгать 5 сәгать 30 мин. ны күрсәтә. Кыскача ничек әйтеп була? Сәгать 7 сәгать 45 мин. ны күрсәтә. Кыскача ничек әйтергә мөмкин? Сәгать 11 сәгать 55 минутны күрсәтә. Моны башкача ничек әйтеп була?

1050. 1) Хәзер унынчы ярты. Бу ничә сәгать һәм минут була?

2) Хәзер 11 туларга 10 минут. Бу ничә сәгать һәм минут була?

1051. 1) Сез үзегезнең көн буе кайчан һәм нәрсә эшләвегез турында дәфтәрегезгә языгыз:

Сәгать ... дә йокыдан торам.

Сәгать ... дә мәктәпкә китәм.

Сәгать ... дә мәктәптән кайтам.

Сәгать ... дән сәгать ... кә кадәр саф һавада йөрим, уйныйм.

Сәгать ... дән сәгать ... кә кадәр дәрес хәзерлим.

Сәгать ... дән сәгать ... кә кадәр әниемә йорт эшләрендә булышам.

Сәгать ... дән сәгать ... кә кадәр китаплар укыйм.

2) Сезнең күпме вакытыгыз китә: а) дәрес хәзерләү һәм китаплар укуга? б) һавада йөрү һәм уйнауга? в) әниегезгә булышуга?

1052. Укучылар экскурсиядә 1 сәгать 10 минут булдылар. Укучылар экскурсиядә ничә минут булдылар?

1053. Ирек 400 *м* араны 1 минут 32 секундта йөгереп үткән. Ирек 400 *м* араны ничә секундта үткән?

1054 нче һәм 1055 нче мәсьәләләрне циферблат белән файдаланып, мөстәкыйль рәвештә чишегез.

1054. Беренче дәрес 8 сәгать 30 минутта башланды. Дәрес 45 минут дәвам итте. Аннан 10 минут ял булды. Икенче дәрес кайчан башланды?

1055. Икенче дәрес 9 сәгать 25 минутта башланды һәм 45 минут дәвам итте. Әгәр дәрес арасында 20 минут ял булса, өченче дәрес кайчан башланыр?

1056. Үз классыгызда дәресләрнең башлануы һәм тәмам булуы турында мәсьәләләр төзегез һәм чишегез.

1057. Пионерлар көндезге сәгать 2 дә урманга киткәннәр, кичке сәгать 6 да өйләренә кайтканнар. Урманга барып кайту ничә сәгать дәвам иткән?

1058. Магазин иртәнге сәгать 9 дан көндезге сәгать 1 гә кадәр һәм көндезге сәгать 2 дән кичке сәгать 6 га кадәр ачык була. Магазин барлыгы ничә сәгать ачык була?

1059. Юннатлар мәктәп бакчасында көндезге сәгать 1 дә эшли башладылар һәм анда 3 сәгать 15 минут эшләделәр. Алар эшне сәгать ничәдә бетергәннәр?

1060. Тракторчы басуны иртәнге сәгать 7 дә сөрә башлаган һәм 8 сәгатьтән соң сөреп бетергән. Тракторчы эшне сәгать ничәдә бетергән?

1061. Мәктәптә балалар иртәсе 1 сәгать 15 минут дәвам иткән һәм көндезге сәгать 12 дә тәмам булган. Балалар иртәсе сәгать ничәдә башланган?

1062. Урман көнендә укучылар агач утырту белән 2 сәгать 30 минут шөгыльләнделәр һәм эшне көндезге сәгать 4 тә тәмамладылар. Алар сәгать ничәдә эшли башлаганнар?

1063. Бер кыз кичке сәгать 9 да йокларга яткан һәм икенче көнне иртәнге сәгать 7 дә йокыдан торган. Бу кыз ничә сәгать йоклаган?

1064. Поезд Мәскәүдән кичке сәгать 11 дә чыкты һәм икенче көнне иртәнге сәгать 9 да Ленинградка килеп житте. Поезд юлда ничә сәгать булды?

1065. Сәяхәтчеләр пароход белән көндезге сәгать 12 дә Горький шәһәреннән чыгып киткәннәр һәм икенче көнне көндезге сәгать 4 тә Ульяновск шәһәренә килеп житкәннәр. Сәяхәтчеләр Горькийдан Ульяновскига кадәр пароходта ничә сәгать барганнар?

1066. Кояш иртәнге сәгать 6 да чыга һәм кичке сәгать 7 дә бата. Көн озынлыгы күпме?

1067. Кояш иртәнге 5 тә чыга. Әгәр көн озынлыгы 15 сәгать булса, кояш сәгать ничәдә батар?

1068. Үзегез торган жирдәге вакытка карап, табигать календарегыздан файдаланып, кояшның чыгуы һәм батуы турында мәсьәлә төзегез һәм чишегез.

Гасыр, ел, ай.

Гасыр 100 елга тигез.
Ел 12 айга тигез.
Ай 30 яки 31 көнгә (февральдә 28 яки 29 көн) тигез.

Январьда 31 көн.	Июльдә 31 көн.
Февральдә 28 яки 29 көн.	Августта 31 көн.
Мартта 31 көн.	Сентябрьдә 30 көн.
Апрельдә 30 көн.	Октябрьда 31 көн.
Майда 31 көн.	Ноябрьда 30 көн.
Июньдә 30 көн.	Декабрьда 31 көн.

1069. Бер елдагы ай исемнәрен тәртип буенча әйтегез һәм һәр айда ничәшәр көн икәнен белегез.

1070. Бер елда ничә ай 30 көннән килә? Шул айларны әйтегез.

1071. Бер елда ничә ай 31 көннән килә? Шул айларны әйтегез.

1072. Март, апрель, май яз айлары дип исәпләнә, яз айларында ничә көн?

1073. Әгәр декабрь, январь, февраль айлары кышкы айлар дип исәпләнсә, кыш ничә көн дәвам итә?

1074. 8 гасырда ничә ел бар? 12 гасырда? 15 гасырда? 19 гасырда?

1075. Түбәндәге сүзләрне күчереп языгыз һәм төшереп калдырылган саннарны куегыз.

1) Мин ... елда тудым.

2) Миңа ... яшь.

3) Без ... гасырда яшибез.

4) Хәзер ... ел бара.

5) ... елдан соң 21 нче гасыр башлана.

6) 20 нче гасырда безнең илебездә Бөек Октябрь социалистик революциясе булды. Ул ... елда булды.

7) Безнең илебездән 1957 елда бөтен дөньяда беренче булып Җирнең ясалма иярчене җибәрелде.

8) 1959 елда безнең илебез Айга беренче ракета җибәрде.

1076. Эрерәк үлчәү берәмлекләрен ваграк үлчәү берәмлекләренә әйләндерегез:

1 тәү. = 24 сәг.	2 сәг. = 120 мин.	3 мин. = 180 сек.
2 тәү. =	3 сәг. =	4 мин. =
4 тәү. =	5 сәг. =	6 мин. =
7 тәү. =	8 сәг. =	8 мин. =
10 тәү. =	10 сәг. =	10 мин. =

1077. Вак үлчәү берәмлекләрен эрерәк үлчәү берәмлекләренә әйләндерегез:

48 сәг. = 2 тәү.	60 мин. = 1 сәг.	120 секунд = 2 мин.
72 сәг. =	120 мин. =	180 секунд =
96 сәг. =	240 мин. =	300 секунд =
144 сәг. =	360 мин. =	480 секунд =
240 сәг. =	540 мин. =	600 секунд =

1078. Мәктәптә 210 укучы. Балалар, дәрестә һәрбер укучы 1 минут вакытны бушка уздырса, мәктәптәге барлык укучыларның 4 дәрестә 14 сәгать вакытны югалтулары мөмкин икәнен исәпләп чыгарганнар. Балалар дөрес исәпләгәннәрме?

Әгәр сезнең класста вакыт югалту очраклары булса, сез дә бушка киткән вакытны исәпләп чыгарыгыз.

1079. Аяк киемнәре фабрикасы 7 сәгатьтә 7 140 пар аяк киеме эшләп чыгара. Фабрика бер минутта ничә пар аяк киеме әзерләп чыгара?

1080. Фабрика 7 сәгатьтә 273 420 дәфтәр хәзерли. Фабрика бер минутта ничә дәфтәр хәзерли?

1081.

$(28\,396 + 844\,364) : 42$	$270 \times 90 : 54$
$(801\,070 - 756\,106) : 36$	$675 \times 86 : 45$
$(911\,020 - 136\,840) : 17$	$5\,925 \times 75 : 25$
$(900\,000 - 860\,220) : 39$	$6\,944 \times 70 : 28$

Геометрик материал.

Туры сызык һәм кисемтә.

1082. Шушы сызыкларның кайсылары туры сызыклар?

1083. Әйләнә-тирәгездәге предметларда туры сызыкларны күрсәтегез.



1084. Җепне туры сызык рәвешендә тартып тотарга.

1085. Бөкләнгән урыны туры сызык рәвешендә булырлык итеп, бер табак кәгазьне бөкләргә.

1086. Линейка ярдәмендә бер туры сызык сызыгыз.

1087. Туры сызыкның А һәм Б нокталары арасындагы өлешен алыйк. Без АБ кисемтәсен табарбыз.

1088. КЛ кисемтәсенең озынлыгын һәм ДЕ кисемтәсенең озынлыгын үлчәгез.

1089. Тактада 32 *см* озынлыгында туры сызык кисемтәсе сызыгыз.

> Балта осталары, пычкычылар һәм столярлар туры сызыкны үткәрү өчен, акбур сөртелгән шнурдан файдаланалар. Шнурны киереп тарталар һәм аннан соң тиз генә ычкындырып җибәрәләр. Тактада яки бүрәнәдә туры сызык рәвешендә эз кала.

1



1090. Шнур ярдәмендә тактага яки өстәл өстенә туры сызык үткәрегез.

1091. Дәфтәргә берсе 8 *см*, икенчесе 6 *см* 5 *мм* озынлыгында ике туры сызык кисемтәсе сызыгыз.

1092. Берсе 9 *см*, икенчесе 5 *см* 2 *мм*, өченчесе 7 *см* 9 *мм* озынлыгында булган өч туры сызык кисемтәсе сызыгыз.

1093. Кисемтәләрнең озынлыгын башта күз белән чамалап, аннан соң үлчәп билгеләгез:



Өч кисемтәнең суммасы ничәгә тигез?

Беренче ике кисемтәнең аермасы ничәгә тигез?

Өченче һәм беренче кисемтәләр арасындагы аерма ничәгә тигез?

Җир өстендә туры сызыклар рулетка, яки үлчәү тасмасы, яки кыр циркуле белән үлчәнә.



Үлчәү тасмасы урынына 10 метр озынлыктагы үлчәү бавы алырга мөмкин. Тартырга һәм казыкка эләргә уңайлы булсын өчен, үлчәү бавының башларына әлмәкләр ясарга кирәк. Озынлыкны билгеләү өчен һәр метр саен: 1 *м*, 2 *м*, 3 *м* һ. б. язылган кечкенә такта кисәкләре беркетелә.

Җир өстендә туры сызыкларны маяклар ярдәмендә үткәрәләр. Маякларны икесе өченчесен каплап торырлык итеп утырталар.



1094. Җир өстендә туры сызык үткәрегез һәм аны үлчәгез.

1095. Җир өстендә 25 *м* озынлыкта туры сызык үткәрегез.

1096. Җир өстендә ике әйбер арасындагы ераклыкны баш та күз белән чамалап билгеләгез, аннан соң бу араны үлчәгез.

1097. 1) Күз белән 10 *м* ераклыкны чамалагыз һәм аныказыклар белән билгеләгез; аннан соң бу араны рулетка белән үлчәгез.

2) 20 *м* ераклыкны күз белән чамалап, казыклар белән билгеләгез, аннан соң рулетка белән үлчәп, дөреслеген тикшерегез.

3) 30 *м* ара өчен дә шулай ук эшләгез.

Почмаклар.

Туры почмаклар.

1098. Әйләнә-тирәдәге әйберләрдә туры почмакларны күрсәтегез.



Туры почмактан зуррак почмак — **җәенке почмак.**
Туры почмактан кечерәк почмак — **кысынкы почмак.**



1099. Түбәндәге рәсемдә туры, кысынкы, җәенке почмакларны күрсәтегез.



Туры почмакларны сызу һәм аларның дөреслеген тикшерү өчен почмаклык (угольник) кулланыла.

1100. Башта шакмаклы кәгазьгә, аннан соң почмаклык һәм линейка ярдәмендә сызыксыз кәгазьгә туры почмак сызыгыз.

1101. Туры почмактан зур һәм туры почмактан кечкенә булган почмаклар сызыгыз.

Турыпочмаклык.



1102. Турыпочмаклыкның ничә ягы бар? Турыпочмаклыкның капма-каршы якларын күрсәтегез.

1103. 1) Турыпочмаклыкның һәр ягын үлчәгез.

2) Турыпочмаклыкның кайсы яклары үзара тигезләр?

1104. Турыпочмаклыкның ничә почмагы бар? Турыпочмаклыкның почмаклары нинди?

Турыпочмаклыкның капма-каршы яклары үзара тигезләр. Турыпочмаклыкның барлык почмаклары турылар.

1105. Әйләнә-тирәдәге әйберләрдә турыпочмаклыкларны күрсәтегез.

1106. Түбәндәге фигураларны карагыз һәм сорау билгеләре куелган яктагы кисемтәләрнең озынлыгын билгеләгез. (Рәсемнәр кечерәйтелеп бирелгән.)







1107. Тактада буе 35 *см*, иңе 20 *см* булган турыпочмаклык сызыгыз.

1108. 1) дәфтәрдә буе 7 *см*, иңе 5 *см* булган турыпочмаклык сызыгыз.

2) Дәфтәрдә буе 6 *см*, иңе 2 *см* га кимрәк булган турыпочмаклык сызыгыз.

1109. Буе 3 *см*, иңе 2 *см* булган турыпочмаклык бирелгән. Турыпочмаклыкның барлык якларының суммасы ничәгә тигез?



Чишү. Әгәр турыпочмаклыкның буе 3 *см*, иңе 2 *см* булса, ул вакыт турыпочмаклыкның барлык якларының суммасы:

$$3\ см + 2\ см + 3\ см + 2\ см = 10\ см \text{ га тигез,}$$

яки

$$(3\ см \times 2) + (2\ см \times 2) = 6\ см + 4\ см = 10\ см.$$

1110. Дәфтәрдә буе 5 *см*, иңе 3 *см* булган турыпочмаклык сызыгыз. Аның барлык якларының суммасын табыгыз.

1111. Турыпочмаклык формасындагы стена газетасының буе 75 *см*, иңе 40 *см*. Стена газетасын каймалау өчен төсле кәгазь тасма нинди озынлыкта кирәк булыр?

1112. Үзегезнең стена газетагызны каймалау өчен нинди озынлыкта кәгазь тасма кирәк булуы турында мәсьәлә төзегез.

1113. Класс тактасының буе ... *дм*, иңе ... *дм*. Тактаның 4 ягы өчен ничә метр агач планка кирәк булыр?

Кирәкле саннарны куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

Квадрат.

1114. Квадратның ничә ягы бар? Квадратның һәр ягын үлчәгез.



Квадратның барлык яклары тигез. Квадратның барлык почмаклары туры.

1115. Квадратның ничә почмагы бар? Квадратның почмаклары нинди?

1116. Әйләнә-тирәдәге предметларда квадратларны күрсәтергә.

1117. Тактада ягы 40 *см* булган квадрат сызыгыз.

1118. Дәфтәрдә ягы 7 *см* булган квадрат сызыгыз.

1119. Квадратның бер ягы 3 *см* га тигез. Квадратның барлык якларының суммасын белегез.



Чишү. Квадратның барлык якларының суммасы:

$$3\ см + 3\ см + 3\ см + 3\ см = 3\ см \times 4 = 12\ см.$$

Әгәр квадратның дүрт ягының суммасы 12 *см* га тигез булса, ул вакыт аның бер ягы:

$$12\ см : 4 = 3\ см.$$

1120. Кулъяулык кырыена челтәр тотарга кирәк. Әгәр яулыкның һәр ягы 20 *см* булса, бер яулык өчен ничә сантиметр челтәр кирәк булыр?

1121. Квадратның ягы 24 *см* га тигез. Аның дүрт ягының суммасын исәпләп чыгарырга.

1122. Квадратның дүрт ягының суммасы 28 *см* га тигез. Аның бер ягы ничә сантиметрга тигез?

1123. Квадратның бер ягы 16 *см*. Аның барлык яклары суммасын исәпләп чыгарырга.

1124. Квадрат формасындагы ашъяулыкның әйләнәсенә чачак тотарга кирәк. Әгәр ашъяулыкның бер ягы 125 *см* га тигез булса, бу ашъяулык өчен ничә метр чачак кирәк булыр?

1125. Квадратның барлык яклары суммасы 36 *см*. Аның бер ягы күпмегә тигез булуын исәпләргә һәм дәфтәргә шундый квадрат сызарга.

1126. Дәфтәрегезгә квадратлардан торган шундый рәсемнәр (орнаментлар) ясарга.



1127. Квадрат һәм турыпочмаклыклардан торган шундый орнамент ясарга.



1128. Квадрат һәм турыпочмаклык нәрсә белән бер-беренә охшыйлар? Квадрат һәм турыпочмаклык бер-берсеннән нәрсә белән аерылалар?

Жир өстендә үлчәү.

1129. Мәктәп ишек алдының буен һәм иңен үлчәгез.

1130. Мәктәп ишек алдын әйләндереп алган коймасын озынлыгын исәпләп чыгарыгыз.

1131. Җир өстендә берәр участокның буен һәм иңен башта күз белән чамалап билгеләгез һәм соңыннан аның якларын үлчәгез.

1132. Үзегезнең яшелчә бакчасында һәр культура өчен бүлеп бирелгән участокның озынлыгын һәм киңлеген үлчәгез. Дәфтәрдә шундый таблица төзеп, саннарны шунда языгыз.

Культураның исеме	Участокның озынлыгы	Участокның киңлеге
Бәрәңге		
Кәбестә		
Кыяр		
Кишер		
Чөгендер		

1133. Балалар мәктәптән тегү фабрикасына экскурсиягә бардылар. Һәм алар бу ераклыкны күрсәтү өчен, 100 *м* урынына кечерәйтелгән үлчәүдә туры сызык кисемтәсе алып, сызым сыздылар. Тегү фабрикасы мәктәптән нинди ераклыкта булган?

1134. Косино һәм Васютино авыллары арасындагы ераклык сызымда кечерәйтелеп бирелгән. Бу ераклыкны исәпләргә.



Мәсьәләләр.

1135. Яшелчә бакчасында бәрәңге, кәбестә, кыяр, кишер һәм чөгендер үсә. Бу яшелчәләрнең һәрберсенә бүлеп бирелгән участокның буен һәм иңен сызымнан карап белергә.



1136. Турыпочмаклык формасындагы бакчаның буе 30 *м*, иңе 18 *м*. Бакчаны әйләндереп алган койма нинди озынлыкта?

1137. Турыпочмаклык формасындагы яшелчә бакчасының иңе 25 *м*, буе, иңенә караганда, 15 *м* га артыграк. Бакча тирәли тотылган койманың озынлыгы күпме?

1138. Бер малай үрентеләр утырту өчен, рәсемдә кечерәйтелеп бирелгән ящик кебек, ящик ясарга уйлый. Шундый ящик хәзерләү өчен ничә метр такта кирәк булыр?



1139. Квадратның бер ягы 60 *мм*. Аның барлык якларының суммасын исәпләргә.

1140. Турыпочмаклыкның озынлыгы 90 *мм*, киңлеге 30 *мм* га кимрәк. Аның барлык якларының суммасын исәпләргә.

1141. Бер кыз рәсемнәр куяр өчен фанердан рам кисеп алган. Рәсемдә күрсәтелгән үлчәмнәре буенча сез дә катыргыдан шундый рам кисеп алыгыз.



1142. Тәҗрибә басуында бодай, арыш һәм солы чәчелгән. План буенча бу культураларга бүлеп бирелгән участокларның буен һәм иңен белегез.



1143. Укучылар ягын 7 *м* итеп квадрат формасында клумба ясаганнар. Клумбаның кырыеннан 1 *м* киңлектәге полосасына үлән чәчкәннәр, калган өлешенә чәчәкләр утырткан-нар. Клумбаның чәчәкләр утыртылган өлешенең ягы ничә метрга тигез?



1144. Квадрат формасындагы бакчаны койма белән әйләндереп алырга кирәк. Бакчаның 24 *м* озынлыктагы

бер ягында койма бар инде. Тагын ничә метр койма ясыйсы калган?

1145. А, Б һәм В шәһәрләре туры сызык буенча төзелгәннәр. А дан Б га 30 *км*, ә А дан В га һәм кирегә В дан А га кадәр 160 *км*. Б дан В га кадәр булган араны табарга.



1146. Турыпочмаклык һәм квадраттан торган участок һәр яктан киртәләп алынган. Планда күрсәтелгән саннардан файдаланып, турыпочмаклыкның буен һәм иңен исәпләгез.



1147. Буе 38 *м*, иңе 19 *м* булган турыпочмаклык рәвешендәге участокта бер өй салганнар һәм ике бертигез җир участогын бакча өчен аерып калдырганнар. Бакчалар берберсеннән һәм өйдән 3 *м* киңлегендәге юл белән аерылалар. Планда күрсәтелгән саннар буенча, бакча өчен калдырылган һәрбер участокның буен, иңен исәпләргә.



1148. Уен мәйданы 45 *м* озынлыкта, 30 *м* киңлектә булган турыпочмаклык формасында иде. Мәйданны 10 *м* га озынайттылар. Мәйданның барлык якларының озынлыгы күпме булды?

1149. Турыпочмаклык формасындагы катокның буе 52 *м*, иңе 35 *м* иде. Катокны икеләтә озынайттылар һәм 15 *м* га

киңәйттеләр. Шуннан соң катокның барлык якларының озынлыгы күпме булды?

1150. Турыпочмаклык формасындагы бакчаның буе 42 *м* һәм иңе 28 *м.* Бакчаның дүрт ягыннан да 2 шәр *м* киңлегендә юл үтә; калган җиргә үсемлекләр утыртылган. Үсемлекләр алып торган җирнең буен һәм иңен белергә.

1151. Квадратның бер ягы 32 *мм.* Квадратның барлык яклары суммасын табарга.

1152. Турыпочмаклыкның буе 26 *мм,* иңе 8 *мм* га кимрәк. Турыпочмаклыкның барлык яклары суммасын исәпләргә.

1153. Турыпочмаклык формасындагы участокның буе 30 *м,* иңе 24 *м.* Балалар бу участокның уртасына яклары участокның һәр ягыннан 9 *м* ераклыкта торган чәчәклек ясаганнар.



1) Чәчәклекнең буе һәм иңе күпмегә тигез?

2) Участокның дүрт ягының суммасы күпмегә тигез?

3) Чәчәклекнең дүрт ягының суммасы күпмегә тигез?

1154. x ны табарга:

$3\,750 + x = 9\,010$ $\qquad$ $x - 4\,075 = 98\,685$

$x \times 37 = 18\,574$ $\qquad$ $x : 408 = 372$

1155. $476 \times 56 : 68$ $\qquad$ $78 \times (63\,635 : 89)$

$531 \times 61 : 59$ $\qquad$ $(45\,593 + 33\,885) : 49$

1156. $(300\,102 - 299\,392) \times 88$ $\qquad$ $1\,906 \times (7\,448 : 98)$

$(640\,018 - 639\,608) \times 67$ $\qquad$ $143\,820 : 47 \times (7\,098 : 78)$

$(16\,788 + 16\,179) : 37$ $\qquad$ $58\,116 : 58 \times (2\,822 : 83)$

Кабатлау.

Телдән исәпләү өчен мисал һәм мәсьәләләр.

1157.

$15 \times 4 : 5 \times 7 + 16$	$80 \times 7 : 4 + 60$
$91 : 7 \times 6 : 2 + 54$	$60 \times 8 : 3 + 80$
$84 : 14 \times 15 - 47 + 29$	$420 : 7 \times 9 - 130$
$76 : 19 \times 23 : 46 \times 0$	$400 : 8 \times 9 + 150$

1158. 60 ны 2 тапкыр зурайтырга, килеп чыккан санны 3 тапкыр кечерәйтергә, яңа килеп чыккан санны 3 кә кечерәйтергә.

1159. 600 не 4 тапкыр кечерәйтергә, килеп чыккан санны 2 тапкыр зурайтырга, яңа килеп чыккан санны 4 кә кечерәйтергә.

1160. Түбәндәге саннарның һәркайсына 20 не кушарга һәм килеп чыккан сумманы 2 тапкыр зурайтырга.

40 90 70 110 160 150

1161. Берсе икенчесеннән 4 тапкыр зуррак булган ике сан әйтегез.

1162. Түбәндәге мисалларны түгәрәкләү юлы белән чишегез:

$47 + 19$	$34 + 99$	$199 + 56$	$299 + 134$
$63 + 29$	$86 + 98$	$398 + 72$	$498 + 250$
$59 + 35$	$99 + 27$	$43 + 699$	$177 + 399$
$19 + 79$	$98 + 75$	$85 + 798$	$462 + 198$

1163. Түгәрәкләү юлы белән чишәргә уңайлы итеп, кушу гамәленә мисаллар төзегез.

1164. Мисалларны түгәрәкләү юлы белән чишегез:

$41 - 19$	$134 - 99$	$352 - 299$	$432 - 199$
$63 - 39$	$252 - 98$	$624 - 598$	$664 - 398$
$72 - 59$	$445 - 99$	$847 - 799$	$577 - 299$
$94 - 48$	$676 - 98$	$588 - 498$	$846 - 699$

1165. Түгәрәкләү юлы белән чишәргә уңайлы итеп, алу гамәленә мисаллар төзегез.

1166. Кушылучыларның урыннарын алыштыру юлы белән түбәндәге мисалларны чишегез:

$36+75+64$ $64+77+23$ $37+78+73+22$
$82+57+18$ $92+68+32$ $8+33+47+94$

1167. Бу таблица буенча күнегүләр эшләгез:

	I	II	III	IV	V	VI	VII	VIII	IX	X
А	60	130	290	400	420	580	700	710	870	940
Б	10	150	220	370	460	540	630	780	850	990
В	40	190	250	330	480	520	670	750	810	960
Г	70	110	260	350	500	600	650	740	890	930
Д	20	170	280	360	490	510	640	720	830	980
Е	50	120	230	310	430	570	690	770	880	950
Ж	100	160	210	390	450	550	610	790	840	1 000
З	30	140	270	320	410	590	680	730	860	970
И	90	180	300	340	470	530	660	800	820	910
К	80	200	240	380	440	560	620	760	900	920

1) Бер баганадагы саннарны икенче баганадагы саннар белән кушыгыз.

2) Алдагы багана саннарыннан үткән багана саннарын алыгыз.

3) Теге яки бу багана саннарын берурынлы санга тапкырлагыз.

4) Теге яки бу багана саннарын берурынлы санга бүлегез.

1168. 1) Тапкырланучы 24, тапкырлаучы 3. Тапкырчыгышны табарга.

2) Бер тапкырлашучы 15, икенче тапкырлашучы 8. Тапкырчыгышны табарга.

1169. Тапкырлашучыларның урыннарын алыштыру юлы белән мисалларны чишегез.

$25 \times 13 \times 4 \qquad 35 \times 7 \times 2 \qquad 9 \times 45 \times 2$

$16 \times 8 \times 5 \qquad 18 \times 9 \times 5 \qquad 4 \times 28 \times 5$

1170. 1) Түбәндәге саннарның һәркайсының өченче өлешен табыгыз.

90 300 540 600 900 720 840

2) Бу саннарның һәркайсының алтынчы өлешен табыгыз.

1171. Бер метрда ничә дециметр? сантиметр? миллиметр? Ничә метр була: 7 *км* 200 *м*? 5 *км* 400 *м*?

1172. 1) Ничә метр була: $\frac{1}{2}$ *км*? $\frac{1}{4}$ *км*? $\frac{3}{4}$ *км*? $\frac{1}{10}$ *км*? $\frac{7}{10}$ *км*?

2) Ничә сантиметр була: $\frac{1}{2}$ *м*? $\frac{1}{4}$ *м*? $\frac{3}{4}$ *м*?

1173. 1) Тоннада ничә центнер? Ничә килограмм?

2) Ничә килограмм була: 10 *т*? 100 *т*?

3) Ничә килограмм була: 10 *ц*? 100 *ц*? 1000 *ц*?

4) Ничә грамм була: $\frac{1}{2}$ *кг*? $\frac{1}{4}$ *кг*? $\frac{1}{10}$ *кг*? $\frac{3}{4}$ *кг*?

5) Ничә килограмм була: $\frac{1}{2}$ *т*? $\frac{1}{4}$ *т*? $\frac{1}{10}$ *т*?

1174. Ай исемнәрен тәртибе белән әйтегез һәм һәр айда ничә көн икәнен әйтегез.

1175. 1) Ничә сәгать була: 2 тәүлек 10 сәгать? 3 тәүлек 8 сәгать? 5 тәүлек 18 сәгать?

2) Ничә минут була: 5 сәгать? 9 сәгать? 2 сәгать 30 минут?

3) Ничә сәгать була: $\frac{1}{2}$ тәүл.? $\frac{1}{4}$ тәүл.? $\frac{3}{4}$ тәүл.?

4) Ничә минут була: $\frac{1}{2}$ сәгать? $\frac{1}{4}$ сәгать? $\frac{3}{4}$ сәгать?

1176. Үсемлекләрнең тамырлары туфракка менә нинди тирәнлеккә үтеп керәләр:

Үсемлекләр	Тамырлары туфракка нинди тирәнлектә үтеп керә
Бәрәңге	60 *см* га
Солы	110 *см* га
Ужым бодае	116 *см* га
Ужым арышы	130 *см* га
Көнбагыш	145 *см* га

Көнбагыш тамыры, биредә күрсәтелгән башка үсемлекләрнең һәркайсына караганда, туфракка күпмегә тирәнрәк керә?

1177. Үткән ел колхозда 380 баш сыер һәм 450 баш сарык бар иде. Бер ел эчендә сыерлар саны 130 баш, сарыклар саны икеләтә артты. Хәзер колхозда ничә баш сыер һәм ничә баш сарык бар?

1178. Октябрятлар ёлка өчен 16 уенчык, пионерлар 48 уенчык ясадылар. Пионерлар ничә уенчык артыграк ясаганнар? Октябрятлар уенчыкларны ничә тапкыр кимрәк ясаганнар?

1179. Уен өчен төзелгән мәйдан 24 *м* озынлыкта, 15 *м* киңлектә иде. Укучылар мәйданны 2 тапкыр озынайттылар, 17 *м* га киңәйттеләр. Шуннан соң мәйданның озынлыгы һәм киңлеге нинди булды?

1180. Йөк машинасы бер шәһәрдән икенчесенә сәгатькә 50 *км* тизлек белән барды. Юлга чыгуына 6 сәгать үткәч, аның, үтелгән юлга караганда, 100 *км* кимрәк юл үтәсе калды. Шәһәрләр арасындагы ераклыкны табарга.

1181. Машинистка 3 сәгатьтә кулъязманың 15 битен басты. Әгәр ул элеккегә караганда берәр бит артык басса, 5 сәгатьтә ничә бит баса алыр?

1182. Слесарь 2 сәгатьтә 16 деталь ясаган. Әгәр ул элеккегә караганда һәр сәгатькә 2 деталь артыграк ясый башласа, 6 сәгатькә ничә деталь ясар?

1183. Машина йөртүче айга 60 *л* бензинга экономия ясарга йөкләмә алган. 15 көндә ул һәр көнне 3 әр *л*, ә калган 12 көндә һәр көнне 4 әр *л* бензинга экономия ясаган. Ул үзенең йөкләмәсен күпмегә арттырып үтәгән?

1184. Ике җиңел машина бер үк вакытта ике шәһәрдән бер-берсенә каршы юлга чыкты һәм алар 4 сәгатьтән соң очраштылар. Әгәр беренче машина сәгатькә 60 *км* тизлек белән, икенчесе 70 *км* тизлек белән барган булса, шәһәрләр арасындагы ераклык күпме булыр?

1185. Аралары 270 *км* булган ике совхоздан иртә сәгать 9 да бер-берсенә каршы ике йөк машинасы юлга чыкты. Машиналарның берсе сәгатькә 50 *км*, икенчесе 40 *км* тизлек белән барды. Алар сәгать ничәдә очраштылар?

1186. 1) Көймә агым уңаена сәгатькә 10 *км*, агымга каршы ике мәртәбә кимрәк тизлек белән йөзде. Әгәр ике авыл арасы 40 *км* булса, көйманең бер авылдан икенчесенә кадәр бару һәм кире әйләнеп кайтуы өчен ничә сәгать вакыт кирәк булган?

2) 10 саны урынына 8 санын куеп, мәсьәләне яңадан чишегез.

1187. Бер кашык 40 тиен тора. 16 чәнечке бәясе 12 кашык бәясенә тигез. Бер чәнечке күпме тора?

1188. Катерга 150 *км* юл үтәргә кирәк иде. Беренче 2 сәгатьтә ул 60 *км* үтте. Шул ук тизлек белән барганда, катер калган юлны ничә сәгатьтә үтәр?

1189. 40 *км* озынлыкта телефон линиясе үткәрергә кирәк иде. Эшчеләр беренче 5 көндә 2 шәр *км*, аннан соң көнгә 3 әр *км* линия үткәрделәр. Барлык линияне алар ничә көндә үткәрделәр?

1190. 6 тавык һәм берничә үрдәк бер елда 920 йомырка салды. Тавыклар 120 шәр йомырка, үрдәкләр 50 шәр йомырка салдылар. Үрдәкләр ничә булган?

1191. Эшчеләр бригадасы норма буенча бер көндә 24 машина җыярга тиеш иде, ләкин коммунистик хезмәт бригадасы норма буенча 5 көндә җыелырга тиешле машиналарны 3 көндә җыйды. Коммунистик хезмәт бригадасы бер көндә ничә машина җыйган?

1192. 1) Уку елы башында мәктәптә 16 юннат бар иде. Ел уртасында аларның саны 3 тапкыр артты, ә ел ахырына тагын 30 кешегә артты. Бер ел эчендә ничә юннат арткан?

2) Сезнең мәктәптә юннатлар саны арту турында мәсьәлә төзегез.

1193. Ике тимер юл станциясеннән бер үк вакытта ике поезд бер-берсенә каршы юлга чыкты һәм алар 2 сәгатьтән соң очраштылар. Беренче поезд сәгатькә 55 *км* тизлек белән барды. Әгәр станцияләр арасы 240 *км* булса, икенче поезд сәгатькә нинди тизлек белән барган булыр?

1194. Б авылы А һәм В шәһәрләре арасындагы ярты юлда урнашкан. Мотоциклда баручы, сәгатькә 45 *км* тизлек белән барып, А һәм Б арасын 2 сәгатьтә үткән. Әгәр ул сәгатькә 30 *км* тизлек белән барса, Б дан В га кадәр булган араны күпме вакытта үтәр?



1195. Техник ремонтлау станциясендә (РТС) бер атнада көнгә 15 әр трактор, ә икенче атнада көнгә 20 шәр трактор ремонтладылар. Шуннан соң ремонтлыйсы тагын 18 трактор

калган. Барлыгы ничә тракторны ремонтларга кирәк булган? (Атнада 6 эш көне.)

1196. 1) Өч ящикта 60 *кг* печенье булган. Беренче ящикта 24 *кг*, ә беренче һәм икенче ящикның икесендә бергә 42 *кг* печенье булган. Икенче ящикта ничә килограмм һәм өченче ящикта ничә килограмм печенье булган?

2) Өч ящикта 54 *кг* печенье булган дип, мәсьәләне яңадан чишегез.

1197. Балалар бакчасы өчен 4 *ц* бәрәңге сатып алганнар. Бер атнада барлык бәрәңгенең $\frac{1}{8}$ ен, икенче атнада калганының $\frac{1}{10}$ ен тотканнар. Икенче атнада ничә килограмм бәрәңге тотылган? (4 *ц* ны килограммнарга әйләндерергә.)

1198. Сәяхәтчеләр ике көндә 32 *км* юл үткәннәр. Алар беренче көнне 3 сәгать, икенче көнне 5 сәгать барганнар. Сәяхәтчеләр ике көндә дә бер үк тизлек белән барган булсалар, беренче көнне ничә километр һәм икенче көнне ничә километр юл үткәннәр?

1199. Укучылар язга 4 *ц* төрле ашлама хәзерләгәннәр. Җәй башына хәзерләнгән ашламаның $\frac{3}{8}$ е калды. Яз көне балалар ничә килограмм ашламадан файдаланганнар? (4 *ц* ны килограммнарга әйләндерергә.)

1200. Буе 60 *м* һәм иңе 40 *м* булган турыпочмаклык формасындагы яшелчә бакчасын койма белән әйләндереп алдылар. Койманың озынлыгы күпмегә тигез?

1201. Аралары 450 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта ике поезд бер-берсенә каршы юлга чыкты. Беренче поезд сәгатькә 40 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 50 *км* тизлек белән барды. Очрашканчы һәр поезд күпме юл үткән?

1202. Ике поезд бер үк вакытта ике шәһәрдән бер-берсенә каршы юлга чыкты һәм алар 2 сәгатьтән соң очраштылар. Әгәр беренче поезд сәгатькә 50 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 5 *км* га артыграк тизлек белән барган булса, ике шәһәр арасындагы ераклык күпме булган?

1203. Аралары 440 *км* булган ике совхоздан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике йөк машинасы юлга чыкты. Һәм алар 4 сәгатьтән соң очраштылар. Беренче машина сәгатькә 50 *км* тизлек белән барды. Икенче машинаның бару тизлеген белегез.

Счётта исәпләү өчен мисаллар һәм мәсьәләләр.

1204.	2 412 + 4 275	1 736 + 2 154	1 327 + 2 468
	6 172 + 1 826	7 242 + 1 458	2 769 + 3 175
	4 071 + 5 920	9 076 + 824	1 684 + 5 647
	8 632 + 367	618 + 1 391	7 386 + 4 958
1205.	4 758 — 1 235	9 850 — 1 632	352 — 137
	5 976 — 2 352	7 600 — 2 485	5 625 — 286
	4 758 — 4 056	8 000 — 1 924	4 143 — 1 265
	1 467 — 1 202	5 000 — 2 358	8 405 — 7 518

1206. 1) 1 400 санынннан бер-бер артлы түбәндәге саннарны ала барыгыз: 175; 43; 120; 102; 620; 39; 215; 62; 4.

2) 2 100 саныннан бер-бер артлы түбәндәге саннарны алыгыз: 300; 670; 485; 504; 68; 9; 24; 40.

1207. Түбәндәге саннарны 968 санына бер-бер артлы куша барыгыз: 36; 75; 80; 120; 200; 308; 417.

1208. Бу счёт буенча күпме акча түләнергә тиешлекне исәпләп чыгарыгыз.

Товарның исеме	Саны	Бәясе	Күпме түләнгән	
			сум	тиен
Кайчылар	16	70 тиен		
Пычаклар	16	30 „		
Чүкечләр	4	50 „		
Линейкалар	8	10 „		
Компаслар	12	30 „		

Барлыгы:

Язып чишү өчен мисаллар һәм мәсьәләләр.

1209. Алтыурынлы сан языгыз. Анда класс һәм разрядларны күрсәтегез.

1210. Түбәндәге саннарны счётта салыгыз һәм цифрлар белән языгыз:

1) өченче разрядның 5 берәмлеген;

2) бишенче разрядның 8 берәмлеген;

3) икенче классның 185 берәмлеген;

4) икенче классның 175 берәмлеге белән беренче классның 48 берәмлеген.

1211. 35 600 санында ничә дистә бар?
273 050 санында ничә йөз бар?

1212. 1) Кушу өчен бирелгән саннар ничек аталалар?
2) Кушкач килеп чыккан сан ничек атала?

1213. Кушуның дөреслеген ничек тикшерергә?

1214. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

35 708 + 154 976   3 750 + 24 806 + 52 634
488 092 + 93 758   67 480 + 5 396 + 125 748

1215. 1) Алу гамәлендәге саннар ничек аталалар?
2) Алгач килеп чыккан сан ничек атала?

1216. Алуның дөреслеген ничек тикшерергә?

1217. Мисалларны чишегез һәм дөреслеген тикшерегез:

85 314 — 57 628   205 100 — 86 909
300 010 — 109 088   912 081 — 890 907
160 102 — 48 905   482 346 — 378 639
100 000 — 69 714   800 000 — 159 800

1218. Гамәлләрне эшләгез:

96 738 — (52 080 + 9 675)
88 020 — (7 546 + 24 087)
132 987 — (64 094 + 4 089)
428 004 — (9 576 + 274 805)

68 071 — 3 970 + (80 001 — 47 072)
75 105 — 2 762 + (90 000 — 78 403)
160 000 — 48 507 — (70 101 — 52 020)
97 087 — 6 359 + (270 060 — 48 624)

1219. 1) Тапкыр гамәлендәге саннар ничек аталалар?
2) Тапкырлагач килеп чыккан сан ничек атала?
3) Тапкырлауның дөреслеген ничек тикшерергә?

1220. Тапкыр гамәлен эшләгез:

348 × 70	680 × 57	408 × 36	7 986 × 98
695 × 60	930 × 64	504 × 79	6 597 × 79
864 × 80	760 × 95	607 × 48	5 208 × 46
576 × 90	470 × 86	909 × 96	4 079 × 68

1221. 1) Бүлү гамәлендәге саннар ничек аталалар?
2) Бүлгәч килеп чыккан сан ничек атала?
3) Бүлүнең дөреслеген ничек тикшерергә?

1222. Бүлү гамәлен эшләгез һәм тапкырлау юлы белән дөреслеген тикшерегез:

168 750 : 50	30 024 : 36	37 944 : 93	124 380 : 18
252 720 : 60	60 408 : 72	41 607 : 69	131 480 : 19
313 040 : 70	13 590 : 45	41 772 : 59	110 480 : 16

1223.

288 × 48 : 24	232 × 87 : 29	357 × 48 : 72
456 × 96 : 48	432 × 75 : 36	693 × 36 : 54
912 × 78 : 39	603 × 80 : 67	507 × 32 : 48
702 × 68 : 17	608 × 69 : 76	837 × 42 : 63

1224.

609 × 65 : 39	228 × 72 : 54	420 × 68 : 51
705 × 90 : 27	387 × 64 : 48	920 × 87 : 69
906 × 84 : 28	350 × 96 : 64	540 × 58 : 87

1225.

63 072 : 18 × 27	16 281 : 27 × 39	50 376 : 12 × 78
76 038 : 19 × 48	11 340 : 28 × 57	79 272 : 24 × 86
47 753 : 53 × 76	89 892 : 99 × 68	96 084 : 18 × 97

1226. Озынлыгы 20 *см* һәм киңлеге 10 *см* булган бер табак кәгазьгә кушу, алу, тапкырлау, бүлүгә берәр мисал язарга һәм чишәргә. Һәрбер мисал янында саннарның ничек аталуын, гамәлне эшләгәннән соң чыккан санның ничек аталуын язарга.

1227. Бу вакланмаларны цифрлар белән язарга: сигездән жиде; биштән өч; уннан дүрт; өчтән ике; алтыдан биш.

Бу вакланмаларның һәрберсе ничек ясалган?

1228. Колхозларның ашлык сату таблицасын тикшереп карагыз:

	Арыш	Бодай	Солы	Арпа	Барлыгы
„Победа" колхозы	256 *т*	430 *т*	145 *т*	87 *т*	
„Октябрь" колхозы	190 *т*	518 *т*	94 *т*	136 *т*	

Кайсы колхоз күбрәк ашлык саткан һәм күпмегә артыграк саткан?

1229. Колхоз моннан ике ел элек үзенең басуларыннан 1 375 *т* ашлык жыеп алган иде. Үткән ел 1 504 *т*, быел 1 723 *т* ашлык жыеп алды. Колхоз быел, үткән елга караганда, ничә тонна ашлык артыграк жыеп алган? Быел, моннан ике ел элек алуга караганда, күпме ашлык артыграк жыеп алган?

1230. Колхозчылар ашлыкны ике срокта: август һәм октябрьда (таблицаны кара) алдылар. Һәр колхозчының октябрьда күпме ашлык алганын исәпләргә. (Дәфтәргә эшләргә.)

Колхозчыларның фамилияләре	Барлыгы күпме ашлык алырга тиеш	Августта күпме ашлык алынган	Октябрьда күпме ашлык алынган
Касимов	2 720 *кг*	1 965 *кг*	
Мансуров	2 036 *кг*	1 260 *кг*	
Сәйфуллин	2 805 *кг*	1 875 *кг*	

1231. Кошчылык фермасында тавыклар өч айда 15 600 йомырка салдылар: беренче айда 4 890 йомырка, икенчесендә, беренче айга караганда, 536 йомырка артыграк салдылар. Тавыклар өченче айда ничә йомырка салганнар? (Чишелешнең дөреслеген тикшерегез.)

1232. Төзү материаллары складында 1 нче мартка 5 700 *ц* цемент, 2 340 *ц* акбур, акбурга караганда 3 тапкыр артыграк известь бар иде. Склад март аенда 3 850 *ц* цемент, 1 560 *ц* акбур һәм 4 980 *ц* известь сатты. 1 нче апрельгә складта ничәшәр центнер цемент, акбур, известь калган?

1233. Ашханә өчен көз көне 960 *ц* бәрәңге һәм 280 *ц* башка яшелчәләр хәзерләнгән. Язга хәзерләнгән бәрәңгенең өченче өлеше һәм яшелчәләрнең дүртенче өлеше калган. Кыш буе күпме бәрәңге һәм күпме яшелчә тотылган?

1234. Завод 185 пассажир вагоны һәм 456 йөк вагоны ремонтларга тиеш иде. Бер айдан соң пассажир вагоннарының бишенче өлешен, йөк вагоннарының алтынчы өлешен ремонтлыйсы калды. Бер ай эчендә ничә пассажир вагоны һәм ничә йөк вагоны ремонтланган?

1235. Укучылар 1 326 төп карлыган, аңардан 478 төп кимрәк крыжовник, карлыган белән крыжовниктан 480 төп артыграк кура җиләге куаклары үстереп халыкка тараттылар. Укучылар бакчага утырту өчен халыкка барлыгы ничә төп җиләк-җимеш куагы үстереп таратканнар?

1236. 120 пионер җимеш агачы орлыклары җыйган. Алардан: 80 пионер 125 әр *г*, калганнары 175 әр *г* орлык җыйган. Пионерлар барлыгы ничә килограмм орлык җыйганнар?

1237. Ике мәктәп бергә 240 *т* металл ватыклары җыйды. Беренче мәктәп җыйган металл ватыкларын ике вагонга, икенче мәктәп җыйганны өч вагонга төяп озаттылар. Әгәр вагоннарга бертигез төялгән булса, һәр мәктәп ничәшәр тонна металл ватыклары җыйган булыр?

1238. Чишү юлы үткән мәсьәләгә охшаган мәсьәлә төзегез.

1239. 1) Пионерларның бер отряды утырту өчен 4 капчык, икенчесе шундый ук 7 капчык урман чикләвеге җыйган. Беренче отряд 3 *ц* чикләвек җыйган. Икенче отряд ничә килограмм чикләвек җыйган? (3 *ц* ны килограммнарга әйләндерергә.)

2) Үзегезнең җәмгыятькә файдалы эшләрегез турында мәсьәлә төзегез.

1240. Бер колхозчы хезмәт көненә 10 капчык бодай, икенчесе шундый ук 15 капчык бодай алды. Икенче колхозчы, беренчесенә караганда, 4 *ц* артыграк бодай алды. Колхозчыларның һәрберсе ничәшәр центнер бодай алган? (4 *ц* ны килограммнарга әйләндерегез.)

1241. $436 \times 48 : 64$ $\quad$ $508 \times 78 : 52$ $\quad$ $807 \times 52 : 78$

$908 \times 72 : 96$ $\quad$ $832 \times 69 : 92$ $\quad$ $945 \times 79 : 45$

$753 \times 32 : 48$ $\quad$ $678 \times 96 : 72$ $\quad$ $639 \times 68 : 51$

$699 \times 88 : 33$ $\quad$ $562 \times 87 : 58$ $\quad$ $756 \times 84 : 56$

1242. $(41\,215 - 40\,297) \times (100\,001 - 99\,915) : (800 - 746)$

$(10\,006 - 9\,226) \times (6\,900 - 6\,812) : (700 - 648)$

1243. $275\,480 : 97 - 1\,875$ $\quad$ $180\,025 : 25 - 6\,759$

$629\,040 : 80 - 5\,908$ $\quad$ $647\,550 : 18 - 9\,086$

$289\,572 : 59 - 3\,076$ $\quad$ $205\,690 : 67 - 1\,978$

1244. 1) Өч участоктан 2 307 *ц* ашлык җыеп алдылар. Икенче участоктан 695 *ц*, икенче белән өченченең икесеннән бергә 1 433 *ц* җыйдылар. Беренче һәм өченче участоктан күпмешәр ашлык җыйганнар?

2) Мәсьәлә шартындагы 2 307 санын 2 200 гә алмаштырып яңадан чишегез.

1245. Көндезге сәгать 1 дә ике шәһәрдән бер-берсенә каршы ике поезд юлга чыкты һәм алар 5 сәгатьтән соң очраштылар. Әгәр беренче поезд сәгатькә 54 *км*, икенчесе 58 *км* тизлек белән барган булса, ике шәһәр арасындагы ераклык күпме булыр?

1246. Завод 13 550 *т* ташкүмер алды. Беренче айда барлык күмернең $\frac{3}{10}$ е, ә икенче айда, беренчегә караганда, 48 *т* кимрәк күмер тотылды. Заводта ничә тонна күмер калган?

1247. Складта 38 750 данә ак кирпеч, аннан өч тапкыр артыграк кызыл кирпеч бар иде. Һәр вагонга 5 600 әр данә төяп, төзелешкә 8 вагон кызыл кирпеч җибәрелде. Складта күпме кызыл кирпеч калды?

1248. Донбасстан Мәскәүгә 60 вагон күмер җибәрделәр. 38 вагонның һәрберсенә 60 ар *т*, ә калган вагоннарга 50 шәр *т* төяделәр. Барлыгы ничә тонна күмер җибәрелгән?

1249. Магазинда килограммы 3 әр сумнан 320 *кг* конфет бар иде. Көн азагына магазинда конфетның $\frac{3}{8}$ е калды.

Магазин конфет сатудан күпме акча алган?

1250. Китап төпләү цехында 95 520 дәреслекне төпләргә кирәк иде. Беренче көнне барлык дәреслекнең $\frac{3}{8}$ ен, икенче көнне $\frac{1}{10}$ ен төпләделәр. Тагын ничә дәреслек төплисе калды?

1251. Бер шәһәрдән икенче шәһәргә кадәр араны самолёт ... сәгатьтә очты. Башта ул сәгатькә ... *км* тизлек белән ... сәгать очты. Аннан соң очу тизлеген ... *км* га арттырды. Тиешле саннарны куегыз, сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

1252. Тегү мастерское озынлыгы бертигез булган 6 кисәк кара сукно һәм 9 кисәк зәңгәр сукно алды. Кара сукно, зәңгәргә караганда, 135 *м* кимрәк иде. Әгәр һәр пальтога 3 әр *м* материя китсә, зәңгәр сукнодан ничә пальто тегәргә мөмкин?

1253. Аралары 420 *км* булган ике шәһәрдән иртәнге сәгать 6 да бер-берсенә каршы 2 йөк машинасы юлга чыкты. Машиналарның берсе сәгатькә 52 *км* тизлек белән, икенчесе сәгатькә 53 *км* тизлек белән бара. Машиналар сәгать ничәдә очрашырлар?

1254. Мәскәүдән һәм Киевтан бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике товар поезды юлга чыккан. Мәскәү поезды сәгатькә 38 *км*, Киев поезды сәгатькә 40 *км* юл үткән. Поездлар Киевтан нинди ераклыкта очрашканнар? (Мәскәү белән Киев арасы — 858 *км*.)

1255. Өсте алынмаган 1 *кг* сөттән 160 *г* каймак алганнар. Өсте алынган сөттән, сөт авырлыгына караганда, 10 тапкыр кимрәк авырлыкта эремчек чыккан. 1 *кг* сөттән күпме эремчек алганнар?

1256. Ике шәһәр арасындагы ераклык 1 440 *км*. Шуннан 360 *км* юлны поезд сәгатькә 40 *км* тизлек белән, калган юлны сәгатькә 45 *км* тизлек белән үткән. Поезд барлык юлны ничә сәгатьтә үткән?

1257. Кондитер әйберләре хәзерләү фабрикасы ике көндә 3 *т* шикәр бетергән. Ул беренче көнне 14 капчык, икенче көнне шундый ук 16 капчык шикәр тоткан. Фабрика икенче көнне, беренче көнгә караганда, ничә килограмм шикәр артыграк тоткан? (3 *т* ны килограммга әйләндерергә.)

1258. Моторлы көймә бер пристаньнан икенчесенә кадәр агым уңаена минутка 625 *м* тизлек белән 40 минут барды. Кире кайтканда, агымга каршы, 10 минут озаграк кайтты. Көймә агымга каршы, агым уңаена баруга караганда, минутына ничә метр кимрәк барган?

1259. Шахтадагы коммунистик хезмәт бригадасы март аеның беренче 12 көнендә һәр көнгә планнан тыш 45 әр *т* күмер, шул айның калган 15 эш көнендә һәр көнгә планнан тыш 56 шар *т* күмер чыгарган. Әгәр бер вагонга 60 ар *т* төясәләр, бригада март аенда планнан тыш ничә вагон күмер чыгарган?

1260. Колхоз бакчасында 1 120 төп агач бар; барлык агачның $\frac{5}{8}$ е чия, барлык агачның $\frac{1}{10}$ е груша, калганнары алмагач. Бакчада ничә төп алмагач бар?

1261. Аралары 680 *км* булган ике шәһәрдән бер үк вакытта бер-берсенә каршы ике автомобиль юлга чыкты һәм 5 сәгатьтән соң алар очраштылар. Беренче автомобиль сәгатькә 72 *км* тизлек белән барды. Икенче автомобильнең бару тизлеген табарга.

1262. Коммунистик хезмәт бригадасы тукучылары һәр көнне планнан тыш 124 *м* сукно тукып чыгаралар. Әгәр бер айда 27 эш көне булса, һәм балалар пальтосына 2 *м* сукно китсә, бу бригада тарафыннан бер айда планнан тыш эшләп чыгарылган сукнодан ничә пальто тегәргә мөмкин?

1263. 1 380 сарыктан 5 әр *кг* йон һәм 128 сарыктан 6 шар *кг* йон алынган. Юган вакытта йон үз авырлыгының өченче

өлешен югалта. Юганда барлык йонның ничә килограмм авырлыгы югалган?

1264. 1) Пионерлар колхоз кырында 78 йомран оясын юк иттеләр. Йомран бер елга 12 *кг* чамасы ашлык ашый. Әгәр һәр ояда 5 җәнлек дип исәпләсәк, пионерлар бер елда күпме ашлыкны саклап калганнар?

2) Әгәр пионерлар 96 йомран оясын юк итсәләр, бер елда күпме ашлыкны саклап калган булырлар иде?

1265. Буе 35 *м*, иңе 23 *м* озынлыкта булган турыпочмаклык формасындагы ишек алдын койма белән әйләндереп алырга кирәк. Әгәр бер метр коймага 8 планка китсә, ишек алдын әйләндереп алыр өчен ничә планка кирәк булыр?

1266. Ике мотоциклист бер-берсенә каршы юлга чыкты...

Түбәндәгечә чишелерлек итеп, мәсьәләнең шартын тулыландырыгыз:

1) 65 *км* + 75 *км* = 140 *км*.
2) 560 *км* : 140 *км* = 4 (сәгать).

1267. Түбәндәгечә чишелерлек итеп, балалар йортындагы балалар өчен ничә күлмәк тегелгәнен белүгә карата мәсьәлә төзегез:

1) 920 сум + 880 сум = 1 800 сум.
2) 1 800 сум : 20 сум = 90 (*м*).
3) 90 *м* : 3 *м* = 30 (күлмәк).

1268.

47 600 : 85 × 59	26 600 : 76 × 99	87 408 : 72 × 49
3 182 : 86 × 98	34 425 : 85 × 58	673 750 : 25 × 19
43 704 : 72 × 87	48 708 : 36 × 69	871 320 : 53 × 37
21 852 : 36 × 76	63 915 : 15 × 84	264 528 : 24 × 48

1269. 654 һәм 578 саннарының суммасын шул ук саннарның аермасына тапкырларга.

1270. 208 һәм 75 саннарының тапкырчыгышы 136 һәм 92 саннарының тапкырчыгышыннан ничәгә артык?

1271. 90 000 не 75 кә бүлгәч килеп чыккан өлеш 1 920 не 32 гә бүлгәч чыккан өлештән ничә тапкыр артык?

1272. Балалар Кошлар көненә плакат ясадылар. Сызымда плакатның буе һәм иңе 15 тапкыр кечерәйтелгән. Чынлыкта плакатның буе һәм иңе күпме булыр?

КОШЛАР — БЕЗНЕҢ ДУСЛАРЫБЫЗ

1273. 1) Планнан карап, җимеш бакчасы, яшелчә бакчасы һәм җиләклек өчен бүлеп бирелгән участокларның буен, иңен табарга.

2) Һәр участокның яклары суммасын табарга.



1274. Юннатлар мәктәп каршына чәчәклек ясаганнар. Чәчәклек турыпочмаклык формасындагы дүрт клумбадан, квадрат формасындагы дүрт клумбадан һәм түгәрәк формасындагы бер клумбадан торган. Турыпочмаклык формасындагы клумбаларның һәркайсына 328 әр чәчәк үрентесе, квадрат формасындагыларның һәркайсына 106 шар үренте, ә бөтен чәчәклеккә 1 920 үренте утыртканнар. Түгәрәк клумбага ничә чәчәк үрентесе утыртканнар?



1275. Кәгазь фабрикасы мартның беренче 15 көнендә көнгә 420 шәр *т*, калган 12 эш көнендә һәр көн 450 шәр *т* кәгазь эшләп чыгарды. Әгәр һәр вагонга 50 *т* кәгазь төялсә, фабриканың бер айда эшләп чыгарган кәгазен озату өчен ничә вагон кирәк булыр?

1276. Ике пристань арасындагы ераклык 168 *км*. Бу пристаньнардан бер үк вакытта бер-берсенә каршы моторлы ике көймә юлга чыкты. 3 сәгатьтән соң алар очраштылар. Беренче көймә сәгатькә 30 *км* тизлек белән барды. Икенче көймә сәгатькә ничә километр тизлек белән барган?

1277. Балалар санаториясе өчен бер үк сортлы ике ящик печенье сатып алынган. Беренче ящикта икенчесеннән 6 *кг* артыграк печенье булган. Беренче ящик өчен 40 сум, икенчесе өчен 28 сум түләнгән. Барлыгы күпме печенье сатып алынган?

1278. Комсомолларның ике бригадасы урман утыртуда эшләгән. Беренче бригада көнгә 135 әр төп агач утырткан, икенче бригада 5 көндә беренче бригаданың 6 көндә утыртканы кадәр агач утыртырга өлгергән. Икенче бригада, беренче бригадага караганда, көнгә ничә төп агач артыграк утырткан?

1279. Тегермәндә 7 200 *кг* бодай тарттырганнар. Тарттырганда 1 200 *кг* ы көрпәгә киткән. Тартылган онны бертигез итеп капчыкларга салганнар һәм ике машинага төягәннәр. Машиналарның берсендә 40 капчык, икенчесендә 35 капчык он булган. Икенче машинага ничә килограмм он төягәннәр?

1280. Озынлыгын 65 *мм*, киңлеген 40 *мм* итеп турыпочмаклык сызарга.

1281. Якларының суммасы 20 *см* га тигез булган квадрат сызарга.

1282. Безнең районда ... башлангыч мәктәп, ... сигезьеллык мәктәп һәм ... унберьеллык мәктәп бар. Әгәр һәр унберьеллык мәктәптә 125 әр сыерчык оясы, һәр сигезьеллык мәктәптә 75 әр һәм һәр башлангыч мәктәптә 25 әр оя ясасалар, безнең район мәктәбе укучылары ничә сыерчык оясы хәзерләрләр?

Кирәкле саннарны куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

1283. Безнең мәктәпнең 1—4 классларында ... укучы, 5—8 классларында ... укучы, 9—11 классларында ... укучы бар. Әгәр 1—4 класслардагы һәр укучы 2 шәр куак, 5—8 класслардагы һәр укучы 1 әр төп агач һәм 2 шәр куак, ә 8—11 класс укучыларының һәрберсе 2 шәр төп агач һәм 2 шәр төп куак утыртсалар, безнең мәктәп укучылары ничә төп агач һәм ничә төп куак утыртырлар иде? (Саннар куегыз һәм мәсьәләне чишегез.)

1284. Бер районда өченче класс укучылары 900. Уку елы ахырына аларның арифметика китаплары бер дә таушалмаган, чиста хәлдә сакланган. Балалар шушы сандагы арифметика дәреслеген яңадан басар өчен китәчәк кәгазьгә 90 шар битле 1 600 уку китабы басып чыгарырга мөмкин дип исәпләделәр. (Арифметикада 160 бит.) Балалар дөрес исәпләгәннәрме?

1285. Уку елы ахырына безнең мәктәптәге ... укучының дәреслекләре бик яхшы сакланган. Әгәр китапның 16 бите 1 басма табак саналса, бу укучылар ничә табак кәгазьне саклап калганнар?

1286. Элек һәр ел мәктәп бинасын ремонтлауга 278 сум, мебельләрне ремонтлауга 75 сум акча тотыла иде. Хәзер, укучыларның мәктәп милкенә сак караулары нәтиҗәсендә, мәктәп бинасына һәм мебельләргә 4 елда бер генә ремонт ясала башлады. Мәктәп бу ремонтка элек 1 елда тотылган кадәр акча тота. Мәктәп 4 елда дәүләтнең күпме акчасына экономия ясый?

1287. Үткән ел җәй көне шәһәрдән санаторияләрдә 845 бала, пионер лагерьларында 2 650 бала артыграк ял иткән иде. Быел җәй көне санаторияләрдә 1 085 бала, ә пионер лагерьларында 3 825 бала ял итәчәк. Быел санатория һәм пионер

лагерьларында икесендә бергә, үткән елга караганда, ничә бала артыграк ял итәчәк?

1288. Үткән ел безнең шәһәрдән санаториягә ... бала, ә пионер лагерена ... бала артыграк озатылган иде. Быел санаториягә ... бала, пионер лагерына ... бала озатылачак.

Саннарны куегыз, сорау куегыз һәм мәсьәләне чишегез.

1289. Сезнең мәктәптәге 1, 2, 3, 4 нче класс укучылары өчен уку елына ничә дәфтәр кирәк булачагын исәпләгез. Дәфтәрегезгә шушындый таблица төзеп, саннарны һәм гамәл нәтиҗәләрен шунда языгыз.

Класслар	Ничә укучы	Бер укучыга ел буена ничә дәфтәр кирәк	Барлыгы
1			
2			
3			
4			

1290. 1) Әгәр һәр көн 12 шәр бит укый алса, укучы җәйге каникулдагы 84 көндә 72 шәр битле 14 китап укып булыр дип уйлый. Укучы дөрес исәпләгәнме?

2) Үзегез турында шулай исәп йөртеп карагыз.

Кызыклы мәсьәләләр.

1291. Балалар урман каравылчысыннан: „Имәнгә ничә яшь?“ — дип сораганнар. „Ә менә үзегез уйлап карагыз, — дигән ул. — Бер урынлы иң зур санны, ике урынлы иң зур санны һәм өч урынлы иң зур санны кушыгыз; килеп чыккан суммадан дүртурынлы иң кечкенә санны алыгыз һәм сез имәнгә ничә яшь икәнен белерсез“.

Имәнгә ничә яшь булган?

1292. Ике вазада 16 шар алма бар иде. Беренче вазадан берничә алманы алдылар, икенчесеннән беренче вазада калган кадәр алманы алдылар. Ике вазада ничә алма калды?

1293. Вәли ике альбом сатып алган. Иптәше аңардан альбомнар өчен ничәшәр тиен түләгәнен сораган. Вәли: „Кечкенә альбом өчен мин бер төрле 5 акча һәм зур альбом өчен шундый ук 7 акча түләдем. Ике альбом өчен барлыгы 60 тиен түләдем“,—дип җавап биргән. Альбомнар ничәшәр тиен булган?

1294. Балалар бабайдан аңа ничә яшь икәнен сораганнар. Бабай болай дип җавап биргән: „Әгәр минем яшемнең санын 6 тапкыр кечерәйтсәгез һәм килеп чыккан санны 6 га кечерәйтсәгез, 6 килеп чыгар“.

Бабайга ничә яшь?

1295. Әгәр уйлаган санны 3 тапкыр кечерәйтсәк, килеп чыккан санны 3 кә зурайтсак һәм яңадан килеп чыккан санны 3 кә тапкырласак, тапкырчыгыш 333 булыр. Шул санны табарга.



1296. 1) 12 таякчыктан 4 квадрат төзергә. Ике квадрат калырлык итеп, 2 таякчыкны алырга.

2) 12 таякчыктан 4 квадрат төзергә. 3 квадрат булырлык итеп, 3 таякчыкның урынын алмаштырырга.

3) 12 таякчыктан 4 квадрат төзергә. 3 квадрат калырлык итеп, 4 таякчыкның урыннарын алмаштырып куярга.

1297. Әгәр:

1) К урынындагы сан Л урынындагы саннан 2 тапкыр кечерәк;



2) Л урынындагы сан М һәм Н урынындагы саннарның суммасына тигез;

3) М урынындагы сан Н һәм П урынындагы саннарның аермасына тигез;

4) Н урынындагы сан П урынындагы саннан өч тапкыр зуррак;

5) П урынындагы сан 56 дан дүрт тапкыр кечерәк икәне билгеле булса, квадрат эчендәге һәрбер хәреф нинди санны белдерә?

1298. Көймә авылдан 9 *км* агым буенча түбәнгә, аннан соң 15 *км* югарыга, соңыннан тагын түбәнгә 11 *км* йөзде. Көймә авылдан нинди ераклыкта булды?

1299. Ике көймә бер-берсеннән 30 *км* ераклыкта торалар. Әгәр аларның берсе агымга каршы 6 *км*, икенчесе агым уңаена 10 *км* барса, алар арасындагы ераклык күпме булыр?

1300. Ике санның суммасы берсеннән 15 кә һәм икенчесеннән 25 кә зуррак. Бу ике санның суммасы ничәгә тигез була?

1301. Ике санның тапкырчыгышы аларның берсеннән 18 тапкыр һәм икенчесеннән 5 тапкыр зуррак. Бу саннарның тапкырчыгышын табарга.

Таблица 1. **Телдән исәпләү өчен.**

	I	II	III	IV	V	VI	VII	VIII	IX	X
А	4	17	25	32	49	56	68	75	83	96
Б	1	15	28	36	43	57	64	72	85	99
В	7	12	21	35	50	60	65	79	88	93
Г	10	18	30	34	45	55	66	80	82	100
Д	6	14	26	39	42	58	61	74	86	94
Е	9	16	23	31	47	53	69	77	84	91
Ж	3	11	29	37	44	51	63	71	89	97
З	5	20	24	33	46	54	67	76	90	95
И	8	13	27	40	48	52	70	73	87	92
К	2	19	22	38	41	59	62	78	81	98

Таблица 2. **12 дән 19 га кадәрле саннарны берурынлы санга тапкырлау нәтиҗәләре.**

	12	13	14	15	16	17	18	19
2	24	26	28	30	32	34	36	38
3	36	39	42	45	48	51	54	57
4	48	52	56	60	64	68	72	76
5	60	65	70	75	80	85	90	95
6	72	78	84	90	96	102	108	114
7	84	91	98	105	112	119	126	133
8	96	104	112	120	128	136	144	152
9	108	117	126	135	144	153	162	171

ҖАВАПЛАР

289. 216 укучы.
385. 1) 854 радиоалгыч.
386. 290 дәрес.
388. 338 *км.*
393. 6 көнгә.
394. 12 көнгә.
398. 756 сум.
401. 213 сарык.
403. 3 көнгә.
405. 180 *г.*
536. 1) 29 530 *ц.*
2) 2 458 *ц.*
541. 1 679 *т.*
551. 2 214 пар.
552. 2 548 *т.*
553. 792 *км.*
561. 4 258 *т.*
568. 160 *ц* га.
598. 1 436 *т.*
610. 2 046 балага.
613. 324 фуражкага.
637. 2 688 *т.*
638. 2 624 *км.*
642. 2 466 автомобиль.
643. 1 217 трактор.
648. 3 833 пальто.
657. 14 190 *т* га;
36 225 *т* га.
658. 1) 432 ящик, 324 ящик.
664. 2 710 *ц.*
674. 175 *л.*
677. 250 *т*; 200 *т.*
693. 6 800 *кг.*
694. 1) 5 040 *кг.*
699. 1) 2 530 капчык.
711. 1 298 *т.*
714. 194 *т.*
715. 445 печән чапкыч.
718. 1) 1 670 *км.*
721. 14 826 *ц.*
722. 32 499 *ц.*
731. 58 725 шпал.
732. 24 750 шпал.
735. 540 парга. 1 116 парга.
738. 1 008 *км.*
741. 324 сум.
742. 180 *кг.*
744. 195 *км.*
753. 2 656 *т.*
758. 890 *л* га.
782. 2 156 *км.* 3 696 *км.*
788. 704 *км.*
790. 135 *м.*
794. 29 496 агач.
795. 182 *м* га.
797. 1 479 *т.*
797. 1) 375 *т*; 1 048 *т.*
798. 375 *г.*
800. 184 деталь.
814. 9 216 *л*; 9 984 *л.*
839. 3 168 дәф. 768 дәф.
855. 38 рәт.
861. 12 көндә.
862. 14 көндә.
869. 84 сәгатьтә.
874. 18 капчык.
875. 14 капчык.
888. 1) 560 *кг*; 308 *кг.*
889. 2 150 *кг*; 2 250 *кг.*
900. 42 кип; 54 кип.
901. 42 ящ. 39 ящ.
915. 9 мичкә.
918. 372 ящик.
919. 180 вагон.
920. 18 көндә.
922. 149 *ц.*
924. Сәгатькә 36 *км.*
925. Сәгатькә 32 *км.*
926. 170 *км*; 190 *км.*
927. 12 тапкыр.
928. 540 сум.
934. 560 *км.*
938. 640 *км*; 1 920 *км.*
946. 376 *км*; 360 *км.*
951. Сәгатькә 48 *км.*
957. Сәгатькә 37 *км.*
984. 2 550 *км.* 3 825 *км.*
986. 48 *м*; 24 *м.*
988. 12 сәгатьтән сон.
991. 324 *кг.*
993. 1) Сәгатькә 54 *км.*
994. Сәгатькә 24 *км.*

1233. 640 *ц*; 210 *ц*.
1234. 148 вагон; 380 вагон.
1236. 17 *кг*.
1240. 8 *ц*; 12 *ц*.
1244. 1) 874 *ц*; 738 *ц*.
1245. 448 *км*.
1246. 5 468 *т*.
1247. 71 450 кирпеч.
1248. 3 380 *т*.
1249. 600 сум.
1250. 50 148 дәреслек.
1252. 135 пальто.
1253. Иртә 10 сәгатьтә.
1254. 440 *км*.
1256. 33 сәгатьтә.
1257. 200 *кг* га.
1258. 125 *м* га.
1259. 23 вагон.
1261. Сәгатькә 64 *км*.
1262. 1 674 пальто.
1263. 2 556 *кг*.
1264. 1) 4 680 *кг*.
1265. 928 планка.
1274. 184 куак.
1276. Сәгатькә 26 *км*.
1277. 34 *кг*.
1278. 27 агачка.
1286. 1 059 сум.
1287. 570 детальгә.

А. С. Пчёлко, Г. Б. Поляк

АРИФМЕТИКА

для 3-го класса

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе *Н. Х. Зәйни*

Редакторы *Ф. К. Сәгъдиева*

Техник редакторы *З. А. Ибраһимова*

Корректорлары *Х. Г. Мөхәмәтдинова, С. Г. Аблаезова*

Производствога бирелде 22/XII-60 ел. Басарга кул куелды 4/II-61 ел. Кәгазь форматы 60x92¹/₁₆. Учетн. изд. табагы 8,08. Басма табагы 10,5. Тираж 59000 экз. Заказ № И-731.
Бәясе тышлыгыннан башка 8,5 тиен, тышлыгы 7,5 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1961 ел.

Бәясе 16 тиен.